**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ**
**Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

**Л.Ш. Бәдертдинова**

# ГАЗИ КАШШАФНЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ҺӘМ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Казан
2014

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Тат)**
**Б 86**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары белән басыла*

**Фәнни мөхәррир**
филология фәннәре докторы, профессор **Х.Й. Миңнегулов**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы, профессор **З.З. Рәмиев,**
филология фәннәре кандидаты **И.Р. Мөхәммәтов**

**Бәдертдинова Л.Ш.**
**Б 86 Гази Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеге** / Ләйсән Шәүкәтовна Бәдертдинова. – Казан, 2014. – 216 б.

ISBN 978-5-93091-179-4

Китап совет чоры татар әдәби хәрәкәтендә мөһим урын алып торган тәнкыйтьче, галим, педагог, журналист, прозаик, җәмәгать эшлеклесе, М. Җәлил фәненә нигез салучы Гази Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеген яктыртуга багышлана. Биредә әдипнең төрле басмаларда дөнья күргән әдәби-тәнкыйди һәм театр тәнкыйте язмалары анализлана, Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә керткән өлеше бәяләнә.

Хезмәт әдәбият белгечләренә, укытучыларга, студентларга, шулай ук татар театр тарихы, Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 821.512.145**
**ББК 83.3(2Тат)**

**ISBN 978-5-93091-179-4**

© Бәдертдинова Л.Ш., 2014
© Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2014

# ЭЧТӘЛЕК


Татар совет әдәбиятының... йөк аты .......................................... 4

КЕРЕШ ............................................................................................... 7

1. Г. КАШШАФНЫҢ БИОГРАФИЯСЕ ҺӘМ КҮПКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ .......................................................................................... 11

2. Г. КАШШАФ – ПРОЗАИК ..................................................... 34

3. Г. КАШШАФ – ТӘНКЫЙТЬЧЕ ............................................ 57

3.1. Әдәби тәнкыйть язмалары ........................................................ 57

3.2. Театр тәнкыйтьчесе буларак Г. Кашшаф ................................ 123

4. Г. КАШШАФ – ҖӘЛИЛ ФӘНЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ .... 140

4.1. Васыятьне үтәү юлында ........................................................... 140

4.2. Г. Кашшафның М. Җәлил турындагы төп хезмәтләре ....... 157

ЙОМГАК ......................................................................................... 175

БИБЛИОГРАФИЯ ......................................................................... 180

## Татар совет әдәбиятының... йөк аты

Гази Кашшаф (Миргазый Солтан улы Кашшафетдинов – 15.04.1907) – совет чоры кешеләренә, татар мәдәни-рухи тормышы белән кызыксынучыларга бик тә таныш зат. Ул тәнкыйтьче, әдип, журналист, галим, педагог, дәреслекләр авторы, җәмәгать эшлеклесе, әдәби хәрәкәтне оештыручыларның берсе буларак билгеле. Аның шактый гомере «Совет әдәбияты» журналы белән бәйле. Гази ага бу журнал белән сугыш һәм аннан соңгы иң кыен елларда җитәкчелек итә; 116 санына баш мөхәррир буларак кул куя. Шунысы гыйбрәтле: күренекле тюрколог Әмир Нәҗипнең «Совет әдәбияты» журналында (1957, №12) нәшер ителгән «Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер язма истәлекләре» мәкаләсе Борынгы һәм Урта гасыр төрки-татар рухи мирасын өйрәнүчеләр тарафыннан менә берничә дистә ел-лар инде югары бәяләнеп килә. Заманында исә бу язма партия Өлкә комитетының 1958 елгы 25 февраль карарында кискен тәнкыйтьләнә һәм аны басканы өчен Г. Кашшаф баш мөхәррирлек вазифасыннан азат ителә.

Гази аганың бер аягы юк иде (ул аны кайда, ничек югалткандыр, – анысын белмим). Татарның «Аксак күп йөрер» әйтемендәге кебек, ул протез белән дә дүрт саны төгәл кешеләргә караганда күбрәк йөрде, күбрәк эш-гамәл кылды. Аның, мәсәлән, сугыш елларындагы эшчәнлеген чын мәгънәсендә фидакарьлек дип атарга мөмкин. Журнал, нәшрият, әдәби иҗат эшләреннән тыш, ул фронттагы каләмдәшләре белән элемтәдә тора, аларның үзләренә, гаиләләренә төрле ярдәмнәр оештыра. Мәгълүм ки, сугыш чорында Казанга, Татарстанга вакытлыча яшәү өчен күпләгән Совет һәм чит ил әдипләре китерелә. Аларны урнаштыру, оештыру мәшәкатьләренең дә шактый өлеше Гази ага җилкәсенә төшә.

Бу мөхтәрәм зат – 400 дән артык мәкалә-хезмәт авторы. Тематикалары, эчтәлекләре белән алар гаять төрле. Бу язмаларда әдәби бәйләнешләр, башка халыкларның да әдәбиятлары теге яки бу дәрәҗәдә гомумтатар сүз сәнгате, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге, уңышлары, кимчелекләре хакында да сүз бара. Гази ага үзәк матбугатта, бөтенсоюз мөнбәрләреннән дә татар әдәбияты турында чы-

гышлар ясап тора. Тәнкыйтьченең иҗат мирасында татар театры, драматургиясе мәсьәләләре зур урынны били. Спектакль-тамашалар карарга аның еш йөргәнен әле мин дә хәтерлим.

Гази ага әдәбияттагы һәр яңа күренешкә үзенең тәнкыйди мөнәсәбәтен белдереп барырга тырышты. Тәҗрибәле әдипләр белән беррәттән, ул башлап язучыларның әсәрләрен дә даим күз уңында тотты. Шунысы мөһим: Г. Кашшаф үзенең тәнкыйди эшчәнлегендә иҗат әһелләренә, аларның язмаларына һәрчак диярлек сак, гадел, объектив якын килергә омтылды, үзе ялгышлар җибәргәндә, аларны танудан да тартынмады, үзен тәнкыйтьләүчеләргә ачу сакламады. Мәгълүм ки, узган гасыр урталарында Гали Халит үзенең аерым мәкаләләрендә Г. Кашшафны да тәнкыйтьләп ала. Әмма аңа карап Гази ага үзенең каләмдәшенә һич тә ачу сакламады, хәтта аның хакында уңай эчтәлекле язмалар да бастырды.

Әдипләр даирәсендә шушындый бер сөйләк йөри: имеш, кемдер аңа «Гази абый, сез үзегез тәнкыйтьче, ә күбрәк кешеләрне мактап язасыз, тәнкыйтьләмисез», – дигән. Аңа Гази ага: «Анысын син эшлә инде», дип, җавап биргән, имеш.

Г. Кашшаф, әйткәнебезчә, төрле тармакларда хезмәт куйган зат. Әмма аның эшчәнлегендә төп һәм хәлиткеч урынны Муса Җәлилне өйрәнү алып тора. Бу һич тә очраклы хәл түгел. Патриот-шагыйрь һәм тәнкыйтьче фикердәш, дуслар була. М. Җәлил үзенең хатларында да Г. Кашшафны «кадерле» иптәше, «иң якын һәм кайгыртучан дус», ышанычлы, тугрылыклы зат булуын ассызыклый. 1942 елның 27 маенда язылган васыять хатын да нәкъ менә Г. Кашшафка атап яза. Гази ага бөек шагыйрьнең, дустының васыятен җиренә җиткереп үти. Аның М. Җәлилне аклау, аны өйрәнү, пропагандалау өлкәсендәге эшчәнлеге биниһая олы батырлык. Әгәр дә М. Җәлил, аның иҗаты бөтен дөньяда танылу алган икән, монда Г. Кашшафның роле дә бәяләп бетергесез.

Гази аганы күпләр үзенең дусты, остазы дип хисаплый. Болар арасында күренекле зат Рафаэль Мостафинның булуы үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Куаныч ки, Гази ага шәхсән минем дә остазларымның берсе. Мин аның язмаларын кечкенәдән үк укып үстем. Ул 1961–1964 елларда, ягъни безнең студентлык вакытында КДУның татар әдәбияты кафедрасында эшләде. Безгә аның лекцияләрен тыңларга туры килде. Мин бер курс эшен дә аның җитәкчелегендә язган идем. Миңа партиягә керергә рекомендация бирүчеләрнең дә берсе Гази ага булды. Без берничә ел буена бер коллективта – тарих-филология факультетында бергә эшләдек, үзара аралашып, очрашып тордык. Студентларның тулай торагында Гази ага белән очрашу оештырганыбызны да хәтерлим. Анда безнең бүлек, факультет студентлары гына түгел, күпләгән кунаклар да катнашкан иде.

Миңа Гази аганың үзе кебек тыйнак булган улы Ренард Кашафетдинов белән дә бергә эшләргә туры килде. Ул тарихчы иде, факультет деканының урынбасары, университет парткомының секретаре вазифаларын да үтәде.

Г. Кашшаф хакында күпләрнең истәлекләре, язмалары бар. Аларда бу затның матур әхлакый һәм инсани сыйфатлары һәрчак ассызыклана. «Син, дускай, үзең бик әйбәт кенә кеше болай, тик бер җитешмәгән ягың бар – артык тыйнак!» – ди аның 60 еллыгында Әхмәт Фәйзи. Моңа Габдрахман Минский болай дип тә өсти: «Иртәгә дә бүгенгедәй хезмәт сөйгән, тыйнак замандашларыбызның берсе бул! Артык тыйнак булуың да зарарсыз». Татар һәм башкорт халыкларының мәшһүр әдибе Сәйфи Кудаш мондый юлларны язып калдырган: «Г. Кашшаф татар совет әдәбиятының сабан туйларында яки ипподромнарда елына бер тапкыр чаба һәм юырта торган аргамакларыннан түгел. Ул татар совет әдәбиятының ел әйләнәсенә муеннан камыт төшерми торган йөк аты булды. Аны нинди зурлыктагы арбага җиксәләр һәм аңа күпме йөк салсалар, ул шуны тарта һәм алга таба сөйрәп барды».

*Х. Миңнегулов*

# КЕРЕШ

«Гази Кашшаф – күренекле әдәбиятчы, тәнкыйтьче, журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Гази аганың бөтен гомере әдәбият һәм журналистика белән бәйле булды. Ул әдәбият гыйлеме һәм тәнкыйте өлкәсендә дә зур мирас калдырды. Аның игътибарыннан читтә калган берәр танылган әдип булдымы икән! Бик күп яшь әдипләр һәм журналистлар иҗатка аңардан фатиха алдылар», − дип яза Ф. Әгъзәмов[1]. Бүгенге көндә Г. Кашшафның исеме журналистикага мөнәсәбәттә еш яңгырый. Әдәбият тарихында ул М. Җәлил фәненә нигез салучы галим буларак таныла. Әдипнең эшчәнлеге моның белән генә чикләнми. Аның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми мирасын өйрәнү совет чоры татар әдәби тәнкыйтенең тарихы, аның үсеш-үзгәреше турында аерым тәнкыйтьче-галим эшчәнлеге мисалында сүз йөртергә мөмкинлек тудыра.

«Татар әдәбияты тарихы» томлыкларында Г. Кашшаф эшчәнлеге Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти, М. Гайнуллин кебек әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләре белән беррәттән аерым бүлектә тикшерелә. «…хәзер шундый вакыт җитте: Гази Кашшафның иҗади мирасын җыеп, тәртипкә салып, аңа тулы бәя бирергә кирәк. Гази Кашшаф − безнең әдәбият һәм мәдәният тарихыбызда үзенә лаеклы урын алырга тиешле шәхес», − дип яза Р. Нуруллина[2]. Ш. Рәкыйпов, бераз арттырып булса да, остазын: «Үз мәнфәгате турында һич-һич кайгыртмаган Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Исхакый, Дәрдемәнд кебек олуг зат иде бит ул»[3], − дип бәяли. Совет чорында татар әдәбиятының сулышын тоеп яшәгән Г. Кашшаф эшчәнлегенең әһәмиятен үз заманында аңа багышлап язылган әдәби әсәрләр дә дәлилли ала. Алар арасында М. Җәлил,

---

[1] Әгъзамов Ф. Тугрылык // Мәдәни җомга. 1997. 25 апрель.

[2] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим. Очерк һәм эссе: Югары уку йортларының журналистика бүлеге студентларына «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан уку ярдәмлеге. Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 28.

[3] Рәкыйпов Ш. Олуг үрнәк иде // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 41 .

Х. Туфан, И. Юзеев шигырьләрен, Г. Әпсәләмовның Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил, батыр җәлилчеләр һәм аларның турылыклы дусты Гази Кашшафның якты истәлегенә багышлынган «Агыла болыт» романын, Г. Ахуновның «Ардуан батыр» повестен һәм шул ук авторның «Йолдызлар калка» повестенең Г. Кашшафка багышланган «Остазымның кайбер гадәтләре» бүлеген атап узарга мөмкин.

Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди, гыйльми, язучылык эше, журналистика өлкәсендә башкарылган эшчәнлеге белән чагыштырганда, аз өйрәнелгән өлкәләр. Г. Кашшафның әдәби тәнкыйть өлкәсенә кагылышлы күпсанлы мәкаләләренең төп өлеше вакытлы матбугат битләрендә дөнья кургән. Шулар арасында «Авыл яшьләре», «Социалистик Татарстан» («Кызыл Татарстан»), «Татарстан яшьләре» («Яшь сталинчы»), «Советская Татария» («Красная Татария»), «Совет әдәбияты», «Совет мәктәбе», «Азат хатын», «Ялкын» һ.б. бик күп газета-журналларның исемнәрен атый алабыз. Аларда басылып чыккан материаллар әдәби-тарихи анализлауга һәм бәя алырга хаклы.

Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми мирасын тикшергән махсус хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Шулай да, газета журнал битләрендә бу куренекле затның эшчәнлеген яктырткан мәкаләләр басылган, аерым язучыларның истәлекләре саклана. Н. Юзиевнең аның биографиясенә һәм эшчәнлегенә багышланган мәкаләсе татар әдәбияты тарихының бишенче томында урын алган. Анда ул: «Гази Кашшаф кырык елга якын сузылган иҗат эшчәнлеге белән әдәби хәрәкәтнең уртасында кайнады, үз чоры әдәбиятының актуаль мәсьәләләрен күтәреп, әдәби тәнкыйтьнең алгы сафында атлады. Ул үзенең күптармаклы эшчәнлеге белән татар совет әдәбияты үсешенә уңай йогынты ясаган талантлы тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме иде», – дигән фикер җиткерә[1]. Моннан тыш, Г.Кашшафның тормыш һәм иҗат юлын тикшергән мәкаләләр арасында Р.Н. Даутовның «Совет Татарстаны язучылары: биобиблиографик белешмә», «Әдипләребез: био-

[1] Юзиев Н. Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы: 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. Б.500 .

библиографик белешмәлек»[1] китапларында китерелгән язмаларын әйтеп узарга мөмкин. Тәнкыйтьченең журналистлык эшчәнлеген Р. Нуруллина «Вакыт сынавын үтеп», «Тугрылык», Ф. Әгъзамов «Остаз», «Якты эз», И. Низамов «Остаз мирасына тугрылык», М. Мәрдиева «Совет әдәбияты» журналында...», Ш. Рәкыйпов «Беренче кирәкле шәйдер», «Олуг үрнәк иде» һ.б. мәкалә-истәлекләрендә яктырталар[2]. Г. Кашшафка багышланган мәкаләләрнең күбесе аның М. Җәлил иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүне күздә тотып язылган. Аларда шагыйрь белән тәнкыйтьченең дуслыгына басым ясала, күп кенә язмаларда (Г. Минскийның «Халыкка хезмәт», И. Ахунҗановның «Остаз», З. Низаметдиновның «Җәлил дусты», Н. Юзиевнең «Фидакарьлек»[3] һ.б.) шагыйрьнең Г.Кашшафка язган васыяте искә алына. Г. Кашшафның укучысы Г. Ахунов аны, нигездә, «Совет әдәбияты» журналы редакторы, шәхес буларак искә ала[4].

Язучы Г. Кашшафның әдәби әсәрләренә тәнкыйди карашлар Ә. Камал, М. Фәйзуллина, Г. Иделле язмаларында китерелә[5].

---

[1] Даутов Р.Н. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә / Р.Н. Даутов, Н.Б. Нуруллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 246–248; Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек / Төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани: 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. Т. 1. Б. 751.

[2] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 14–29 .; Нуруллина Р. Тугрылык // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 172-173; Әгъзамов Ф. Остаз // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 9–14; Әгъзамов Ф. Якты эз // Социалистик Татарстан. 1977. 14 апрель; Низамов И. Остаз мирасына тугрылык // Мәдәни җомга. 2007. 27 апрель; Мәрдиева М. «Совет әдәбияты» журналында... // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 50–59; Рәкыйпов Ш. Беренче кирәкле шәйдер // Шәһри Казан. 1997. 18 апрель; Рәкыйпов Ш. Олуг үрнәк иде // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 29–50 .

[3] Минский Г. Халыкка хезмәт: Г. Кашшафка 60 яшь // Казан утлары. 1967. № 4. Б. 96-97; Ахунҗанов И. Остаз // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 3–8; Низаметдинов З. Җәлил дусты // Мәйдан. 2007. № 4. Б. 77–86; Ахунов Г. Беренче остазым // Мәдәни җомга. 1997. 1 май; Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 127–140.

[4] Ахунов Г. Гази Кашшаф хатлары // Татарстан. 1994. № 7–8. Б. 76–80.

[5] Камал Ә. Укытучы // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 76–78; Фәйзуллина М. Совет хатын-кызының героик образын бозып бирүчеләргә каршы // Кызыл Та-

Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди хезмәтләренә карата берьяклы һәм кайвакыт кискен тәнкыйтьне Г. Халит һәм К. Фасиев язмаларында очратырга мөмкин. Әмма XX гасырның 40 – 50 нче елларында язылган бу мәкаләләр Г. Кашшаф эшчәнлегенә тулы бәя бирүне күздә тотмый, ә бәлки тәнкыйтьченең аерым хезмәтләрен генә яктырталар. Әлеге тәнкыйтьче-галимнәрнең әдәбиятка кагылышлы карашлары бүгенге көндә яңадан күзәтеп чыгуга һәм объектив бәяләмәгә мохтаҗ.

Хезмәттә Г. Кашшафның әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыклар, газета-журнал битләрендә басылып чыккан рецензияләр, докладлар, язмалар, әдәби әсәрләр, монографияләр, кыйммәткә ия өстәмә чыганаклар буларак, көндәлекләр, истәлекләр, хатлар, шулай ук әдипнең Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, Казан (Идел буе) федераль университетының кадрлар бүлегендә сакланган шәхси фондыннан аның биографиясенә һәм эшчәнлегенә караган кайбер материаллар кулланылды.

Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми хезмәтләре беренче тапкыр аның күпкырлы эшчәнлеге контекстында һәм газета-журнал битләрендә дөнья күргән күпсанлы язмалары, хезмәтләре белән бергә туплап тикшерелә. Алар совет чоры әдәби процессының идеологик һәм сәяси чынбарлыгын күздә тотып карала. Тикшерену барышында тупланган материаллар тәнкыйтьченең эшчәнлеген совет чоры, татар әдәбияты белеме үсеше җирлегендә объектив рәвештә күз алдына китерергә мөмкинлек тудыра.

Тәнкыйтьче-галимнең әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеген чорларга яңача бүлеп карау тәкъдим ителә. Монографиянең аерым өлешендә Г. Кашшаф М. Җәлилне өйрәнү фәненә нигез салучы буларак тикшерелә.

---

тарстан. 1947. 7 июль; Иделле (Усманов) Г. Партия һәм халык таләпләрен большевикларча үтәү өчен! // Кызыл Татарстан. 1946. 22 ноябрь.

# 1. Г. КАШШАФНЫҢ БИОГРАФИЯСЕ
# ҺӘМ КҮПКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Гази Кашшаф (Миргазый Солтан улы Кашшафетдинов) 1907 елның 15 апрелендә Уфа губернасы, Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы, Туймазы районы), Яңа Арсланбәк авылында мулла гаиләсендә туа. Миргазыйның ата-бабасы һәм нәсел-ыруы укымышлы, затлы нәселдән. Аның бабасы Кашшафетдин Казан мәдрәсәсендә белем алган, Татарстанның Азнакай районында мөгаллимлек иткән, соңрак мулла вазифасын башкарган. Гомумән, Г. Кашшаф нәселендә мөгаллимнәр, муллалар һәм укытучылар күп, берничәсе Мәккә-Мәдинәгә хаҗга бару бәхетенә дә ирешкән. Аның атасы инкыйлабтан соң, 1922 елда, авыл мулласы һәм мөгаллимлек вазифаларын ташларга мәҗбүр булып, алга таба үз хуҗалыгында гади крестьян хезмәте белән шөгыльләнә. Хосусый хуҗалыклар күмәкләштерелгәч, туган авылы колхозында умартачы булып эшли.

Миргазый, әтисеннән укырга-язарга өйрәнеп, авыл мәктәбендә башлангыч белем алганнан соң, 1920 – 1925 елларда Бәләбәй шәһәрендәге укытучылар семинариясендә (соңыннан – педагогия техникумы) укый, аннары Уфада кыска сроклы әзерлек курсларын тәмамлый. Аның иҗат белән кызыксынуы Бәләбәй педагогия техникумында укыган вакытларында башлана. Беренче карашка, тыныч кына аккан тормыш агымы кулына каләм алган Г. Кашшафка карата мәрхәмәтле кебек күренә. Чынлыкта исә, булачак тәнкыйтьче яшәешнең иң авыр минутларын кичерә. И.А. Ахунҗанов үзенең «Художник һәм аның сүзе» дигән мәкаләсендә Г. Кашшафны Г. Ахуновның Ардуан батыры белән чагыштыра һәм моны бигрәк тә Г. Кашшафның истәлекләренә күз салып исбат итәргә тырыша: «Кереп кунар урын һәм бер кабымлык икмәк өчен мин дуңгызлар, кәҗәләр көттем, бакча казыдым, җәй көннәрендә, җилкәмә күтәреп, урманнан утын ташыдым...»[1]. Тормышның әлеге сынауларын узганнан соң да, яшь күңелнең матурлыкны яратуы сүнмәгән, сүрелмәгән.

---

[1] Ахунҗанов И.А. Остаз // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 3.

Үзен биләп алган көчле мавыгу, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Һ. Такташ кебек әдипләрне үз күзләре белән күрергә омтылу Г. Кашшафны Казанга алып килә. Көнчыгыш педагогия институтында уку елларында (1924 – 1928) ул иҗат эше белән ныклап кызыксынып китә. Татар мәдәнияте йортында эшләп килгән яшь язучылар түгәрәгендә актив катнаша, соңрак, Г. Кутуй, М. Әмир кебек, бу түгәрәккә үзе дә җитәкчелек итә. Татар язучыларының әсәрләре һәм театрда барган спектакльләр турында беренче рецензияләре, мәкаләләре дә шушы елларда языла. 1928 елда алар «Авыл яшьләре» журналында, «Кызыл яшьләр» газетасында «Кәш», «Г. К.», «Кәшгаз», «Кәләй», «Газый Кәшшаф» имзалары белән басылып чыгалар. Әйтергә кирәк, заман шаукымына ияреп, үзен күрсәтергә тырышкан Г. Кашшаф бу елларда төрле хаталардан да азат түгел. Аның, мәсәлән, вульгар социологизм белән мавыгып китүен вакытлы матбугатта басылган тәнкыйть мәкаләләре дә күрсәтеп тора. Шул ук вакытта, яшь тәнкыйтьче әдәбиятка бәйле вакыйгаларда катнаша. Мәгълүм булганча, егерменче елларда ТАПП, РАПП һ.б. оешмалар әдәбиятта үз юлларын, үз кыйблаларын билгелиләр. Г. Кашшаф та ТАПП оешмасының әгъзалары рәтендә тора. 1930 елның көзендә ТАПП әгзаларын «тазарту» кампаниясе үткәрелә. «ТАПП әгзаларын тазарту комиссиясенең беркетмәсе»ннән мәгълүм булганча, бу «тазарту»га 52 кеше чакырыла, шулар арасыннан унысы «тазарту» аша үтә алмый һәм алар ТАПП составыннан чыгарылалар (...Гази Кашшаф – «тазарту вакытында тупас кылануы, биргән сорауларга дөрес җавап бирмәве, чит элементларга хас булган гадәтләрен бетерергә теләмәве өчен»)...»[1].

Институтны тәмамлаганнан соң, Г. Кашшаф төрле уку йортларында (Татрабфакта, Авыл хуҗалыгы коммуналь мәктәбендә, Тире һәм мех промышленносте техникумында, Авыл хуҗалыгы институтында) татар теле һәм әдәбияты укыта. Техникумда алып барылган әдәби эшчәнлеге хакында «Совет әдәбияты» журналында басылып чыккан «Без ничек эшлибез» язмасы хәбәр итә. 1937 елда

[1] Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4. Б. 106.

Г. Кашшафны Татарстан китап нәшриятына өлкән әдәби консультант итеп эшкә чакыралар, ике елдан соң матур әдәбият секторының өлкән мөхәррире (мөдире) итеп билгелиләр.

Әдипнең егерменче еллар ахыры – утызынчы еллар башындагы эшчәнлеге басылып чыккан һәр яңа китапны, җыентыкны бәяләп барырга омтылуы, аларны киң җәмәгатьчелеккә актив рәвештә пропагандалавы белән сыйфатлана. «Авыл яшьләре», «Совет әдәбияты» журналларында, «Кызыл Татарстан», «Кызыл яшьләр» газеталарында И. Гази, Һ. Такташ, Ш. Маннур, М. Крымов, Т. Ченәкәй, Г. Кутуйның шигырь китаплары, М. Максудның нәсерләре, А. Таһиров, М. Галәүнең хикәяләр җыентыклары турында Г. Кашшафның рецензияләре басыла. Шул чордагы әдәби хәрәкәт тәэсиренә ияреп, яшь тәнкыйтьче аерым язучылар иҗатын, кайбер әдәби күренешләрне укучыларга берьяклырак аңлата. Менә аның утызынчы еллардан алып, алга таба үсешен күзәткән Ә. Исхак истәлекләреннән бер өзек: «Егерме бер яшьлек бу егет ул вакытта кай ягы белән минем күңелне үзенә җәлеп иткәндер, анысын белмим. Ә тора-бара минем күңелемә бөтен барлыгы белән кереп утыруының сәбәпләрен табарга була... Бу, минемчә, беренче нәүбәттә, аның характеры, күпләргә үрнәк булырлык тыйнаклыгы, сабырлыгы, нинди авыр шартларда да түземлелеге. Сүрелмәс оптимизмы. Тынгысыз хәрәкәтчәнлеге. Хезмәт сөюе. Ирешкәннәр белән тынычлана белмәве. Кешене тыңлау осталыгы. Алар белән мөнәсәбәттә үзен тота белүе. Әдәбият һәм сәнгатькә мәхәббәт. Бу өлкәләрдәге уңышларга ихлас күңелдән куана, кимчелекләргә әрни белүе. Масая һәм үпкәли белмәве... Кыскасы, Газинең андый кешелек сыйфатларын санап бетерергә мөмкин түгел»[1].

Утызынчы елларның икенче яртысында Г. Кашшаф «Совет әдәбияты», «Совет мәктәбе», «Азат хатын» кебек журналларда, «Кызыл Татарстан» һ.б. газеталарда еш чыгыш ясый. Мисал өчен, 1938 елда Хәсән Хәйри белән берлектә, аның «Совет мәктәбе» журналында Г. Тукайның бер томлыгы басылып чыгу уңаеннан

[1] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 132.

рецензиясе дөнья күрә. Шул ук елда «Яшь сталинчы» газетасында Г. Кашшафның «Тукай һәм аның чоры» язмасы басыла. Бу чор иҗатында аның театр, драматургия белән кызыксынуын да ассызыкларга кирәк. Хәсән Хәйри, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Әхмәт Исхак, Хан Җәмил белән берлектә спектакль постановкаларына язылган рецензияләре татар театры тәнкыйтендә үз урынnarын алдылар. Моннан тыш И. Вахитов белән берлектә Г. Камал иҗатын һәм эшчәнлеген өйрәнеп язылган мәкаләне аерып чыгарырга мөмкин.

Әдәби тәнкыйть, әдәбият тарихы һәм драматургия-театр өлкәләрендә алып барылган эзләнүләр белән беррәттән, Г. Кашшаф шушы елларда проза жанрында да көчен сынап карый. 1934 елгы «Совет әдәбияты»нда аның «Охранник» дип исемләнгән шактый күләмле хикәясе урын алган. Чик сакчыларына багышланган «Ил чигендә» хикәясе 1935 елгы «Совет әдәбияты» журналының берничә санында басылып килә. Соңрак бу хикәя нигезендә язылган «Чүл буенда» (1940) повесте дөнья күрә. Шул ук елда «Укытучы» дигән хикәяләр җыентыгы, берничә хикәя-очеркы «Совет әдәбияты»нда басыла. 1938 елда ул А.И. Ульянова-Елизарованың «Ильичның балалык һәм мәктәп еллары», соңрак, 1940 елда, А. Гайдарның «Сугыш сере турында әкият» исемле әсәрләренең ирекле тәрҗемәләрен тәкъдим итә. Әмма шулай да, нигездә, Г. Кашшаф тәнкыйтьче буларак таныла.

Совет чорында әдәбият һәрвакыт сәясәт басымы астында яши. Утызынчы елларда күп очракта хаксызга гаепләнеп җәзага тартылган интеллигенция вәкилләре арасында татар язучы-шагыйрьләре дә аз түгел. Кызганыч ки, Г. Кашшаф та бу вакыйгалардан читтә калмаган. Дөрес, ул хөкем ителмәгән, әмма шул хөкем чыгаруларда, турыдан-туры булмаса да, катнашкан.

1941 елда Х. Туфанның «эше» буенча өченче комиссия утырышында шагыйрь Ш. Маннур, тәнкыйтьче Г. Кашшаф, «Кызыл Татарстан» газетасының баш мөхәррире И. Үзбәков асылда шагыйрьнең язмышын хәл итәләр. «Язучыларның V съездында Ш. Маннур ясаган чыгышка караганда, комиссия башта уңай, Туфанны аклый торган нәтиҗәгә килә. Актны да шул рухта язып бирәләр. Ләкин тикшерүче

бераз басым ясап, «кыса» башлагач, фикерләрен 180 градуска үзгәртеп, «кирәкле» кәгазьне язып бирәләр»[1]. Х. Туфан исеме татар әдәбияты тарихыннан сызыла, әмма вакытлыча гына. Иректән мәхрүм ителгән шагыйрь 1957 елда реабилитацияләнә. Әлеге үткән вакыйгага карата шул ук елны Г. Кашшаф болай дип җавап бирә: «Чыннан да, Туфанны революциягә, Советка каршы кеше дип әйтергә бернинди нигез юк иде. Безне НКВД тикшерүчесе З.К. Батуллин чакыртып алды. Туфанның үз-үзен фаш итә торган шаһитнамәләрен укыды. Гаебен үзе таныгач, ничек ышанмыйсың? Димәк, бик оста яшеренә белгән икән, дип уйладык. Тикшерүче безгә ничек язарга кирәклеген аңлатты. Шулай итеп, без Туфанны политик яктан гаепли торган, чынында исә – гаделсез булган экспертизаны яздык (1957 ел, 25 гыйнвар)»[2]. Вакыйга моның белән дә тәмамланмый. Х. Туфан сөргеннән кайткач, Г. Кашшафның М. Җәлил иҗатын өйрәнеп язылган хезмәтенә соклана һәм тәнкыйтьчегә багышлап шигырь яза[3]. Әлеге вакыйгаларга Г. Кашшафның еллар узганнан соң туган карашын, шул уңайдан татар халкы тарихына бәйле фикерләрен Ш. Рәкыйпов бер мәкаләсендә җиткерә: «... шәхес культы заманнарын искә төшерсәк, анда ни генә юк! Артык болар дип, күп җимеш бирә торган ботакларны да кистеләр шул... Бихәбәр булсыннар дип, безнең алфавитны да кат-кат үзгәрттеләр. Әмма тарихны алай гына үзгәртеп булмый. Агымсу, астан – җир куеныннан тибеп торган саф чишмәләр барыбер үз юлларын тапкан кебек, хакыйкать тә бәреп чыга ул!»[4]. Шул рәвешле, совет чорында әдәбият дөньясындагы шәхесләргә бик күпне күрергә, бик күпне кичерергә һәм еллар узгач та, үз эшләре өчен җавап тотарга туры килә.

Кырыгынчы елларда Г. Кашшафның әдәбият фәне, әдәбият-сәнгать тәнкыйте, педагогика, журналистика өлкәләрендәге күптармаклы эшчәнлеге җәелә төшә. Бу чорда тәнкыйтьче әдәби

---

[1] Мостафин Р. Бер «зарарлы әсәр» тарихы... // Сүнмәс утлар балкышы. Казан: Идел-Пресс, 2006. 250 б.

[2] Шунда ук.

[3] Шунда ук.

[4] Рәкыйпов Ш. Олуг үрнәк иде // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 14–29.

процесс белән тыгызрак һәм якынрак бәйләнешләрдә яши, күренекле җәмәгать эшлеклесе, әдәбият галиме һәм педагог-остаз буларак таныла. 1942 елның октябреннән ул рәсми рәвештә «Совет әдәбияты» журналының редакторы вазифасында.

«Атака»ның «Совет әдәбияты» исемендә чыгуы әдәбиятта социалистик реализм методын үзләштерү өчен көрәш башланган елларга туры килә. Нәкъ менә шушы елларда журнал битләрендә Г. Кашшаф исеме дә күренә, дип яза М. Мәрдиева[1]. Мөхәррир сүзе язучы, журналист, автор, редактор кебек мәгънәләрне үз эченә сыйдыра. Шул ук вакытта, совет чоры әлеге хезмәт иясенә үз йөкләмәсен дә өсти. Билгеле бер дәрәҗәдә мөхәррирлек эше бу чорда сәясәт, илдә барган тарихи вакыйгалар белән дә турыдан-туры бәйләнешкә керә, партия, аның карарлары нигезендә яшәргә мәҗбүр ителә, соцреализм иҗат методын беренче планга куя. Г. Кашшафның мөхәррирлек хезмәтенең беренче чоры Бөек Ватан сугышы елларына туры килә.

Н. Юзиев һәм М. Мәрдиева Г. Кашшафның бу эшчәнлеге 1942 елның октябрь аеннан башлана, дип язып чыгалар[2]. Чынлыкта исә, беренче тәҗрибәсе 1941 елда ук була. Әлеге елның 12 нче саны өчен җаваплы редактор итеп Г. Кашшаф билгеләнә, ә 1942 елда ул мөхәррирлек эшенә тулы хокук ала. Аның бу вакыйгаларга кагылышлы истәлеге бар. «Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган, – дип яза ул. – Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби сотрудник штаты кыскарды. Бу вакытта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Г. Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде, бөтен эш А. Гомәр җилкәсенә авып калды.

1942 елны Г. Бәшировны мин алыштырдым, ул Татрадиокомитетның баш редакторы булып китте. Журналдагы хәл авырлы-

---

[1] Мәрдиева М. Эзләнүләр һәм үсеш юлыннан // Казан утлары. 1982. № 5. Б. 28.

[2] Юзиев Н. Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы: 6т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. Б. 503.; Мәрдиева М. «Совет әдәбияты» журналында... // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 50.

гына матбугат йортының котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле Матбугат йорты ягылмый иде.

Менә без – А. Гомәр белән икәү – «Совет әдәбияты»ның чираттагы санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый, салкын үзәккә үтә һәм без урамны әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда, урамда җылырак шикелле тоела безгә...»[1]. Журналның редколлегия әгъзалары рәтендә шулай ук Т. Гыйззәт, Ш. Камал, Г. Бәширов, Х. Хәйри, Т. Имаметдиновлар була.

Бөек Ватан сугышы башлангач, яшь сәркатипкә эшен гаять авыр шартларда – Мәскәүдән эвакуацияләнеп килгән һәм Тукай клубына урнашкан зур стажлы язучыларны учетка алудан, аларны гомуми эшкә тартудан башлап җибәрергә туры килә. Алар арасында танылган әдип А. Толстой да була. Яшь сәркатип авыр хәлдә калган рус һәм чит ил әдипләренә ярдәм кулын суза.

1943 елның октябрендә, башка эшләрдән бушатмыйча гына, Г. Кашшафны Татарстан Язучылар Союзының җитәкчесе итеп сайлыйлар. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан Язучылар Союзының партоешма сәркатибенә һәм җитәкчесенә, «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторына фронтовик әдипләр, журнал һәм яңа чыккан китапларны гына түгел, гаиләләренә ярдәм сорап та, рәхмәтләр әйтеп тә хатлар язганнар. «Бу хатлардан да Г. Кашшафның гаять кешелекле сыйфатлары ачыла. Әгәр М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, И. Гази, Ш. Маннур, А. Шамов, Н. Баян, Г. Әпсәләмов, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗиев һ.б. язучыларның аның белән язышкан хатлары барысы бергә җыеп бастырылса, сугыш елларындагы әдәби хәрәкәт шактый тулы ачылыр, Г. Кашшафның әдәби хәрәкәтне оештырудагы роле тагын да ачыграк күренер иде», – дип яза Н. Юзиев[2]. Шул ук вакытта, ул публицистика өлкәсендә уңышлы эшләп килә, хикәя, очерклар яза. Нигездә, аларда сугыш һәм тыл батырлары сурәтләнә. 1943 елның гыйнвар башында Г. Кашшаф,

---

[1] Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. Б. 154.

[2] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 130.

К. Нәҗми, Х. Ярми белән берлектә, фронтовик татарларга сәлам хатын язуда катнаша.

Ул еллардагы эшнең иң кыены – журналны вакытында чыгарып бару була. Тирә-күрше автономияле республикаларда әдәби журналлар чыгудан туктаган бер вакытта, «Совет әдәбияты» яшәвен дәвам итә. Кәгазь кытлыгы, типографиянең куәте җитмәү еш кына эшне тоткарлый. 1943 елның җәендә типографиядә журналның 7 саны чыга алмый ята. Кая гына мөрәҗәгать итми Г. Кашшаф. Ярдәм Александр Фадеевтан килә. Дустының гозеренә колак салып, ул татар әдәбиятының хәлен карауны СССР Язучылары берлегенең президиумына куя. Докладчы Г. Кашшаф президиум әгъзаларында: «Татар язучылары үзләренең әсәрләре белән совет әдәбияты үсешенә зур өлеш кертәләр», – дигән фикер тудыра алган. Күренекле әдәбият белгече П. Скосырев әлеге чыгышны яклап һәм хуплап чыга.

Аннары татар язучыларын ВКП(б) Үзәк комитетына чакырып алалар. Г.Кашшаф анда К. Нәҗми, Т. Гыйззәт белән бергә бара. Татарстан язучыларының тормышы, эшләре турында, язучылар һәм республика көчләре белән генә хәл итеп булмый торган кыенлыклар хакында сөйли. «Үзәк Комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар. Авырлык белән булса да, журналны туктатмыйча чыгарып килүне мактадылар.

– Бу – сезнең подвиг! – диделәр.

Бу мактауны без партиянең Татарстан өлкә комитетының һәм журналда актив катнашучы барлык язучыларның казанышы дип кабул иттек.

Ул чакта журнал өч мең данә басыла иде, бу тираж аның лимиты. Үзәк Комитетта мәсьәләне ачыклагач, безгә сизелерлек ярдәм күрсәттеләр. Үзәк комитет журналның тиражын ун меңгә (өч тапкыр артык!) җиткерергә һәм бастыру өчен үз фондыннан өстәмә рәвештә кәгазь җибәрергә булды», – дип искә ала мөхәррир[1].

Журналның йөзен билгеләргә заман үзе булыша. Бөек Ватан сугышы елларында журналда «Фронттан килгән шигырьләр», «Ватан сугышы эпизодлары», «Ватан сугышы кырларында», «Ватан

---

[1] Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. Б. 155.

сугышы язмалары», «Советлар Союзы Геройлары» рубрикалары ачыла. Журнал сугышның алгы сызыгыннан, хәрби вакыйгаларның кайнар эзләреннән йөрәк ялкыны белән язылган шигырьләр һәм сугышчыларның батырлык үрнәкләрен гәүдәләндергән хикәя-очерклар, шагыйрь-язучыларыбызның уй-хисләрен, хатирәләрен сеңдергән язмалары белән баетыла.

Журналның ул еллардагы саннары канлы көрәш кырларында: хәрәкәттәге армиядә, партизаннар сафында, фронт газеталарында каләм һәм автомат белән батырларча көрәшкән язучы һәм шагыйрьләребез – М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, А. Алиш, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, Г. Бакиров, Г. Галиев, Р. Ишморат, Х. Госман, М. Садри, Ә. Маликов, З. Нури һәм башкаларның иҗатлары тупланмасы һәм дәһшәтле көннәр елъязмасы буларак аеруча кадер-хөрмәт уята. Белоруссия җирләрендә атаклы партизан отрядларында сугышкан Җәүдәт Хәбибуллинның «Белоруссия урманнарында» (1943, № 5 – 7) һәм «Партизан хикәяләре» (1943, № 9 – 10) әсәрләре, «Сугышчы блокнотыннан» рубрикасы белән бирелгән язмалар журналны чыгаруда сугышчыларның үзләре дә катнашканлыгы турында сөйли.

«Совет әдәбияты» очерк жанрына аеруча киң урын бирә. Очерклардагы публицистик пафос конкрет документаль фактлар белән ныгытыла бара, аларның тәэсир итү көче тагын да үсә. Сугыш барышын яктырткан материаллар – фронт һәм тыл батырлыкларын сурәтләгән очерклар алгы урында торалар. Ул чакта ил башлыгы карарларын бастыру да әдәби журнал өчен табигый булып саналган: «Чөнки аларга Совет Армиясенең сугыштагы җиңү адымнарын теркәп баручы тарихи документлар итеп карала иде»[1]. Шулардан соң гына эчтәлектә шигырьләр, хикәяләр, пьесалар теркәлгән. Журналда төп рубрикалардан “Ватан сугышы кырларында”, “Сәнгать”, “Театр”, “Публицистика”, “Тәнкыйть-библиография” кебекләрне атап китәргә була. «Совет әдәбияты» укучыларны Марк Твен, Э. Золя, И. Крылов, В. Кожевников һ.б. әдипләрнең иҗат җимешләре белән дә таныштырып бара. Вакый-

[1] Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. Б. 155.

галарга кагылышлы әдәби календарь белән хроника бүлекләре – мөхәррирлек эшенең зур күрсәткече.

1945 – 1947 елларда Г. Кашшаф Татарстан Язучылар Союзында референт-консультант була. Сугыш беткән елда, тәнкыйтьче каты авырып китү сәбәпле, «Совет әдәбияты» журналының мөхәррирлек эшенә Г. Иделле алынган була. Аңардан соң редактор вазыйфасын бер-бер артлы К.Нәҗми, А.Шамов башкара. Менә, мәсәлән, А. Гомәрнең 1947 елда басылып чыккан саннарны карап чыкканнан соң туган теләге: «Совет әдәбияты» журналы редколлегиясе журнални бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп чыгару турында бик нык уйланырга, үзенең эшен яңача үзгәртеп оештырырга тиеш»[1]. Кызганычка каршы, нәтиҗә генә күренми. «Мин яңадан редактор булып килгәндә, элекке сотрудниклардан берсе дә калмаган, редакция таркау хәлдә иде. Афзал абый профессиональ язучылык эшенә күчкән, журналның җаваплы секретаре Габдрахман Әпсәләмов шул ук максат белән редакция өстәлен калдырган, поэзия бүлеген җитәкләүче Сибгат Хәким дә иптәшләреннән аерылырга теләмәгән. 1950 елның 3 маенда, редактор буларак эшкә килгәч, мин буш бүлмәләрдән һәм укылмаган хатлардан башка берни дә, беркемне дә күрмәдем»[2], – дип, яза Г. Кашшаф. Әлбәттә, авыр сугыш елларында журналның йөзен саклап калган, аның тиражын арттыру дәрәҗәсенә җиткергән мөхәррир өчен бу мәсьәләне чишү җиңел булмый. Журналның штатында бары тик мөхәррир һәм сәркатип өчен генә урыннар барлыгы ачыклана. Г. Кашшаф яңадан Үзәк комитет ярдәме белән «Совет әдәбияты»ның язмышын җанландырып җибәрә. Һәрбер бүлеккә үз мөдире – мөхәррире билгеләнә. Ярдәмгә килгән яшьләр арасында Б. Гыйззәтуллин, Г. Ахунов, Р. Башкуров, Н. Юзиев, Х. Курбатовлар да була.

«Совет әдәбияты» журналында мөхәррирлек эшен Г. Кашшаф 1958 елга кадәр дәвам итә. Бу юлы журналдан китү сәбәбе сәяси-иҗтимагый вакыйгаларга барып тоташа. «Совет әдәбияты» журналы

---

[1] Гомәр А. «Совет әдәбияты» журналының соңгы саннары турында // Кызыл Татарстан. 1948. 27 гыйнвар.

[2] Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. Б. 158.

редколлегиясе тарафыннан ясалган хаталар турында Татарстан партия өлкә комитеты 1958 елның 25 февралендә шундый карар чыгара: «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 12 санында Ә. Нәҗипнең «Татар әдәбиятының һәм әдәби теленең кайбер онытылган язма истәлекләре турында» мәкаләсе буржуаз объективизм рухы белән сугарылган. Анда фәнни авторитет буларак буржуаз националист, Советлар Союзының кан дошманы эмигрант Зәки Вәлиди исеме популярлаштырыла. Журналның редакторы Г. Кашшаф партия органнары тарафыннан ясалган берничә кат искәртүдән һәм тәнкыйтьтән тиешле нәтиҗә чыгара алмады, журналның идея-теоретик һәм әдәби дәрәҗәсен күтәрү өчен чаралар күрми. Шуңа күрә КПССның Обком бюросы түбәндәге карарны чыгара:

1) ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең тәкъдимен кабул итеп, журналның җитәкчелек эшен тиешле дәрәҗәдә башкармаганы өчен иптәш Г. Кашшафны «Совет әдәбияты» журналының редакторы вазифасыннан азат итәргә»[1]. (Әлеге документ Татарстан Республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивында саклана. Карарны 2011 елда “Гасырлар авызы” журналы бастырып чыгара).

Г. Кашшаф – «Совет әдәбияты» журналында озак эшләгән мөхәррирләрнең берсе. Илленче елларда журналда шулай ук И. Гази, С. Хәким, Н. Юзиев, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, А. Гомәров һ.б. хезмәт итә. Бу елларда басылып чыккан «Совет әдәбияты», сугыш елларында басылган саннарга караганда, шактый үзгәрешләр кичерә дип әйтеп булмый. Нигездә журналның бит саны бераз артса да, эчтәлектә шул ук рубрикалар саклана. Г. Кашшафка – «Совет әдәбияты» һәм, гомумән, шушы вакытта чыккан күп кенә китапларның мөхәрриренә бу хакта күп кенә шелтәләр ишетергә туры килә. Кызганыч ки, Бөек Ватан сугышы тәмамлануга ничә еллар узса да, татар әдәбиятында сугышта вафат булган язучыларны алыштырырдай яна буын күренми. Мөхәррир шул мәсьәләләр белән дә борчылып яши, иҗатка яшьләрне өнди.

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы редколлегиясе тарафыннан ясалган хаталар турында партия Өлкә комитеты карары. 25 февраль 1958 ел. Татарстан Республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, 15 ф., 6 тасв., 5112 эш, 10 кгз // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2011. № 1/2. Б. 100.

Г. Кашшафның «Совет әдәбияты» журналында алып барган эшчәнлеге бары тик мөхәррирлек эше белән чикләнми. Бер үк вакытта берничә йөкләмәне үзе башкарган шәхес инде олыгаеп барган чорда да эзләнә. Нәтиҗә буларак, очерк жанры теориясенә, аның үсешенә үзеннән өлеш кертә, үзе дә очеркист буларак каләмен чарлый. Берничә әсәре сугыш чорында журналда басылып чыга.

Билгеле булганча, очерк жанры 30 нчы еллардан ук, бишьеллыклар төзелешләрендә тәҗрибә туплап, Бөек Ватан сугышы елларында активлаша. Сугыштан соң ул тагын да тирәнәю һәм эмоциональ ягын көчәйтү юнәлешендә үсә. Г. Кашшаф журналның битләрендә очеркны аерым рубрика рәвешендә дә тәкъдим итә. Соңрак аны татар очеркы теориясенә нигез салучыларның берсе буларак кабул итә башлыйлар.

Шул рәвешле, «Совет әдәбияты» журналының 116 санына кул куеп чыгарган, татар әдәбияты, журналистикасы, матбугаты өлкәсендә эз калдырган Г. Кашшаф эшчәнлеге бүген дә күпләр өчен үрнәк булып тора ала. Татар әдәбиятының гасырга якын үсеш-үзгәрешен, язучы-әдипләребезнең тормышы һәм иҗатын яктырткан саннарга күпме көч, вакыт, түземлек сарыф ителгән. Ул бу журналда 30 елдан артык хезмәт итә.

* * *

Сугыштан соңгы елларда да Г. Кашшаф әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайный, эшчәнлеген төрле тармакта алып бара. Менә аның «Татар әдәбияты тарихы»ның бишенче томында китерелгән көндәлек дәфтәреннән кайбер юллар:

«13 февраль, 1946.

Бу арада бик тыгыз эшләргә туры килде. Язучылар Союзында доклад ясадым, аны бик яраттылар. «Кызыл Татарстан»да бер публицистик хикәя басылды, сайлаулар уңае белән тагын бер мәкалә бастырдым («Халык тантанасы»). Радио өчен Дәрдемәндне язып бирдем. Опера театры өчен «Башмагым»ны рецензияләдем. Я. Агишевның Тукай турындагы очеркын тикшереп бирдем. Менә хәзер Сәйдәшев концерты турында язарга, Г. Әпсәләмовны рецензияләргә, Ф. Кәрим

турында язарга, VII класс өчен хрестоматия, дәреслек төзергә, Тукай юбилеена әзерләнергә кирәк...»[1].

Г. Кашшаф 1947 елдан башлап дәреслекләр төзү эшендә катнаша һәм аларның басмалары 1961 елга кадәр дөнья күрә: Х. Хәйри, Х. Хисмәтуллин, Г. Халитлар белән берлектә 10 нчы сыйныф өчен татар совет әдәбияты, М. Җәләлиева, И. Гомәрова, Ф. Ибраһимова катнашында 8 нче сыйныф өчен татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматия, Ф. Минһаҗева, В. Хаҗиев, М. Мәһдиев, Ф. Миңнуллин белән бергәләп чыгарылган татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматияләр. 1964 елда «Совет мәктәбе» журналы «Әдәбият укытуны – бүгенге көн таләпләренә» дигән сөйләшү, фикер алышу башлап җибәрә һәм шул мәсьәләләргә бәйле филология фәннәре кандидаты Г. Кашшафның мәкаләсен урнаштыра. Озак еллар дәреслек-хрестоматияләр авторы булган тәнкыйтьченең киләчәктә әдәбият укытуга кагылышлы төп таләпләре түбәндәге юлларда бирелә:

1) «Минемчә, VII класстан башлап, әдәбият тарихи принциптан чыгып укытылырга тиеш. Тарихи эзлеклелек кирәк. Һәм язучы турында мөмкин кадәр тулырак белешмә бирергә, аның биографиясен дә истә кала торган художестволы очерк төсендә сөйләргә кирәк. Коры анкета белешмәләре бирүдән туктарга вакыт. Бала язучыны, аның иҗатын, иҗат алымнарын күз алдына китерә алсын, соңыннан да аның турында сөйли алсын, мәктәпне тәмамлап чыккач та, шул язучы аның тормыш юлдашы булып барсын, программага сыймаган әсәрләрен үзе эзләп табып укысын!»;

2) 1947 елдан башлап чыккан басмаларның бүгенге көндә күләмнәре кечерәю һәм шул кыскартулар нәтиҗәсендә дәреслекнең кайбер урыннары коры белешмәгә тартым булып калуы;

3) бер генә дәреслек белән канәгатьләнмичә, бер үк сыйныф өчен параллель икенче дәреслекләр булдыру эшенә керешү;

4) татар теле һәм әдәбияты укыту программаларын тамырдан үзгәртү[1] һ.б.

---

[1] Юзиев Н. Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы. 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. Б. 505.

Шул рәвешле, бүгенге көндә дә дәреслекләр, программалар төзү эшендә килеп чыккан каршылыклар һәм бәхәсләр узган гасырдан ук килә дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкин.

Тәнкыйтьче күп эшли, күп яза. Әйтергә кирәк, Г. Кашшаф аеруча театр белән драматургиягә битараф карый алмый. Әлеге өлкәгә караган мәкаләләре әледән-әле вакытлы матбугат битләрендә басылып килә. 1975 елда (авторның вафатыннан соң) аның әдәби тәнкыйтенә караган аерым язмалары «Күңел көзгесе» дип исемләнгән мәкаләләр җыентыгында дөнья күрә.

Г. Кашшаф драматургиянең үсеше белән генә түгел, проза һәм поэзиянең торышы белән дә якыннан кызыксына. Ул К. Нәҗми, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, И. Гази, М. Әмир, А. Шамов, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин кебек прозаикларның, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ә. Давыдов, Н. Арсланов, Ә. Исхак кебек шагыйрьләрнең яңа китапларына рецензияләр яза, иҗатларын төпле анализлаган мәкаләләр бастыра.

Тәнкыйтьче татар әдәбиятының талантлы язучыларын, күренекле әсәрләрен ил күләмендә пропагандалауга, аның башка әдәбиятлар белән элемтәләрен ныгытуга күп көч куйган, әдипләр белән дуслык бәйләнешләре урнаштырган. Аның А. Фадеев, М. Ауэзов, С. Вургун, Ч. Айтматов, М. Кәрим, С. Кудаш, Ә. Мохтар кебек әдипләр белән шәхси танышлыгы да күп нәрсә турында сөйли. Э. Мильштад, Л. Небенцаль кебек немец язучылары белән ул даими хат язышып торган.

Г. Кашшаф сугыштан соңгы елларда әдәбиятчы-галим буларак та эшчәнлеген активлаштыра һәм әһәмиятле казанышларга ирешә. Тәнкыйтьче аерым язучыларның әдәби портретларын тудыру белән генә чикләнми, татар әдәбиятының, татар журналистикасының үсеш этапларын ачу юнәлешендә дә нәтиҗәле эш алып бара, «Казан утлары» журналының тарихи юлын яктырткан хезмәтләрен бастыра. Икенче яктан, элеккегечә ул әдәбиятта тирән эз калдырган

[1] Кашшаф Г. Әдәбият укытуны − бүгенге көн таләпләренә // Совет мәктәбе. 1964. Б. 32 – 37.

әдипләрнең (Ш. Камал, Г. Камал, М. Галәү һ.б.) иҗатын өйрәнә, аларны әдәбият фәне ирешкән биеклектән бәяли.

Һичшиксез, Г. Кашшаф – үз заманы өчен бик күп хезмәт күрсәткән әдип. Шулай да, тәнкыйтьчене чын мәгънәсендә әдәбият мәйданының түренә бастырган хезмәте – аның М. Җәлилне өйрәнү өлкәсендәге гамәлләре. 1955 елда, М. Җәлил исеме кайтарылуга ике ел узганнан соң, тәнкыйтьче аның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан «Патриот-шагыйрь Муса Җәлил» исемле доклад белән Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты каршындагы Гыйльми совет утырышында катнаша. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүгә багышланган язмалары кандидатлык диссертациясенең нигезен тәшкил итә.

Г. Кашшаф кандидатлык диссертациясен 1960 елда тәмамлый. Шул ук елның 15 декабрендә В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты каршындагы Гыйльми советның чираттагы утырышында Г. Кашшаф филология фәннәре кандидаты исемен алу өчен «Татар совет әдәбияты үсешенең төп этаплары һәм Муса Җәлил иҗаты» дигән темага диссертация яклый. Әлеге тарихи факт «Совет әдәбияты» журналында да яктыртыла: «Рәсми оппонентлар филология фәннәре докторы, профессор Л. Җәләй, филология фәннәре кандидаты, доцент Х. Госман иптәшләр һәм философия фәннәре докторы, профессор М. Абдрахманов, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы мөдире, филология фәннәре кандидаты Г. Халит, яшь галимнәрдән – филология фәннәре кандидатлары Р. Башкуров, Х. Курбатов, драматург Р. Ишморат диссертантның бу хезмәтен һәм гомумән татар әдәби тәнкыйтен үстерүдәге эшчәнлеген югары бәягә лаек дип билгеләделәр. Гыйльми совет Г. Кашшафка бертавыштан филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирү турында карар чыгарды»[1].

[1] Г. Кашшаф – филология фәннәре кандидаты // Совет әдәбияты. 1961. № 1. Б. 178.

Диссертация Гражданнар сугышыннан алып алтмышынчы елларга кадәрге татар әдәбиятын тикшерүне үз эченә ала. Тәнкыйтьче хезмәтен өч өлешкә бүлгән:

1) Татар совет әдәбиятының төп үсеш этаплары һәм юллары;

2) Муса Җәлилнең өчтомлыгын редакцияләүгә кагылышлы материаллар;

3) М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турында монография.

Г. Кашшаф авторефератында үзе искәрткәнчә, диссертациядә беренче бүлекнең төп нигезе – урта мәктәпләр өчен төзелгән «Татар совет әдәбияты» дәреслеге. Калган ике бүлектә Г. Кашшаф әдәбият галиме, тәнкыйтьче, публицист, ә иң мөһиме – М. Җәлилнең тугры дусты буларак чыгыш ясый.

* * *

1948 елның 1 сентябреннән Г. Кашшаф, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләү белән бергә, Казан дәүләт университетында татар совет әдәбияты курсын укытырга керешә. 1961 – 1964 елларда тарих-филология факультетының татар әдәбияты кафедрасында өлкән укытучы, ә 1962 елның октябреннән җитмешенче елларга кадәр яңа ачылган журналистика кафедрасында эшли[1]. Ф. Әгъзәмов лектор Г. Кашшафның эшчәнлеген искә төшереп: «... ул коеп куйган оратор түгел иде. Сабыр-салмак кына, тамагын кырганда аз гына вакытка ял итеп алгандай, бер җайга әдәбиятыбызның үсеш баскычларын барлый, безнең өчен изге булган язучыларның, шагыйрьләрнең тормыш һәм иҗат юлларын шәрехли. Ул аларның һәркайсының диярлек иҗатын фәнни тикшергән, йә иҗатларына, йә аерым әсәрләренә багышланган мәкаләләр язган. Шулар өстенә җанлы әдәби процессның, иҗтимагый тормышның үзәгендә кайнаган. Шуңа күрә дә аның лекцияләре кызыклы фактларга, истәлекләргә, детальләргә искиткеч бай була. Без авыз ачып тыңлыйбыз», – дип яза[2]. Шул ук вакытта,

[1] Отдел кадров Казанского (Приволжского) федерального университета, Дело 145, Опись 12, св. 4.

[2] Әгъзамов Ф. Остаз // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр. 2008. Б. 9–10.

Г. Кашшаф укучыларын уйландыра торган фикерләр, мәсьәләләр күеп, үз фәне белән мавыктыра да алган.

Бүгенге көндә татар журналистикасы тарихында Г. Кашшаф очерк, эссе жанрларын теоретик яктан нигезләүгә һәм үстерүгә зур өлеш кертүче галим буларак билгеле. «Эссены теориягә, – мөстәкыйль жанр итеп күз алдына китереп, исемен дә шулай атап, – беренче Гази Кашшаф кертте», – дип яза И. Низамов[1]. Тәнкыйтьче-галим очерк жанрының хасиятләре турында түбәндәге фикерен җиткерә: «...Татар журналистикасы тарихы очерк жанрыннан башланган... Очерк ул чынбарлыкны, көндәлек вакыйгаларны, замандашларны сәнгатьчә чаралар белән чагылдыручы жанр»[2]. Әлеге билгеләмәне ул М. Горький күзәтүләренә бәйле чыгара: «Аны гадәттә Максим Горькийның төрле вакытта күзәткән төрле сыйфатларына таянып билгелиләр. Әйтик, «очерк» сүзе урысча «чертить», «очерчивать» фигыленнән алынган. Очерк публицистлылык белән «тулы» булса, шул ук вакытта ул «югары сәнгатьлелекне» дә таләп итә. Шуңа күрә дә атаклы язучы, аңа урын – «хикәя белән фәнни хезмәт арасында», дип санаган...»[3].

Әдипнең татар журналистикасына караган эшчәнлеге шулай ук М. Мәрдиева, Ф. Әгъзамов, Р. Нуруллина, И. Фәттахов һ.б. мәкаләләрендә бәяләнә. Р. Нуруллина Г. Кашшафның журналистлык эшчәнлегенә кагылышлы түбәндәге юлларны китерә: «Гази Кашшаф калдырган бай мирасны өч өлешкә бүләргә мөмкин. Аның бер өлешен нәкъ менә журналистика өлкәсендәге эшчәнлеге тәшкил итә. Алай гына да түгел, журналистика аның бөтен хезмәтенең нигезе булып тора. Вакытлы матбугатта турыдан-туры эшләве өстенә ул әдәбият галиме, театр белгече буларак та журна-

[1] Низамов И. Үзебездәниләр бар? // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 142.

[2] Низамов И. Очерк турында кереш сүз // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 1.

[3] Кашшаф Г. Мастерство очеркиста. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1970. С. 6.

листика жанрларын, алымнарын куллана»[1]. Әлеге сүзләр чыннан да Г. Кашшафның күпкырлы эшчәнлеген бергә үреп, аның төрле чараларын үтемле кулланып эш итүе хакында сөйлиләр. И. Низамов Г. Кашшафны «публицистиканың, журналистиканың да эчен-тышын дигәндәй, ягъни үзенең язучылыкта һәм дә бу фәннәрне югары уку йортында укыту тәҗрибәсендә «теше төшкән» галим», – дип исәпли[2]. Язучы Г. Кашшафның публицистик очерклары Бөек Ватан сугышы көннәрендә нәфрәт, үч алу теләге белән сугарылган, соңрак язылганнары илдәге төзелешләр, үзгәрешләрне тасвирлый. И. Фәттахов, үз чиратында, Г. Кашшафның публицистикасында Муса Җәлил образын тикшерә[3].

Г. Кашшафның актив җәмәгать эшчәнлеге һәм күпьяклы нәтиҗәле иҗаты үз заманында югары бәяләнә. Ул 1957 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1967 елда «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнә. Кызганыч ки, патриот-шагыйрьнең җитмеш еллык юбилеена әзерлек юлында иң күп көч куйган әдип бу бәйрәмне күрми. 1975 елның 9 декабрендә Г. Кашшаф якты дөньядан китеп бара. 1976 елда М. Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турындагы тикшеренүләре өчен әдәбиятчы-галим Татарстанның (ул вакытта Татарстан комсомолының) Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек була.

---

[1] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 16.

[2] Низамов И. Үзебездә ниләр бар? // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 142.

[3] Фаттахов И.Ф. Образ Мусы Джалиля в публицистике Гази Кашшафа // Татарская журналистика в XXI в.: векторы развития. Сборник материалов научно-практической конференции, посвящённой 75-летию со дня рождения Флорида Агзамова (Казань, 11 февраля 2011 г.) / под ред. В.З.Гарифуллина; сост. Р.М.Галиева. Казань: Казан. ун-т, 2012. 214 с. С. 84–86; Фаттахов И.Ф. Роль Гази Кашшафа в пропаганде творчества Мусы Джалиля // Фундаментальные и прикладные науки сегодня: материалы II международной научно-практической конференции (19-20 декабря 2013 г., Москва). М.: В 2-х т. Т. 1. 2014. С. 200–204; Фаттахов И.Ф. Муса Джалиль в публицистике Гази Кашшафа // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы X международной научно-практической конференции, 17–19 октября 2013 г. / под ред. Р.П. Баканова. Казань: Казан. ун-т, 2014.

Г. Кашшафка багышланган күп кенә язмаларда бер тенденция чагыла: һәр тикшеренүче йә истәлек авторы аның характерлы үзенчәлекләренә дә тукталырга тырыша, тәнкыйтьченең нәтиҗәле эшчәнлеген нәкъ менә аның шәхси холык сыйфатларына бәйләп карый. «Гази Кашшаф күп язучыларның якын киңәшчесе, якын дусты булды, «алтын» характеры белән күп язучыларның, сәнгать әһелләренең мәхәббәтен, ышанычын казанды. Бергә эшләгән иптәшләре, якыннан белгән дуслары Гази аганы һәрчак тирән хөрмәт белән кешелекле олы шәхес буларак искә алалар», – дип яза Н. Юзиев үзенең «Фидакарьлек» дигән мәкаләсендә[1]. Менә Р. Нуруллинаның «Тугрылык» дигән мәкаләсеннән берничә юл: «Ул сабырлык белән, кешеләргә яхшылык теләп, миһербанлы яшәде. Гази абый бик тыйнак, атылып-бәрелеп гаепләргә ашыкмый, хәтта кайчагында артыграк сабыр, дип тә уйланыла иде. Ләкин менә хәзер аның эшләрен, сүзләрен хәтердән кичергәндә күренә: сабырлык аның үзенә бик җиңел булмаган, башкаларны аяганга күрә, үзен кулда тоткан ул. Әмма кирәк чакта, дәшми мөмкин булмаганда, мәсьәләне хәл итү өчен аның сүзе таләп ителгәндә, ул гадәтенчә салмак кына, ләкин катгый карарга килеп үз фикерен әйтә иде»[2]. Шушы ук мәкаләдә тәнкыйтьченең гаделлек, кешелеклелек кебек сыйфатлары да билгеләп үтелә. Мәкаләнең исеме үк Г. Кашшафның бер ягын атап тора – тугрылык. М. Җәлил белән дуслыгына тугры булып калуы турында бер истәлегендә хезмәттәше К.Н. Куранов та язып чыга[3].

Тугрылык сүзе белән янәшә язмаларда еш кына тагын бер сүз кабатланып килә. Бу – тыйнаклык. Замандашлары үзләре үк тәнкыйтьчегә аның асыл сыйфатларын әйтеп торалар. «Син, дускай, үзең бик әйбәт кенә кеше болай, тик бер җитешмәгән ягың бар – ар-

[1] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 133.

[2] Нуруллина Р. Тугрылык // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 173.

[3] Куранов К.Н. Верность дружбе // Между прошлым и будущим: Сорок лет на Кремлевской: Сборник / Сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 46–48.

тык тыйнак!», – дип төрттерә Ә. Фәйзи[1]. Г. Минский, Г. Кашшаф белән кырык елдан артык булган дуслыгына куанып, әлеге фикерне үзенчә тәмамлап куя: «Гази дус! Алдагы иҗат юлыңны да халкыңа хезмәт итү бәхетен кичереп яшә. Иртәгә дә бүгенгедәй хезмәт сөйгән тыйнак замандашларыбызның берсе бул! Артык тыйнак булуың да зарарсыз. Шундый әйбәт сыйфатның кешедә, аз булуына караганда, артык булуы әйбәтрәк, чөнки тыйнаклык ул кеше күрке, диләр ич»[2].

Язучыларның истәлекләре буенча, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм галимнең башка кызыксыну өлкәләре турында да сүз йөртергә мөмкин. Мисал өчен, М. Хуҗин шахматтан чемпион булган Рәшит Нәҗметдинов белән сеансны тасвирлап бирә. Г. Кашшаф уенда ничья ясый. Язма авторы бу хакта: «... Гази Кашшафның сеанста чемпион белән ничья ясавы гаҗәп тә түгел. Чөнки Гази абый шахматны әйбәт үк уйный иде, аның гаиләсендә дә шахмат хөрмәттә булган – улы, галим Р. Кашафетдиновның университетка укырга кергәнче үк, шахматта беренче разряд алуы моңа дәлил. Тәнкыйтьчебез Гази Кашшаф шахмат уенында теоретик яктан да шактый әзерлекле иде. Рәшит Нәҗметдиновның башлап өйрәнүчеләр өчен «Шахмат уены» исемле татарча китабы (Татарстан китап нәшрияты, 1953) Гази Кашшаф редакциясендә чыкты»[3].

Г. Кашшафның лекторлык вазифасына үзенең истәлегендә М. Галиев туктала: «... мин Гази Кашшафны сагынып искә алам. Ул кәкре башлы таяк тотып, сыңар аягына аксап йөри иде. Сугышта катнашмавын соңыннан белсәм дә, ул минем өчен барыбер фронтовик булып тоела иде... Гази ага җәелеп көлүне өнәмәгән бик җитди кыяфәтле, әмма җитдилеге ачык йөзлелегенә хилафлык китерми иде... Гази ага тавышын күтәрмичә генә, һәр сүзен алдан уйлап сайлый-сайлый, кайбер рус сүзләрендәге кырт киселгән

---

[1] Минский Г. Халыкка хезмәт: Г. Кашшафка 60 яшь // Казан утлары. 1967. № 4. Б. 94.

[2] Шунда ук, Б. 95.

[3] Хуҗин М. Солтанатлы каһарман // М.Х. Хуҗин. Кочасы иде дөньяны... : иҗат тасвирате төсмерләре [төз. Г. Насибуллова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 51-52.

үткен авазларны түгәрәкләндереп, гади җөмләләр белән йомшак кына итеп тамак төбе белән сөйли»[1].

2007 елның унбишенче апрелендә тәнкыйтьче, әдәбият галиме, журналист, педагог, язучы һәм күп кенә башка өлкәләрдә көчен сынаган танылган шәхеснең тууына йөз ел тулды. Бу көннәрдә әдипнең исеме еш телгә алынды – мәктәпләрдә, югары уку йортлары, мәдәни, иҗади, гыйльми оешмаларда аңарга багышлап төрле чаралар үткәрелгән. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: әлеге юбилейга аеруча Казан дәүләт университетының журналистика һәм социология факультеты битараф кала алмады, чөнки биредә Г. Кашшафны университетта журналистика бүлегенә нигез салучыларның берсе итеп таныйлар. Тәнкыйтьче белән бер чорда хезмәт иткән галим һәм укытучыларның истәлекләре Г. Кашшафның факультеттагы абруе хакында искәртәләр. «Гази ага Кашшаф турында дөнья куйган кеше буларак язу кыен миңа. Без, журналистика кафедрасы әгъзалары һәм аның шәкертләре (мин университетның татар бүлегендә укыганда ук аның совет әдәбияты турында лекцияләрен тыңлаган идем), әле дә булса үзебезнең даирәне аңардан башка күз алдына китерә алмыйбыз. Аңа, сәләтле галимгә, аның эшлеклелек, гаделлек, күңел киңлеге һәм юмартлыгы, ярдәм кулы сузарга әзер булу, һәр нәрсәне үз урынына куя белү кебек сыйфатларына үтә дә күнеккән идек. Юк, ул абруе белән түгел – ә аның абруе бик зур иде – басымчаклык итми, ә юл уңаеннан гына әйтелгән зирәк сүзе, акыллы киңәше, барыннан да элек шәхси үрнәге белән безгә ярдәм кулы суза иде. Гази ага гаҗәеп педагогик тактка һәм аралашу культурасына ия иде. Ул төрле телле, төрле яшьтәге, төрле холык-фигыльле кешеләрне берләштергән гаилә башлыгын хәтерләтә иде. Безнең кафедрада аның шәкертенең олы мәхәббәт белән сугарылган портреты тора. С. Карпенко остазының характер сыйфатларын үзенчәлекле һәм оста тотып алган»[2]. Г. Кашшафның яшь язучы һәм тикшеренүчеләргә игътибарлы бу-

---

[1] Галиев М. Без, без, без идек // Догалы еллар. Казан: Татар. газета-журн. нәшр., 1998. Б. 93.

[2] Агзамов Ф.И. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: Сорок лет на Кремлевской: Сборник / Сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 31-32.

луын Р. Мостафин, Г. Ахунов һәм башкаларның язмалары һәм әсәрләре дәлилли ала[1]. Биредә «Төрле телле» һәм «төрле яшьтәге» дигән сүзтезмәләрне куллану чыннан да аклана. Мисал өчен, К. Куранов хәтерендә шагыйрь Сибгат Хәким сөйләгән вакыйганы яңарта: « Гази, мин (Сибгат Хәким – *Л.Б.*) һәм Татарстан Язучылар союзыннан тагын берничә кеше Муса Җәлил юбилеена караган тантаналы чараларны үткәрү өчен Берлинга юл тоттык. Шунда ул Тукай исемен дә атап чыгыш ясый. Алман тәрҗемәчесе өчен әлеге фамилия билгеле бер кыенлыклар тудыра. Шунда Гази Кашшаф, барыбызны да шаккатырып, шагыйрь турында алман телендә үзе аңлатма биреп уза. Шунысы ачыкланды: ничә еллар дәвамында Муса Җәлил турында язышкан кешеләр белән турыдан-туры аралашыр өчен, юлга чыгар алдыннан, ул яшерен рәвештә алман телен үзләштергән. Гази хатлар язарга ярата һәм бу эшкә бик җитди карый иде...»[2].

2007 елдан башлап журналистика факультетының еллык йомгаклау конференциясе дә «Кашшаф укулары» исеме астында үткәрелә. Бу хакта И. Низамов истәлеге игътибарны җәлеп итә: «Моннан биш ел элек – әдипнең тууына 95 ел тулган көндә шәкертләре – беренче чиратта аның белән бергә шушы бүлеккә нигез салып, гомерләрен татар журналистлары укытуга багышлаган Ф. Әгъзәмов, М. Мәрдиева, Р. Нуруллина, шәкертләре һәм иҗатташлары Ш. Рәкыйпов, Р. Мостафин, Ә. Әдиятуллина, М. Шәфыйкова, журналистлар, студентлар белән бергә «түгәрәк өстәл»гә җыелып, аның әдәби мирасын барлау турында сөйләшкәннәр, ел саен университетта Гази Кашшаф укуларын үткәрүне гадәткә кертергә дигән карарга килгәннәр иде. Шуннан бирле факультетта бу чара үткәрелеп килә»[3]. Галимнең йөз еллык юбилее уңаеннан журналистика факультеты галимнәре тырышлыгы белән югары уку йортларының журналистика бүлеге студентлары өчен «Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим» (2008)

---

[1] Ахунов Г. Сайланма әсәрләр. 5 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. V том: Повестьлар. Б. 172.

[2] Куранов К. Верность дружбе // Между прошлым и будущим: Сорок лет на Кремлевской: сборник / сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002 С. 47-48.

[3] Низамов И. Остаз мирасына тугрылык // Мәдәни җомга. 2007. 27 апрель.

дигән «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан уку ярдәмлеге бастырыла. Китапның бер өлешен тәнкыйтьче-галим турындагы истәлекләр тәшкил итә.

Журналистларның йөзьеллык юбилейга багышланган сүзе матбугат битләрендә дә урын алды. «Мәдәни җомга»да Казан дәүләт университеты профессоры И. Низамовның «Остаз мирасына тугрылык», «Казан утлары»нда З. Низаметдиновның «Җәлил дусты Кашшаф», Ф. Җамалетдинованың «Ватаным Татарстан»да «Гази ага безне һаман да укыта» исемле мәкаләләре чын мәгънәсендә остазга хөрмәт һәм соклану хисе белән сугарылган[1]. Журналистлардан кала Г. Кашшафны шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ш. Маннапов та искә ала. Аның «Тугрылык Алиһәсе» исемле мәкаләсе «Мәдәни җомга»да 2007 елда басылып чыккан һәм укучыларны Г. Кашшафның үз вакытында Ш. Маннапов китабына язылган рецензиясе белән таныштыра[2].

Г. Кашшафның тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге турында шактый санда истәлек-хатирәләр язылган, бәяләмәләр бирелгән. Әмма аларның күп өлеше Г. Кашшафны нигездә журналист, педагог, Җәлил фәненә нигез салучы буларак ачып бирәләр, әдипнең шәхси холык сыйфатларына басым ясыйлар. Ә менә аның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге күләгәдәрәк кала сыман. Г. Кашшафның биография материаллары күрсәткәнчә, тәнкыйтьче әдәбият өлкәсенә шактый иртә керә һәм, шул ук вакытта, аның каләме дә тиз чарлана. Эшчәнлегенең башлангыч чорыннан ук ул төрле юнәлешләрне үз итә, үзен һәрьяклап сыный. Хронологик яктан аның татар мәдәнияте өлкәсендә алып барган күпкырлы эшчәнлеге узган гасырның 20 нче елларында башлана һәм 1975 елга кадәр дәвам итә. Киң даирәдә ул тәнкыйтьче, педагог, журналист, мөхәррир, галим, Җәлил фәненә нигез салучы буларак танылып өлгерә.

---

[1] Җамалетдинова Ф. Гази ага безне һаман да укыта // Ватаным Татарстан. 2007. 17 апрель.

[2] Маннапов Ш. Тугрылык Алиһәсе // Мәдәни җомга. 2007. 13 апрель.

## 2. Г. КАШШАФ – ПРОЗАИК

Әдәбият галиме Ю. Тынянов фикеренчә, тәнкыйтьче үзендә галим һәм әдипне берләштерә[1]. Биредә әдип сүзен киң мәгънәдә язучы, иҗат итүче кеше итеп аңларга кирәк. Әлеге карашка тугрылыгын раслагандай, Г. Кашшаф үз каләмен проза өлкәсендә дә сынап карый. Әсәрләре зур күләмле булмаса да, алар совет чорында басылып чыккан, укучыга тәкъдим ителгән.

1934 елда «Совет әдәбияты» журналында Г. Кашшафның «Охранник» исемле хикәясе басылып чыга. Шул ук журналның 1935 елгы берничә санында «Ил чигендә» хикәясе дөнья күрә. Әсәрнең атамасын төгәлләштерү дә бар: «чик саклаучы Й. Ишмөхәммәтов язмаларыннан», диелгән. Билгеле бер вакыт узганнан соң, 1940 һәм 1968 елларда, әлеге хикәя шактый тулыландырылган вариантта укучыга аерым китап буларак барып ирешә. Язучы әсәрнең жанрын повесть дип билгели, китап «Чүл буенда» дигән исем белән чыгарылган. Әлеге әсәр урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен тәкъдим ителгән.

Повесть 1935 – 1937 елларда язылган һәм чик сакчыларының авыр хезмәтен сурәтләүгә багышланган. Биредә моннан күп еллар элек булган вакыйгалар – басмачыларга каршы көрәш, чик сакчыларының иксез-чиксез Кара-Ком сахрасына таралган дошманнарны ничек тар-мар итүләре тасвирлана. Шулай да әсәр гади бер вакыйгаларны сөйләп чыгуга корылмаган. Хикәяләүне Йосыф исемле егет алып бара. Нигездә барлык вакыйгалар да турыдан-туры аның белән бәйле. Повесть егерме бер бүлекчәдән тора һәм аларның һәрберсе төп эчтәлекләренә карап исемләнгән. Вакыйгалар барышы әнә шул бүлекчәләр белән чикләнеп алынган. Мәсәлән, «Мин – солдат» бүлекчәсе Йосыфның уйланулары белән башланып китә: «Яшь егеткә һәрвакыт ике мәсьәлә бик авыр тоела: солдат хезмәтен үтәп чыгу һәм өйләнү. Юк, солдат хезмәте үзе

---

[1] Философия социальных и гуманитарных наук. Учебное пособие для вузов / Под общ. ред. проф. С.А. Лебедева. М.: Академический Проект, 2006. С. 852.

авыр түгел, анысы мактаулы эш, горурлык хисе уята торган изге бурыч. Ә менә шул хезмәтне үтәгәндә, сөйгән кызың кияүгә чыгып куйса...»[1]. Нәкъ шушы юллар бүлекчәнең төп темасын билгели: хәрби хезмәт һәм тугры мәхәббәт. Күтәрелгән төп мәсьәлә – хәрби хезмәткә китүче яшь егетнең сөйгән кызы белән хушлашуы, аңа ышанычы. Укучы, Гайшә белән танышкач, Йосыфны сагынып көтүче барлыгына ышанып, тынычланып кала.

«Клиновский» дип исемләнгән бүлекчәдә геройның берничә тел белүе һәм аларны өйрәнергә сәләте барлыгы ачыклана. Бу мәсьәлә бүген дә заманча яңгырый (хәрби хезмәт кебек үк). Күп телләр белгән кеше төрле юнәлештә үзен сыный, күрсәтә ала. Йосыф, үз чиратында, бу ягы белән командиры Клиновскийның ышанычын казана. Шушы урында китапның 1940 һәм 1968 елда чыккан басмаларындагы эчтәлек аермасы аеруча ачык күренә. Беренче вариантта Клиновский фамилияле начальник Йосыфның төрекмәнчә белү-белмәвен сорый, аңа бер хатны укытып, шул хатны тәрҗемә иттерә. Йосыфның төрекмәнчә, үзбәкчә, фарсыча аз гына булса да аңлаганлыгы ачыклана. Шуның белән бу варианттагы вакыйга тәмамлана. 1968 елгы басмада исә, начальнигы егетнең тагын өстәмә инглиз, гарәп телләрен белүе белән дә кызыксына. Йосыф гарәп телен өйрәнүне, иптәшләре көлгәннән соң, ташлавы турында сөйли. Ягъни аңа иптәшләре: «Комсомолец башың белән корьән хәрефләре укып йөрисе булма...», – дип әйтәләр[2]. Йосыф үзен гаепле итеп тойса да, Клиновский аннан бары көлә генә һәм хәреф белән тел аермасы, тел белү байлык икәне турында җавап кайтара.

Тагын бер кызыклы гына бүлекчә «Ташбака коткарды» дип исемләнә. Шунда ук бу атама укучының игътибарын җәлеп итә, кызыксындыра. Чынлыкта исә, ташбака биредә коткаручы вазифасын башкарса да, үзе үлемгә дучар ителә. Кара-Ком даласында сусауны басар өчен чик сакчылары ташбака канын эчәргә мәҗбүр, шулай итеп алар чүлдә гомерләрен саклап калалар.

[1] Кашшаф Г. Чүл буенда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 3.
[2]Шунда ук. Б. 19.

Нәтиҗә рәвешендә шуны әйтергә мөмкин: һәрбер бүлекчә чик сакчылары тормышының бер күренешен тәшкил итә. Шуңа да күпмедер дәрәҗәдә бу кечкенә генә вакыйгалар искә төшерү мизгелләре кебек күзаллана. Әсәр ахырында исә моның дөреслеккә туры килүенә инанасың. Китапның 1968 елда басылып чыккан вариантында 1967 елда язылган һәм ахырдан урнаштырылган «Автордан» дигән бүлекчә бар. Биредә автор үзе герое белән танышлыгын белдерә: «Әйе, солдат икмәге килешкән сезгә, – дип әйтәсе килде, моннан 35 еллар элек очрашкан Йосыфны хәтерләдем. Ул бит минем хыялыма канат биргән иде, атналар буе таңны каршылаганчы сөйләшеп утыра идек. Бераздан мин повесть язарга керештем. Ул сөйли белмәсә, минем язу тәҗрибәсе чамалы иде, ләкин без язылган һәрбер бүлекне бергәләп тикшерә, кайчак бәхәсләшеп тә китә идек»[1]. Шул рәвешле, шартлы алым кулланып, еллар үтү белән, автор герое белән очраша, аның тормышта ирешкән дәрәҗәләре белән горурлана. Нәтиҗәдә әсәр ике авторлы булып чыга. Берсе – чик сакчысы Йосыф. Икенчесе – автор-хикәяләүче. Әлеге ике автор арасында мөнәсәбәт тә үзенчәлекле. Бу – ике авторның киңәшүе, әсәрне редакцияләве нәтиҗәсендә туган, истәлекләргә корылган бер ядкяр.

Нигездә, эчтәлек ягыннан (бүлек исемнәрендә кайбер үзгәрешләрне исәпләмәгәндә) ике басма да бер. Әмма шулай да 1968 елда чыккан китапта өстәмәләр шактый. Берсе – алда язып үткән тел мәсьәләсенә бәйле: бер-ике урында Гайшә авызыннан Ходаем сүзе ишетелә. Бу инде махсус рәвештә, заман идеологиясенә корылган булса да, татар кызына, гомумән, бу дәвер татар халкына хас булган Аллаһка инануның бер билгесе. Минем уйлавымча, авторның менә шушы бер сүзне генә кертеп җибәрүе дә Г. Кашшафның тормышка, яшәүгә карашы үзгәрүен ачык билгели. Икенчедән, соңгы басмада Гайшәнең хатлары аша Йосыф укучысын М. Җәлилнең, Ф. Кәрим, Һ. Такташ, Г. Кутуйның шигырьләре белән таныштыра. Әсәр икенче бер үзенчәлекле ягы белән дә ачылып китә сыман: совет чорының чик сакчылары

[1] Кашшаф Г. Чүл буенда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 91.

язмышын күрсәтү белән янәшә татар милләтенең бер улы язмышын сурәтләү. Шул ук вакытта татар милләтенә кардәш башкорт егетенең гамәлләре дә Йосыфта горурлык хисләре уята, ул аны якын итә: «Башкортстанның ефәк кебек болыннарын, кояш нурларында коенган кара урманнарын, вак ташлардан сикереп ыргыла торган елгаларын хәтерләтеп, Бикбай «Урал», «Азамат» көйләренә җырлап алды. Мин, аңа күренмәскә тырышып, үземнең «Чабан» исемле туры атымны сөеп, ялларын тарап, алдындагы солысын рәтләгән булып тордым. Үзебезнең Идел буйлары, иртәнге томанда оеп утырган тугайлар күз алдыма килде»[1].

Шулай итеп, Г. Кашшаф 1968 елда «Чүл буенда» повестен үзгәртеп, татар милләтен тасвирлый торган сыйфатларны кертеп җибәргән. Әсәрдә рус сүзләре дә кими төшкән. Автор еллар узганнан соң да бу повесте белән укучысын кабат кызыксындырырга тырышкан.

Совет чорында ил башлыкларын мактап, аларга дан җырлап язылган әсәрләр аз түгел. Әйтергә кирәк, кулга каләм алган һәрбер кеше диярлек аларга үз рәхмәтен җиткерергә тырышкан. Нәтиҗә буларак яңадан-яңа китаплар, мактау әсәрләре барлыкка килгән. 1940 елда татар телендә дөнья күргән шундый җыентыкларның берсе «Ленин-Сталин турында» дип атала. Әлеге җыентыкка төрле жанрдагы әсәрләр тупланган. Китапка рецензияне заманында Г. Кашшаф яза. «Ана шатлыгы» исемле хикәясе белән җыентыкта ул да чыгыш ясый.

Хикәя мавыктыргыч кына башланып китә. Төп герой Нәзирә апа Мәскәүгә килә, аны Бөтенсоюз киңәшмәсенә катнашу өчен чакырганнар. Башкаланың матурлыгына, хозурлыгына сокланып йөргән чакта, Нәзирә апа таныш күзләр, таныш караш белән очраша. Ул аларны метрода барганда ерактан гына шәйләп калса да, көтелмәгән очрашу аның күңелендә ерак истәлекләрне актарып ташлый. Авыр сугыш елларында күрелгән хәлләр бер-бер артлы күңеленнән кичә. Шушы моменттан башлап, автор укучыда Нәзирә апаның шундый зур калада таныш кешесе белән очраша

[1] Кашшаф Г. Чүл буенда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б. 22.

алырмы-юкмы дигән сорау уята. Икенче яктан, озак еллар аерылып яшәгән ана белән бала, күрешсәләр, бер-берсен танырлармы? Очраклы рәвештә Мәүҗүдә исемле танышы Нәзирә апага бу очрашуга мөмкинлек ача. Ана баласын таный, шатлыгы эченә сыймый. Кирам да анасын табуга шатланып туя алмый. Аларның шушы Бөтенсоюз киңәшмәсендә очрашулары автор тарафыннан ил башлыгына дан җырлау булып яңгырый. Янәсе менә шушы куанычлы мизгел – очраклы күрешү өчен ана-бала Сталинга рәхмәтле булырга, аңа дан җырларга тиеш. Ахырга таба әсәр Нәзирә апа белән Кирамның ил башлыгына булган рәхмәт хисләрен кичерүләре белән тулылана. Күмәк фотога төшүне автор: «Анда сөекле Сталин геройлар арасында!..», – дип билгеләп уза[1]. Бу инде вакыйганы тарихи факт буларак теркәү ноктасы. Әлбәттә, кешелек дөньясында төрле хәлләр була, ләкин әлеге күренеш чынлыгы бүгенге укучыны аз ышандырыр.

Г. Кашшафның «Посылка» дип исемләнгән хикәясе 1942 елда «Совет әдәбияты» битләрендә басыла. Ул: «Фрау Хельданың сугыш турында үз фикере юк иде. Фрау ул турыда уйланып та карамады... Аның карты – трубкасы авызыннан төшми торган, саргайган мыеклы Карл Штрассер – сугышка каршы икәнен хатынына ачык әйтеп йөри, ә Хельда алай түгел», – дип башланып китә[2]. Әсәрнең төп вакыйгалары да шушы гаиләгә бәйле.

Фрау Хельда белән Карл Штрассерның ике уллары була. Фриц исемле олы уллары Икенче Бөтендөнья сугышы көннәрендә ата-анасына бер-бер артлы посылкалар җибәреп тора. Ана шат, сугышны ул байлык чыганагы дип кабул итә башлый. Икенче улы Ганс сугышка алынгач кына, ул гаҗәпләнә, уйлана. Аңа да, иренә дә эшкә керергә туры килә. Патрон заводында шартлау булганнан соң исә, Фрау Хельда берничә ай авырып ята. Шушы вакытта ул кабат посылка дип саташа башлый. Гансның йөргән кызы Мария Галас Карл белән килеп сөйләшә, Фрицның үлемен хәбәр итә. Фрау Хельданың хәле арулангач, ул да бу хәбәрне белә. Хәзер ин-

---

[1] Кашшаф Г. Ана шатлыгы // Ленин-Сталин турында. 1940. Б. 46.
[2] Кашшаф Г. Посылка // Совет әдәбияты. 1942. № 3. Б. 24.

де ул үз кулларым белән улымны сугышта һәлак иттем, дип уйлый. Мария Галас китергән посылка, нәтиҗәдә, Фрау Хельданың сугышка нәфрәтен, гаделсезлеккә ачуын күрсәтә. Бу кызга ул каршы булса да, улларының сугыш корбаннарына әйләнүе белән килешә алмый. Ахырда, заводта шартлау оештырып, ул үзе дә дөньядан китеп бара.

Г. Кашшаф бу хикәясе аша берничә мәсьәләне калкытып куярга тели. Бердән, әсәрдә басып алган халыкның да сугыш корбанына әйләнүе күрсәтелә. Ни генә булмасын, сугыш кеше үлеме белән бәйле. Совет халкы фашистларга каршы көрәшә, гади герман халкының да бу көрәшне хупламавы аңлашыла. Хикәя билгеле бер халыкка нәфрәт уяту өчен язылмаган. Нигез итеп биредә сугышка, кан коюга каршы чыгу, протест белдерү алынган. Әлбәттә, күп очракта халык сугыш вакытында хакимият курчакларына әйләнә. Автор әнә шул мәсьәләне калкытып куя алган һәм әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр бары Гитлер Германиясенә генә кагыла, дип әйтә алмыйбыз. Әсәрнең тәэсир көче, уйландырырга этәрүе сизелеп тора. Рус әдәбияты белгече А.Г. Бочарев, сугыш еллары прозасын тикшергәннән соң, мондый нәтиҗәләр ясый: «Совет сугыш еллары прозасы «сугышчан» һәм «сугышка каршы» дигән диалектиканы тирән һәм эзлекле гамәлгә ашыра. Ул сугышның коточкыч, табигый булмаган, тамырдан кешегә дошман күренеш икәнен яшерми; сугыш алып килгән һәлакәтләрнең бөтен фаҗигалелеген күрә торып, ул гаделлек, яшәү, бәхет тантанасы урнаштыру юлындагы көрәшнең күркәм максатларын раслый, шул максатларга ирешү өчен корбан китерүне аңлый»[1]. Г. Кашшафның «Посылка» хикәясендә А.Г. Бочаревның фикерләре аеруча ачык чагылыш таба. Тема бүгенге көн өчен дә бик актуаль.

1943 елда Г. Кашшафның тагын бер китабы басылып чыга. Бу – «Укытучы» дип исемләнгән хикәяләр җыентыгы. Биредә барлыгы биш әсәр тупланган.

---

[1] Современная русская советская литература. Темы. Проблемы. Стиль. В 2 ч. М.: Просвещение, 1987. Ч.2. С. 50.

Җыентыкны «Укытучы» (1942) дип аталган хикәя ачып җибәрә. Автор эпиграфта аны беренче укытучысы “Х. Еникеевка багышлыйм” дип язган. Әсәрнең эчтәлеге дә исеменә чыгарылган геройга барып тоташа. Менә аның кыскача сюжеты.

Кыш көннәренең берсендә Хәбибулла исемле укытучы мәктәпкә килмәгән шәкертенең өенә бара. Гали исемле бу укучының ата-анасы Хәбибулла абзыйны теләмичә генә каршы ала. Малай үзе исә, укытучысыннан качып, икенче бүлмәгә чыгып китә. Хәбибулла абзый ата-ана өчен шактый күңелсез хәбәр җиткерә – улларын караклыкта гаепли. Әмма бу мәсьәләне чишәсе урында, Галинең ата-анасы Хәбибулла абзыйны гаепле итеп калдыралар. «Тәрбияли алмагач, тотынмыйлар аны», – дигән сүзләр белән укытучыны озатып калалар[1]. Хәбибулла абзый үзенең хаклыгын белә, ләкин бай яшәүче, кооперативта эшләүче, балаларын иркәләп үстерүче бу гаиләдә бәхәс кузгатып торуның мәгънәсез бер эш икәнен күрә. Авыр кичерешләр белән ул йорттан чыгып китә, өенә – «... күркәм холыклы булуы өстенә, бик акыллы һәм зирәк...» Хәнифәсе янына кайта. Аңлашып яшәгән Хәбибулла белән Хәнифә бер-берсенең эчке тойгы-кичерешләрен бер күз ташлау белән сизеп алырга өйрәнгәннәр. Хәнифә бу мизгелдә югалып калмый, иренең һәр адымын алдан белә. Автор, әнә шул рәвешле, сүзсез генә ике җанны сөйләштерә. Гарьләнү кичергән Хәбибулла абзый диванда чалкан яткан килеш стенадагы рәсемгә карый һәм үткән тормышын күз алдыннан кичерә. Ретроспекция алымы аша Хәбибулла абзый яшьлек елларына әйләнеп кайта.

Моннан күп еллар элек Хәбибулла исемле егет, семинарияне тәмамлагач, Зирекле исемле караңгы бер авылга укытучы булып килә. Биредә рус-татар мәктәбен ачып җибәрә, балаларны, үзеннән олырак булган абзыйларны укыта. Әмма бер вакытны китаплардан тәре таккан патшалар рәсемен күргән укучылар ярсып, Хәбибулла абзыйны кыйнап ташлыйлар. Икенче елны мәктәпне яндырып китәләр, тагын әллә нәрсәләр эшлиләр. Хәбибулла абзый түзә, моның вакытлы хәл булуына үз-үзен ышандыра. Революциянең

[1] Кашшаф Г. Укытучы. Казан: Татгосиздат, 1943. Б. 12.

беренче елында исә аны кемнәрнеңдер коткысы белән тоталар да көпә-көндез каравыл өенә яптыралар, китапларны яндыралар, укытучыны волостька озаталар. Шул рәвешле, авыл халкына белем алып килүче укытучы Зирекле халкына үпкәләп китеп бара. Яңа шәһәрдә яңа тормыш башланса да, Хәбибулла абзый белән Хәнифә ханымның балалары булмый. Меңләгән балалар укытып та, үз балаң булмау Хәбибулла абзыйның йөрәген әрнетә. Гыйльмановлар да укытучының әнә шул ярасына кагылалар. Кырык елдан артык бергә гомер кичергән укытучы белән Хәнифә ханым ятимә кыз Дина Гутманны тәрбиягә алалар. «Хәбибулла абзый семьясына бала алып тәрбияләү мәсьәләсе бүгенге көннең актуаль хәле булганлыгы өчен генә тагылып куелган. Чөнки Хәбибулла абзый нинди генә яхшы педагог булмасын, үзенең укучыларын тәрбия кылуга зур көч куймасын, аның әле автор безгә күрсәткән шартларда, бала алып үстерү фикерендә йөрүенең хаҗәте юк», – дип фикерле Ә. Камал[1]. Бәлки, совет чорында бер үк теманы күтәреп чыккан әсәрләр арасында аерма-охшашлыклар ачык күренеп торгандыр. Әмма әсәрнең логик нигезендә салынган вакыйга аклана ала. Нәкъ менә шушы ата-ананың каты әйтелгән сүзләре Хәбибулла абзыйны ятим бала тәрбияләү адымына якынлаштыра.

Мәкаләсен дәвам итеп, Ә. Камал түбәндәгечә яза: «Ләкин... ләкин... шуннан соң, безнең күңелләр кайта башлый. Язучының безнең белән шаяра башлавын күрәбез»[2]. Авырып ятучы Марат исемле укучысы янына баргач, Хәбибулла абзый якташларын очрата. Алар Зиреклегә күрше Имәнкүпер авылыннан килгән булып чыгалар. Укучының атасы Гомәр Хәбибулла абзыйны авылдашларының бик хөрмәт итеп искә алуларын сөйли. Хәтта колхозга да аның исемен кушканнар икән. Хәбибулла абзыйның күзләренә яшь килә. «Ул күз яшьләре ачы да, ләззәтле дә иде», – дип тәмамлана хикәя[3].

«Әсәрнең баш өлеше киеренке, бәйнә-бәйнә матурлап күрсәтү юлы белән язылып, соңга таба өзек-өзек, өстән-өстән генә эшләнеп

---

[1] Камал Ә. Укытучы // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 77.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук, Б. 39.

үтелгән бүлекләргә күчеп китә. Әсәргә зур кызыксыну белән керешәсең, соңга таба вакыйгалар шул тикле формаль рәвештә чишелә башлыйлар ки, кызыксыну югала, чөнки аның ничек тәгәлләнәчәге үтәдән-үтә күренеп тора», – ди тәнкыйтьче[1]. Ә. Камал хаклы: әсәрнең башта мавыктырса да, алга таба бүлеп бирелүе аның кыйммәтен төшерә. Киеренкелек җиңел генә хәл ителә. Әлбәттә, әгәр бу чорда язылган әсәрләргә күз салсак, аларның барысында да диярлек каршылыкларны, хакимияткә дошман булган көчләрне җиңеп чыгу белән тәмамлануын күрербез. Г. Кашшафка, бәлки, «Укытучы» хикәясен тулыландырырга кирәк булгандыр. Икенче яктан карасак, бүлекләп бирелгән өлешләр бары тик беренче вакыйгага өзек-өзек җавап бирү рәвешен ала: барысы да яхшы якка чишелә.

Шул рәвешле, вакыйгалар Хәбибулла абзыйның эчке, күңел халәтен сурәтләүгә корылган. Әсәр башында герой өчен туган борчылу хисе ахырда шатлану, куануга әйләнә. Хикәянең сюжеты да, нигездә, вакыйгаларга таянмый, ә бәлки укытучының еллар буе күңелендә сакланып йөргән рәнҗү, үпкәләү хисенең чишелешен тәшкил итә. Ә. Камал хикәянең төп кимчелеге итеп аның аңлату алымына күчүен саный. Дөрестән дә, әсәрнең ахыры вакыйгаларны бер-бер артлы һәм тиз чишүгә корылган. Шул ягы әсәрнең сюжет көчен дә, сәнгати кыйммәтен дә ярлыландыра.

Җыентыктагы икенче хикәя «Һава дуэле» дип исемләнгән. 1941 елның июлендә язылган әлеге әсәр лейтенант Хөсәеневнең сугышта күрсәткән батырлыгын сурәтли. Ул капитан Модестов куйган мәсьәләне чишә, дошманның дүрт самолетын бәреп төшерә. Хөсәенев үзе яралана, самолетын утыртуга, аңын югалта. Ул бары тик полковник Власовның мактау сүзләрен ишетә, иптәшләренең ярдәмен тоя.

Сугышның беренче айларында иҗат ителгән бу хикәя, бер яктан, халыкны тынычлык, ирек өчен көрәшергә, батырларыбыздан үрнәк алырга өндәсә, икенче яктан, гуманистик хисләрне иң алгы планга чыгарып куя. Хөсәенев тә гади кеше кичергән хисләр белән яши.

---

[1] Камал Ә. Укытучы // Совет әдәбияты. 1943.№7. Б. 77.

Аның хатыны Зөһрә, улы Рөстәм бар. Ул һәрвакыт аларны уйлый, сагына, гаиләсе хакына көрәшә, җирдә тынычлык урнаштырырга тырыша, Ватанының киләчәген кайгырта.

«Һава дуэле»ндә җиңеп чыгу сугышта җиңүгә ишарә кебек яңгырый. Бары тик үз көченә ышанган, иле, гаиләсе өчен үз-үзен аямаган батыр гына көрәштә җиңүче булып кала, дигән нәтиҗә чыгарыла. «Автор бу әсәрдә теге яки бу проблеманы ачу принцибын да куеп эш итми, шуңа күрә ул, матур бер эскиз урынын тотып тора», – дип яза Ә. Камал[1].

Алга таба китапны әле 1934 елда язылган «Фазлыев» дигән хикәя дәвам итә. Биредә сугыш батыры түгел, бәлки хезмәт батыры алгы планга чыгарылган.

Фазлыев – мех эшкәртү фабрикасында постта тора, сакчы хезмәтен үти. Аңа иптәшкә фабрикада тагын бер сакчы эшли – Хәйруллин. Әйтергә кирәк, биредә автор-хикәяләүче шул заманның эшчеләр сыйныфына хас булганча, үз эшенә тугры, намус белән караучыларны һәм каракларны, әле «җәмгыятькә ярашмаган» кешеләрне аерып куярга тели. Билгеле инде, сүз идеаль совет җәмгыяте, аның дөреслеккә корылган системасы турында бара. Фазлыев белән Хәйруллинның да карашлары нәкъ менә шушы ноктада кисешә. Әгәр Хәйруллин, җәмгыять инде үсте, анда караклар юк, дип сөйләсә, Фазлыев моның киресен раслый, үзенчә мисаллар китерергә тырыша. Укучы әлегә Хәйруллинның чын йөзен белми кала, ләкин аның кешеләргә шул дәрәҗәдә ышануы һич кенә дә реальлекне чагылдырмый. Алга таба бу сер Фазлыев тарафыннан уңышлы гына чишелә.

Фабриканың лабораториясендә эшләүче Шульц, хезмәткәрләр Гәрәев, Зайцев тиз арада Фазлыев белән дуслык урнаштырырга тели. Аның хәлен белешеп торалар, малаеның туган көненә кыйммәтле бүләкләр алып бирәләр, аны затлы эчемлекләр белән исертергә телиләр. Фазлыев бу «дус»ларга ышанмый, тиешле җиргә барып хәбәр итә. Шул рәвешле, фабрикада күптән инде «кара эшләр» белән шөгыльләнүче җинаятьчел төркем фаш ителә.

---

[1] Камал Ә. Укытучы // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 78 .

Фазлыевның Хәйруллиннан шикләнүе дә дөрес булып чыга. Ул да шул кешеләр белән бәйләнештә торган. Автор төп геройның үз эшенә тугры булуын ассызыклап, башкаларны да шушы юлны сайларга чакыра.

Әсәр чор девизының бер яңгырашы буларак кабул ителә: эшчене, аның намуслы эшен алга чыгара. Ә. Камал әсәрдәге вакыйгаларның үсешенә, чишелешләрнең төгәл бер бөтенлек белән бирелүенә игътибар итә. Шушы яктан аның өчен хикәя «Укытучы» повестеннан өстен тора. Ул хәтта: «Тылыбыздагы предприятиеләрнең бөтенлеген, аның милкен явыз диверсантлардан саклау мәсьәләсе хәзердә дә бик актуаль, шуның белән бергә, сыйнфый сизгерлекне элеккегә караганда да кабатлый төшү үзәк урында тора торган бурычыбыз булып тора. Шуның өчен, бу әсәр Г. Кашшаф иптәшнең иҗатында иң характерлы урынның берсен биләп тора ала»[1], – дигән фикерне алга сөрә. Әмма бүгенге укучы бу бәя белән килешмәс иде. Кеше күңелен, аның кичерешләрен сурәтләгән хикәя – җитештерү өлкәсенә караган, төрле вакыйгаларны барлаган әсәр белән бер сафта тора алмый.

Җыентыкта шулай ук «Москва», «Канга – кан, җанга – җан» дигән әсәрләр урнаштырылган. Алар башка хикәяләрдән күләмнәре, эчтәлекләре белән аерылып тора.

«Москва» әсәре авторның башкала белән бәйле истәлекләрен искә төшерүгә корылган. Менә Кызыл мәйдан, Пушкин, Суворов, Кутузов, Толстой булган урамнар, Мавзолей. Болар барысы да хикәяләүче хәтерендә хисләр шаукымын тудыра, горурлык хисләрен уята. Әсәрне очерк-хатирә дип кабул итәргә мөмкин.

«Канга – кан, җанга – җан» хикәясе исә сугыш темасына әйләнеп кайта: «Мин мәет ашаучылар басып алган җирләрдән качып чыккан намуслы кешеләрнең истәлекләрен укыйм. Фашистлар тырнагыннан котылган кешеләрнең сүзләрен ишетәм. Кызылармеецларның хатлары белән танышам... Минем йөрәгемә кан савыла. Арка тамырлары каталар, көчле нәфрәттән мин бер сүз әйтә

[1] Камал Ә. Укытучы // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 78.

алмый торам...»[1]. Автор фашистларны ерткыч җәнлекләр белән чагыштыра: «Ерткыч җәнлек – балага тими, ә фашист – ярдәмсез бала күрсә, котыруның соңгы чигеннән чыгып, аны газапларга, җәзаларга тотына һәм шул газаплардан ләззәт ала»[2]. Г. Кашшаф дошманның явызлыгын, ерткычлыгын сурәтләп, бер үк вакытта аңа карата нәфрәт хисе уята, аңа каршы күтәрелергә чакыра, сүз ярдәмендә кешеләрне азатлык хакына көрәшкә өнди, күңелләрнең битараф калуын теләми. Әсәр ахырында: «Үч алу өчен, каннарыбызны, җаннарыбызны кайтару өчен канга – кан, җанга – җан!..» – дигән сүзләр белән көрәшкә чакырып кала[3]. Билгеле, Г. Кашшаф үзе фронт вакыйгаларында катнашмый. Шулай да, аның күп кенә язучы-шагыйрьләребез белән сугыш кырыннан хат алышуы, фронтовик татарларга сәлам хатын язуда катнашуы мәгълүм. Шуңа да әлеге хикәя бер өндәү-чакыру, халык күңелендә өметне калкыту кебек яңгырый.

Минемчә, бу соңгы ике әсәрне хикәя жанрына кертеп карау дөреслеккә туры килми. Бердән, алар билгеле бер образлылыкка корылмаган, төп герое, сюжетлары юк, бары тик искә төшерү һәм хатлар уку нәтиҗәсендә туган иҗат җимешләре. Икенчедән, алар публицистик характерда, агитация рәвешендә язылганнар. Берсүзсез, әсәрләрнең эчтәлеге үз чоры өчен заманча, актуаль яңгырый. Андый әсәрләрнең булуы шул вакыт өчен кыйммәтле. Әмма аларның жанрын публицистик язмалар дип билгеләү дөресрәк булыр сыман. «Москва», «Канга – кан, җанга – җан» әсәрләре дә нәсер формасында язылган, авторның эчке тойгыларының дошманга нәфрәт белдергән көчле язмалары булып торалар», – дип яза Ә. Камал[4]. Нәсер формасында иҗат ителгән публицистик язмалар, дип әйтү бу очракта уңышлырак булса кирәк. Әсәрләрдә нәсергә хас кечкенә күләм, эмоциональлек, ритмик төзелеш белән шигъри сөйләмгә якын булу, лирик-патетик ха-

---

[1] Кашшаф Г. Укытучы. Казан: Татгосиздат, 1943. Б. 106.
[2] Шунда ук, Б. 108.
[3]Шунда ук. Б. 111.
[4] Шунда ук. Б. 78.

рактер һәм публицистикага хас хәзерге көн өчен әһәмиятле һәм актуаль иҗтимагый-сәяси вакыйгалар берләштерелгән.

Гомумән алганда, Ә. Камал бу җыентыкны заман укучыларына тиешле җан азыгы бирә алырлык, дип исәпли. Әлбәттә, китапны бары тик совет чоры идеологиясе ноктасыннан тикшерә алабыз. Бүгенге көндә социалистик идеология тәнкыйтьләнсә дә, заманга, яшәү рәвешенә, мохиткә бәя бирү өчен мондый җыентыкларга да әдәбият белгечләре мөрәҗәгать итәргә тиеш.

Г. Кашшафның хикәяләре газета-журнал битләрендә дә үзләренең урыннарын таба. Әдип биографиясен яктырткан бүлектә күрсәтелгәнчә, Г. Кашшафка Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә авырлыклар кичерергә туры килә. Гаделлек өчен көрәшүче тәнкыйтьченең каләме исә шушы шартларда да сынатмый, укучысына хезмәт итә. Нәтиҗәдә аның иҗат җимешләре дөнья күрә.

«Совет әдәбияты»ның 1945 елда басылып чыккан алтынчы санында Г. Кашшафның «Ашыгыч нәтиҗә» исемле хикәясе урын алган. Күләме зур булмаган бу әсәр вакыйгалар саны ягыннан да чикләнгән. Менә Сәлим исемле бер ир-егет вокзалга төшә. Биредә ул фронтта вафат булган дусты Мостафаның Кәримә исемле хатынын каршы алырга ниятли. Әмма Кәримә поезддан төшкән кешеләр арасында күренми. Сәлим аптыраашта кала. Кайчандыр, яшь чагында, үзе, хатыны Хәлимә, Мостафа белән бергә укып йөргән Кәриманең бу эшен ул башына сыйдыра алмый. Чынлыкта исә, Кәримә салкын тидереп авырган була, шуңа күрә дә очрашуга килә алмый кала. Ләкин Сәлим инде Кәримәгә үпкәләгән.

Әсәр шушы урында тәмамлана. Шунысы ачык күренеп тора: автор укучысын уйланырга мәҗбүр итә. Якын дуслар күрешерме, аңлашырмы, ситуациягә ачыклык кертелерме. Икенче яктан, һәр кешенең үз гомерендә моңа охшаш хәлдә калганы бардыр. Аңлашылмаучылык, вакыйганың сәбәпләренә төшенмәү, үпкәчел булу, ашыгыч нәтиҗәләр чыгару – күп кенә тормыш хаталарына китерә. Әйе, алар бер карашка вак кына булып тоелырга да мөмкин. Әмма, без карап үткән мисалдагыча, дуслык җепләре өзелүгә дә китерә ала. Хикәяләүче укучысын сак булырга өнди.

Якыннарны, дусларны, туганнарны ихтирам итәргә чакыра, каршылыклы нәтиҗәләр чыгармаска куша.

Авторның «Әби һәм кияү» хикәясе шул ук елда «Совет әдәбияты»ның унынчы санында чыга. Алдагы әсәрендә Г. Кашшаф килеп туган ситуациядән нәтиҗә файдалы булыр дип күз алдында тотса, киңәш итсә, әлеге хикәясендә «артык» киңәш бирүнең нәрсәгә китерәчәген ачарга тырышкан. Бу мәсьәлә дөньяда һәр кеше өчен кадерле, газиз аналар кайгыртучанлыгы мисалында чишелә.

«Матур аналар бар, төнбоеклы күл өсте кебек, тын аналар бар. Ямьсез аналар да юк түгел. Кыр мәчесе кебек, кырыс, усал аналар да була.

Мәрфуга әби үзен яхшы аналар хисабына кертә иде»[1].

Хикәя шулай башланып китә. Аннан соң без Мәрфуга әбинең кызы Сәгыйдә, оныгы Фәрид барлыгын беләбез. Мәрфуга әби үзен «яхшы аналар» рәтенә кертсә дә, бу хәлнең дөреслегендә шик туа. Бердән, ул Ниса карчыкның ирен «инвалид, аксак» дип йөртсә, сугыш башлангач, Нисага син бәхетле, дип төрттерә. Икенчедән, булдыксызлыкта, малае булмауда гомер буе гаепләп, ире Әхмәдулланың хәтерен калдыра. Әхмәдулла инде вафат. Мәрфуганың бүгенге көн мәшәкате исә – кызын Касыйм исемле бай бер кешегә кияүгә бирү. Билгеле, мондый ана үз теләгенә ирешергә омтыла. Кызы Сәгыйдә исә каршы чыга – ул сугышта хәбәрсез югалган ире Мөхәммәтҗанны көтә, әнисе тапкан кияүдә аның эше юк. Касыйм да анадан ерак китмәгән. Фәридкә бүләкләр ташый, Сәгыйдәне һәрдаим театрга, киногa барырга чакыра. «Килен» генә һаман үзенекендә тора, әнисе сүзен тыңламый. Шулай да ике яклап үгетләүләр юкка китми. Сәгыйдә риза була, ләкин үзе күңеленнән һаман техникумда гашыйк булган укытучысы – Мөхәммәтҗанны чыгарып ташлый алмый. Мәҗлес җыелган көнне исә почтальон почта ящигына Мөхәммәтҗан хатын ташлап китә. Хатта нәрсә язылганы, вакыйгаларның ничек тәмамлануы укучыларга мәгълүм түгел, чөнки әсәр шушы урында өзелеп кала. Исәнме Мөхәммәтҗан, кайтырмы ул, Сәгыйдә хат ту-

[1] Кашшаф Г. Әби һәм кияү // Совет әдәбияты. 1945. № 10. Б. 134.

рында белерме – әлеге һәм башка сораулар җавапсыз кала. Алга таба вакыйгаларның үстерелешен хикәяләүче укучы иркенә калдырган. Әйтергә кирәк, бу авторның осталыгы турында сөйли.

«Ашыгыч нәтиҗә», «Әби һәм кияү» хикәяләре заманында Мәрзия Фәйзуллина тарафыннан кискен тәнкыйтькә очрыйлар. «Совет хатын-кызының героик образын бозып бирүләргә каршы» дигән мәкаләсе: «Ни сәбәптәндер, «Совет әдәбияты» журналы совет хатын-кызларының ролен кимсетә торган чүп-чар әйберләргә үзенең битләрен киң ача. Мин сүзне ике язучыдан – Фатих Хөсни һәм Гази Кәшшафтан башламакчы булам. Бу ике язучының сугыш елларында биргән уңышлы гына әсәрләре булу белән бергә, алар үзләренең кайбер хикәяләрендә хатын-кыз образларын гафу ителмәслек бозып бирделәр», – дип башланып китә[1]. Шуннан соң әсәрләргә күп кенә сылтамалар ясап, мәкалә авторы үз фикерен дәлилләргә тырыша. М. Фәйзуллина фикеренчә, совет хатын-кызлары Октябрь революциясе нәтиҗәсендә моннан 29 – 30 ел элек үк инде ирек алганнар, көчләп кияүгә бирү фактлары совет җирлегендә күптән юк. Шуңа күрә дә ул хикәя авторын хатын-кызларны мыскыл итү, аларны көчсез, ярдәмсез итеп күрсәтергә тырышуда гаепли. «Ашыгыч нәтиҗә»гә карата: «Язучы күпчелек ирләрне хатын-кызга товар күзлегеннән караучы итеп ялган караш уздыра», – дип яза[2]. Бүген әлеге әсәрләрне башка күзаллау аша укыйбыз. Әмма хикәяләрнең эчтәлегеннән аңлашылганча, язучы бары тик очраклы вакыйга-күренешләр аша кешенең сайлау алдында калуын күрсәтә.

«Совет әдәбияты»ның 1946 елгы март ае санында дөнья күргән «Мендәр» хикәясе дә Г. Кашшафның уңышлы гына әсәрләр иҗат итүе турында сөйли.

Автор үзе аны «күңелле хикәя» дип атаган. Чынбарлыктан алып сурәтләнгән ситуация, чыннан да, күңелне күтәреп җибәрә, кешеләрнең гади эш-гамәлләреннән көлдерә.

---

[1] Фәйзуллина М. Совет хатын-кызының героик образын бозып бирүләргә каршы // Кызыл Татарстан. 1947. 7 июнь.

[2] Шунда ук.

Хикәяләү автор исеменнән алып барыла. Вакыйгалар ял йортында сурәтләнә. Хикәяләүче-герой гадәти бер санаторийга килеп эләгә. Барысы да үз тәртибендә барган бер вакытта, хикәяләүче кызык хәлгә тап була. Юкә-Тау ял йортында әйберләрне урламаска сүз биреп, бер кәгазьгә кул куйдырталар икән. Бу хәл авторда көлке уята. Ләкин хәлнең җитдилеген шәфкать туташы аңа кат-кат искәрткәч, сәерсенеп куя: «Сиңа кадәр яткан Хәлиуллин мендәрне чәлеп киткән», – дип сөйли ул[1]. Колак мендәре аркасында туган бу вакыйга санаторий директоры тарафыннан хәл ителә. Ул тегү мастерскоеның директоры булган Хәлиуллинны яңадан ял йортына китерә. Озак кына бәхәс куптарып торганнан соң, Хәлиуллин мендәр тышлыклары, каз йоны сатып алып, санаторийга тапшырып китә. Нәкъ менә шушы вакытта хикәяләүченең дә мендәре югала. Ул туп-туры директор янына керә. Чынлыкта исә, Хәлиуллин китергән мендәр тышлыкларының стандартка туры килү-килмәвен автор мендәрен алып тикшергәннәр икән. Хикәя шуның белән тәмамланыр да иде төсле. Ләкин, алдагы хикәяләрдәге кебек үк, Г. Кашшаф вакыйганың дәвамына ишарә ясый. Автор-хикәяләүче санаторийдан китәргә җыенганда, матрац астыннан инде тактага әйләнеп беткән бер мендәр тартып чыгара. Моны җыештыручы бер апа күреп тора һәм бер дә исе китмәгәндәй: «Шул инде Хәлиуллин мендәре», – дип куя[2].

«Ф. Хөсни, Г. Закиров, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Ә. Ерикәйнең кайбер әсәрләре белән беррәттән, Г. Кашшафның «Мендәр» хикәясен дә «безнең политик таләпчәнлегебезнең кимүе турында, совет әдәбиятының төп интересларын һәм бурычларын онытуыбыз турында сөйлиләр», – дип язып чыга Г. Иделле[3]. Чынында исә тормышта туып торган мондый очраклы күренешләр һәрдаим булып тора, һәм аларны әсәр тукымасына кертеп тасвир итү гыйбрәт өчен башкарыла.

Кешелек җәмгыяте үзе тудырган көлкеле хәлләрне сурәтләгән Г. Кашшафның тагын бер хикәясе 1965 елда «Чаян»да басыла. Ул «Эшләпә» дип исемләнә. Кечкенә күләмле бу әсәрдә салам эшләпә

---

[1] Кашшаф Г. Мендәр // Совет әдәбияты. 1946. № 3. б68.

[2] Шунда ук. 72 б.

[3] Иделле Г. Партия һәм халык таләпләрен большевикларча үтәү өчен! // Кызыл Татарстан. 1946. 22 нояб.

аркылы җәмгыятьтә урнашкан бюрократизм күренешләре күрсәтелә. Хатыны ирен һаман да бер иске эшләпә киеп йөрүендә гаепли. Ә төп геройның тормышында бу кием предметы зур урын алып тора: ул аның инде чәчләре коелып беткән башын кояштан саклый. Ир көн саен диярлек, эшенә барып төрле җыелышлар, киңәшмәләр үткәрә, ә бер көнне, хатыны белән тарткалашып торганнан соң, эшләпә киерлек хәлдә калмау сәбәпле, эшенә ялан баш бара. Ул көнне хикәянең герое үзен бик начар хис итә башлый, авырып китә. Хатыны белән хастаханә буйларында йөрсәләр дә, нәтиҗәсе булмый. Кайда гына бармасыннар – табиб җыелышка киткән. Югарырак торганына барсалар, анысы да үз урынында түгел, киңәшмәдә. Шул рәвешле, төп герой үзенең эшенә читтән бер күз ташларга мөмкинчелек ала. Тик ул үзе өчен моннан да бернинди нәтиҗә чыгармый: шул табиблар җыелышына аны төп профсоюз лидеры, оратор буларак чакыралар һәм ул янәдән шул салам эшләпәсен киеп чыгып китә. Хикәя шулай тәмамлана. Әлбәттә, укучы бу хәлне иске эшләпәне куллану белән чагыштыра ала: кешедәге гадәтләрне бетерү җиңел эш түгел. Хәтта аларның ни дәрәҗәдә зарарлы булуын аңа читтән мисал итеп күрсәтсәң дә, ул үз юлында кала. Бер яктан караганда, Г. Кашшаф бер күренешне ике мисал үрнәгендә күрсәтеп бирә алган. Икенче яктан исә, кешеләрнең ни дәрәҗәдә билгеле бер торгынлыкка ияләшүен калкытып куйган. Тормыш агымына иярү, нәрсәнедер үзгәртү теләге тумау – битарафлыкка илтә торган юл. Һәр кеше бу юлны сайлый икән, көннәрдән бер көнне җәмгыять тә аңа әнә шул ягы белән әйләнеп басачак. Хикәядәге хатын образы гына бу әсәрдә бер кечкенә өмет чаткысы булып сиземләнә.

* * *

Язучының иҗат мирасында очерклар аерым бер урынны алып тора. Бүгенге көн әдәбият белеме сүзлегендә «Очерк – авторның үз күзе белән күргәнне тасвирлап, сөйләп чыгуына корылган эпик жанр. Очерк матур әдәбият һәм публицистика чигендә тора», – дип билгеләнә[1]. Ә менә. А.Н. Николюкин редакциясендә чыккан әдәби

[1] Гайнуллина Г.Р. Очерк // Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 133.

терминнар һәм төшенчәләр энциклопедиясендә аңа киңрәк, шул ук вакытта төгәлрәк аңлатма бирелә: «Автор-«мин»нең оештыручы роле ачык чагылып торган эпик, прозаик жанр»[1]. Шушы ике билгеләмәне истә тотып, татар очеркы теориясенә нигез салучыларның берсе Г. Кашшафның хезмәтенә мөрәҗәгать итик: «...Татар журналистикасы тарихы очерк жанрыннан башланган... Очерк ул чынбарлыкны, көндәлек вакыйгаларны, замандашларны сәнгатьчә чаралар белән чагылдыручы жанр»[2]. Нигездә сүз бер үк мәгънә турында барса да, Г.Кашаффның очеркны журналистика жанры итеп каравын күрәбез. Монда каршылык туа: очеркны эпик төргә кертергәме, әллә журналистика жанры итеп карапгамы? Бүгенге көн журналистикасында әлеге терминны тикшергән И.М. Низамов мондый фикер җиткерә: «Ә менә очеркка, – ул чыннан да очерк булсын өчен, – әдәбилек белән публицистиклыкның үрелүе мотлак зарури, мәҗбүри шарт. Бу – очеркның асыл сыйфаты»[3]. Шушы фикерләргә нигезләнеп, очеркны әдәби һәм публицистик башлангычларны үзендә үреп биргән жанр дип әйтә алабыз.

Әдәбият белемендә очеркларны әдәби, публицистик яисә документаль башлангычның өстенлек алуына карап билгеләү каралган[4]. Әдәби очерклар очерк-мемуар, очерк-биография, очерк-юлъязма, фәлсәфи-лирик очерк кебек композицион төрләргә аерыла. «Совет чорында очерк газета-журналларның даими жанрына әйләнә. Ватан сугышы елларында ул үсеш кичерә»[5]. Сугыштан соңгы елларда да очерк жанры актуальлеген югалтмый. Яңа калкып чыккан шәһәрләрне, зур төзелешләрне, совет кешесенең данлы хезмәт юлын яктырткан әсәрләр әледән-әле вакытлы матбугат-

---

[1] Литературная энциклопедия терминов и понятий / Под ред. А.Н. Николюкина. М.: НПК «Интелвак», 2003. 707 стб.

[2] Кашшаф Г. Очерк в газетах Татарии // Мастерство очеркиста. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1970. С. 6.

[3] Низамов И. Ул «аралыктагы» жанр түгел // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 89.

[4] Литературный энциклопедический словарь / Под общ. ред. В.М. Кожевникова, П.А. Николаева. М.: Сов. энциклопедия, 1987. С. 263.

[5] Гайнуллина Г.Р. Очерк // Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 133.

та үз урынын таба. Г. Кашшаф та очеркларын нәкъ менә шушы елларда иҗат итә.

1943 елда Г. Кашшаф «Совет әдәбияты» журналында «Урман» дип исемләнгән юлъязмаларын бастырып чыгара. Биредә Тәкәнеш урманнары яныннан узып китү вакыйгасы сурәтләнә. Әлеге күренеш Бөек Ватан сугышы көннәрендә бара: «Мин күккә карыйм: нәкъ шушы ачыклыктан гына адашып калган сыек болыт кисәге йөзеп бара. Ул ашыкмый гына көнбатыштан килә һәм бераздан ашъяулык хәтле күләгәсе белән нарат, чыршы очларын, алан чәчәкләрен сыйпап үтә. Кем белә, бәлки ул көнбатыштагы безнең туганнарыбызның сагышлы сәламнәрен сибеп киткәндер. Әнә, йөзгән саен ул сыеклана бара, тоныклана»[1]. Автор туган-үскән җирнең туфрагына, кырларга, юл буенда үсеп утыручы юкәләргә сокланып, сугышка кадәр бу табигать күренешләре белән сокланган авылны күз алдына китерә. «Ибраһим Гази ерак фронттан язган хатында: «Минем өчен дә бер тапкыр Матбугат Йортын әйләнеп чык әле» дип язган иде»[2]. Шул теләкне истә тотып, автор сугыш кырында Ватан даны өчен көрәшүчеләрнең уйтеләкләрен үтәргә тырыша сыман. Нәтиҗә итеп, түбәндәгеләрне яза: «Әйе, авыл – шул ук фронт. Урманы да шулай ук. Әнә, куелык эченнән яшь малайларның көр тавышлары ишетелә, янә яшь кызлар:

Кара да гынай урман,
Караңгы төн –
Яхшы атлар ки-и-рәк үтәргә-ә-ә.., –

дип сузып-сузып җырлыйлар»[3]. Әнә шул рәвешле, Ватан сугышы елларында һәр өлкә җиңүне якынайту өчен үз өлешен кертергә ашыккан. Бу күренеш заман, укучы таләбе булган. Язучы белән уртак хисләрне кичерү, бер үк теләк белән яну халыкның күңеленә җиңеллек өстәгән, чыдап булмый торган шартларда да, өметен өзмәскә, киләчәккә атларга ярдәм иткән.

Г. Кашшафның берничә очеркы Бөек Ватан сугышы көрәшчеләренең батырлыкларын сурәтләп язылган. Аларны без

---

[1] Кашшаф Г. Урман // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 65.
[2]Шунда ук.
[3] Шунда ук. Б. 68.

хаклы рәвештә очерк-биография төренә кертеп карый алабыз. Чынбарлыктан алып сурәтләнгән вакыйгаларны яктырткан әсәрләрне күбрәк публицистик-документаль төргә дә кертеп булыр иде. Ләкин бер каршылык килеп чыга: вакыйга-күренешләр автор тарафыннан сөйләнелә. Әсәр герое «ул» дип бирелә. Ягъни автор үз героеның сөйләгәннәрен укучыга эшкәртеп тәкъдим итә. Бу очракта автор әдәби алымнарга таянып иҗат итә. Билгеле бер дәрәҗәдә очеркларда уйдырма, арттыру-күпертүләр дә булырга мөмкин. Шуңа да без аны очерк-биография итеп әдәбият-сәнгать әсәре буларак тикшерү ягында торабыз.

1944 елда «Совет әдәбияты» һәм шулай ук «Кызыл Татарстан»да Кави Нәҗми белән авторлыкта басылып чыккан «Диңгез батыры» язмышына тукталыйк. Әсәр Советлар Союзы Герое Асаф Абдрахмановка багышланган. Очеркта автор кат-кат геройның Иж-Буби мәктәбен тәмамлавын искәртә. Туып-үскән мохит, туган як табигате, автор фикеренчә, Асафта яшьтән үк Ватанга карата хөрмәт хисләрен уяткан. Бөек Ватан сугышы көннәрендә ул фашистларга каршы сугыша: «Караңгы төннәрдә, дошман уты астында үзенең бронетанкеры белән Керчь ярымутравына унике тапкыр десант төшергән өчен һәм диңгез сугышларында күрсәткән каһарманлыгы өчен Асаф Абдрахмановка Советлар Союзы Герое исеме бирелде»[1]. Тик шунысы кызганыч: фашизмның коллык тырнагыннан котылган Кырым татарлары үз Ватаныннан тиз арада куыла. Бу вакыйгага да, мөгаен, автор битараф калмаган.

Сугыш каһарманына багышланган тагын бер очерк «Василий Яницкий» дип атала. 1945 елда дөнья күргән бу әсәр алдагысыннан шактый күләмле булуы белән аерылып тора. Автор, герое белән Шөгергә килгәч, Иске Куак авылында очрашуга бара. Шул вакытта Василий Яницкий авторны танып ала. Алар мехчылар техникумы аша таныш булып чыгалар. Биредә Г. Кашшафның үз биографиясе китерелүе шик тудырмый. «Минем күз алдына кинәт 1936 елның язгы айлары килеп басты. Әйе, хәтерлим, безнең техникум ул вакыт

[1] Кашшаф Г., Нәҗми К. Диңгез батыры // Кызыл Татарстан. 1944. 30 апрель.

иң яхшы укучы комсомолецлардан алты кешене очучылар мәктәбенә озатты. Алар арасында Василий Яницкий да булган икән. Мин инде, билгеле, аның фамилиясен саклый алмаганмын», – дип аклана автор[1]. Алга таба әсәр геройның тормыш юлын яктырткан иң мөһим фактларны теркәп бара. Аның гаиләсе, уку еллары, очучылыкта беренче адымнары һ.б. Шулай да очеркта төп урынны Бөек Ватан сугышы көннәрендә барган вакыйгалар тәшкил итә. Василий Яницкий ул елларда оста очучы, ышанычлы сугышчы булып өлгерә. Аңа командование дә иң авыр бурычларны тапшыра, ул исә аларны уңышлы үтәп чыга. Шундый заданиеларны үтәгәндә, Яницкий самолеты утына гитлерчылар эләгә, ул фронт сызыгыннан утыз километр ераклыкта янып кала. Василий да һәм аның Казимиров дигән иптәше дә исән калалар. Яңадан үз сугышчылары ягына кайту өчен, аларга ашамый-эчми озак, авыр юл үтәргә туры килә. Исән килеш частька кайтып керүләре дә аларның иптәшләре өчен бер көтелмәгән вакыйга була. Частьта аларны инде күптән үлгән дип санаганнар. Сугышта күрсәткән батырлыгы өчен Василий Яницкийга Герой исеме бирелә.

1950 елларда Г. Кашшаф янә очерк жанрына мөрәҗәгать итеп, юлъязмалар алып бара. Шуларның берсе Мәскәүдәге Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе турында. Совет чорында әлеге тарихи объектка эләгү үзе бер вакыйга булып саналган. Миңа калса, әсәрдәге берничә юл бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый кебек. Алар автор аңында Татарстан павильонын күзәткәннән соң туа: «Культура төзелеше бөтенләй күрсәтелмәгән диярлек. Китап продукциясе дә, әдәбият-сәнгать үсеше анда чагылмый... әйтерсең безнең Тукаебыз да булмаган, Ш. Камал, Г. Камал, М. Гафури һ.б.ларыбыз да иҗат итмәгән, әйтерсең без рус классикларын да тәрҗемә итмибез. Советлар Союзындагы барлык халыкларның горурлыгын үстергән, батырлыгы белән миллионнарны таң калдырган Муса Җәлил дә һич булмаган шикелле! Бу кадәр «тыйнаклык» һәм үз-үзеңне таныrга теләмәү безгә аңлашылмады! Безнең язучылар да

[1] Кашшаф Г. Василий Яницкий // Совет әдәбияты. 1945. № 6. Б. 42–54.

ике бөртек кенә түгел ич!»[1]. Шушы ук очеркта Г. Кашшаф татар артисткаларының татар театрын үстерүдә тиешле дәрәҗәдә бәяләнмәвен искәртеп уза. «Волжская, Болгарская, Богданова, Таждарова, Сыртланова, Синяева, Ильская һ.б. күренекле энтузиастлар революциягә кадәр үк сәхнәгә аяк бастылар. Боларны оныту һич ярамый. Хатын-кызларның демократик хәрәкәткә актив катнашуларын, соңыннан революцион көрәшкә кушылып китүләрен кире кагу дөрес түгел»[2]. Бу сүзләр билгеле бер дәрәҗәдә М. Фәйзуллинаның тәнкыйтенә җавап та булып торадыр.

Совет чорында интернационализм үсү, рус милләтен һәрвакыт бөек итеп күрсәтү алгы планда тора, дип язсалар да, илленче елларда бу хәлнең үзгәрүен күзәтергә мөмкин. Язучы моны «Яңа шәһәрдә» очеркында ачык күрсәтә. Очерк-юлъязма Лениногорск шәһәренә бару вакыйгасына бәйләнешле. Автор һәм аның юлдашлары төзелешләргә, яңа шәһәрнең үсүенә сокланалар. Әмма ахырга таба очеркта язучының борчулы уйлары пәйда була: «Тик безнең икенче нәрсәгә исебез китте. Яңа ачылган алты мәктәпнең берсе дә татар мәктәбе түгел, диделәр безгә. Шуннан соң мин шәһәр халкын күзәтебрәк йөри башладым: урам тулы татар, кайда гына барып керсәң дә татарча сөйләшәләр». Уйлап карыйк: совет чоры, илленче еллар азагы. Автор татар мәктәпләренә игътибар итә. Ярты гасыр узганнан соң да без шул ук мәсьәләләрне кабат күтәрәбез. «Алар инде бөек рус культурасын ахырынача чөмереп бетергәннәр, күрәсең, ана телендә массага якынаю, ана телендә аларны тәрбияләү безнең эшебез түгел инде ул, дип карыйлар булса кирәк. Алдагы елда тагын берничә яңа мәктәп өлгерер, алары да аның бәлки татарча укытмаслар», – дип тәмамлана очеркның бүлекчәсе[3].

Шул рәвешле, Г. Кашшаф әсәрләрен берникадәр күзәткәннән соң, түбәндәге нәтиҗәләрне чыгарырга мөмкин.

Әдәби әсәрләр күләмнәре ягыннан зур түгел; алар повесть, хикәя һәм очерк жанрларында. Хикәяләр җыентыгына кертелгән

---

[1] Кашшаф Г. Күргәзмәдә // Совет әдәбияты. 1954. № 9. Б. 58.
[2] Шунда ук, Б. 58 – 59.
[3] Кашшаф Г. Яңа шәһәрдә // Совет әдәбияты. 1958. № 1. 5 . 6.

хезмәт арасында публицистик язмалар да бар. Алар, нигездә, чакыру, өндәү, агитация булып яңгырыйлар.

Г. Кашшафның хикәяләре исә үзенә бертөрле. Дөрес, аларда тотрыклы яки мавыктыргыч сюжет булмаска да мөмкин, образлар да тиешле күләмдә ачылып бетмиләр кебек, ләкин шулай да алар яшәргә хаклы. Әлеге кечкенә күләмле әсәрләрдә чынбарлыктан алынган күренешләр шактый җанлы сурәтләнә. Укучы хикәяләрне укып чыккач, уйлана, борчыла. Автор билгеле бер дәрәҗәдә тормыш ваклыкларына күз ачып карарга куша. Нәтиҗәләр чыгару исә һәр кешенең үз иркендә калдырыла. Г. Кашшафның соңгы мәкаләләренең берсе «Журналистлык кайда бетә» (1967) дип исемләнә һәм анда ул публицист һәм язучылык хезмәтенең тыгыз бәйләнештә торуын дәлилли.

Г. Кашшафның хикәяләре, очерклары, повесте үз заманының басмаларында урын алган, укучы хәтерендә сакланып калган. Чынлыкта авторның шактый әсәрләре тематик яктан, күтәрелгән мәсьәләләренең актуальлеге белән әле бүген дә заманча яңгырый. Кешеләр һаман бер үк мәшәкатьләр белән яши. Шул яктан карaганда, минемчә, тәнкыйтьченең әсәрләре бүгенге укучы өчен дә кызыклы тоелыр иде.

Очеркларга килгәндә, аларның үзенчәлекле булуы, алар арасында очерк-биография, очерк-юлъязма кебек төрләрнең аерылып чыгуы билгеләп үтелде инде. Г. Кашшаф очерклары әдәбият тарихы, гомумән, татар халкы тарихы өчен бүген дә актуальлекләрен югалтмыйлар. Аларда без реаль шәхесләр – Ватан сугышы геройлары, танылган язучыларыбыз белән очрашабыз. Әдипнең татар халкының мәдәниятенә бәйле язылган фикер-карашлары да милләтебезнең бүгенге халәтен бәяләргә, үткәнен аңларга ярдәм итәләр.

# 3. Г. КАШШАФ – ТӘНКЫЙТЬЧЕ

## 3.1. Әдәби тәнкыйть язмалары

Совет чоры татар әдәбиятын өйрәнү – бүгенге көндә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе. Бу өлкәдәге тикшеренүләр, беренче чиратта, заманны аңлау, тарихны белү, коммунистлар партиясе сәясәтенең әдәбиятка йогынтысын күзәтүгә нигезләнергә тиеш. Икенчедән, татар совет әдәбияты тарихы буенча объектив тикшеренүләр алып барганда, әдәби тәнкыйтьче-галимнәрнең эшчәнлеген, фикерләрен, эстетик карашларын, иҗади позицияләрен, әдәби процесста тоткан урынна-рын өйрәнү әһәмияте туа, чөнки шул вакытта гына әдәбияттагы күренешләрне тулырак ачыкларга, билгесез факт-мәгълүматларны гыйльми әйләнешкә кертергә мөмкинлек барлыкка килә.

Совет чоры әдәбияты XX гасыр әдәбиятының зур өлешен тәшкил иткән кебек, ул иң күп фикер-карашларның кисешүе, бәхәсләр чыганагы да булып тора. Соңгы елларда бу дәвер әдәбияты белән кызыксыну аеруча арта бара. Совет заманында исемнәре һәм иҗатлары әдәбияттан сызып ташланган язучы-шагыйрьләрнең әсәрләре кайтарыла, җитмеш елда тупланган бай мирас яңадан өйрәнелә. Әдәби әсәрләр белән беррәттән, совет чо-рын бәяләүдә, аңлауда шул елларның әдәбият белеме, әдәби тәнкыйте дә ярдәм итә. Аеруча соңгысының тарихы татар әдәбиятында өйрәнелмәгән өлкәләр рәтендә калып килә.

«Әдәби тәнкыйть – әдәбият белеменең бер тармагы; әдәби иҗатның әдәби әсәргә чорның гыйльми-нәзари һәм иҗтимагый-сәяси, эстетик-әхлакый нормаларыннан чыгып бәя бирүче, әдәби хәрәкәттәге күренешләрне аңлатучы бер төре»[1]. Әдәби тәнкыйть – әдәбият турындагы әдәбият. Ролан Барт фикеренчә, ул «фән һәм укып кабул итү арасында тора»[2]. Әдәби тәнкыйть матур әдәбият әсәрен

---

[1] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 32.

[2] История русской литературной критики: Учеб. для вузов / Под ред. В.В. Прозорова. М.: Высш. шк., 2002. С. 7.

аңларга һәм аңлатырга тырыша, укучыны иҗат белән очраштыра, текст авторы, башка тәнкыйтьчеләр белән диалогка кертә.

Күренекле әдипләребез Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, Г. Кәрам һ.б. катнашында XX йөз башында татар әдәби тәнкыйте әдәбиятның аерым бер тармагы буларак формалаша. Совет чорында татар әдәби тәнкыйте өлкәсендә Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Халит, Х. Госман, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Н. Гыйззәтуллин, Ф. Мусин, Ф. Хатипов, Р. Мөхәммәдиев һ.б. актив эшчәнлек алып баралар. XX гасыр азагына таба Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Т. Галиуллин, А. Әхмәдуллин һ.б.ларның тәнкыйди хезмәтләре дөнья күрә. Бүгенге көндә XX йөз татар әдәби тәнкыйтен өйрәнүдә Ф. Галимуллин, Э. Галиева, Д. Заһидуллина, Ә. Закирҗанов, Т. Гыйлаҗев һ.б. зур тырышлык куя. Мәсәлән, Т. Гыйлаҗев игътибарын XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтенә юнәлтсә, 1920 – 1930 еллар әдәби хәрәкәтенә карата Ф. Галимуллинның «Табигыйлеккә хилафлык», «Әле без туганчы...» хезмәтләрен, Т. Галиуллинның тәнкыйди мәкаләләрен атап узарга мөмкин. Инде соңрак килеп, утызынчы еллар сәяси вакыйгаларының әдәбиятка тәэсире турында Р. Мостафинның хезмәтләре билгеле. Чит илләрдәге татар әдәбиятын һәм билгеле бер дәрәҗәдә әдәби тәнкыйтен Х. Миңнегулов тикшерә. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар татар әдәби тәнкыйте турында бүгенге көндә язмалар бик аз, булганнары да безнең заман таләпләренә җавап бирми. Әдәбият белеме алдында совет чоры мирасыбызны барлап, өйрәнеп, үсү-үзгәрү үзенчәлекләрен күзәтеп, хәзерге көн укучысын татар әдәби тәнкыйтенең тарихы белән таныштыру бурычы тора, һәм бу юлда беренче адым – совет чорында иҗат иткән аерым каләм әһелләренең әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеген өйрәнеп, хезмәтләрен бәяләү.

«Гомумән, тәнкыйть, бер яктан, аерым әсәрләрне яисә шул чор әдәби процессын оештыруга, аның үсеш-үзгәрешенә ярдәм итсә, икенче яктан, китап укучы белән әдип арасында арадашлык вазифасын башкара, соңгысының сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен аңларга булыша, өченче яктан, эстетик төшенчәләрнең ниге-

зен ачу-аңлату аша әдәби зәвыкны үстерергә ярдәм итә»[1]. 1990 елда басылган әдәбият белеме сүзлегендә, гомуми билгеләмәдән тыш, марксистик һәм совет чоры тәнкыйтенә карата: «Марксистик тәнкыйть әдәби әсәрне социаль, эстетик, эпик күзаллаулардан чыгып карарга омтыла. Әдәби тәнкыйть, әдәби иҗат кебек үк, тормышны танып белү һәм аңа тәэсир итү чарасы булып тора. Совет әдәбияты тәнкыйте художестволы әсәрләрне заманның иң әһәмиятле мәсьәләләре яктылыгында тикшерә һәм бәяли, аларда сурәтләнгән характерларның һәм тормыш күренешләренең ни дәрәҗәдә дөреслеген, язучы файдаланган сәнгатьчә сурәтләү чараларын ачып бирә», – диелгән [2]. Билгеләмәдән күренгәнчә, совет чорында тәнкыйть билгеле бер кысаларда, билгеле бер таләпләргә таянып эш итә. Ул социалистик реализмның әйдәп баручы метод икәнен танудан килә. Әлбәттә, беренче чиратта, бу совет чорындагы сәяси басым астында бара. Хакимият әдәби тәнкыйтьтән әдәби процесс белән җитәкчелек итү коралы ясый.

Әдәби тәнкыйтьнең тарихы турыдан-туры тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләреннән тора. Шулай ук төрле әдәби юнәлешләрнең, карашларның формалашуы, яңа тенденцияләр барлыкка килү дә әдәби тәнкыйтьнең тарихын тәшкил итә. Рус әдәбияты тарихчысы М.М. Голубков әдәби тәнкыйть тарихының эченә әдәби тормышның төрле формаларын да кертеп карарга тәкъдим итә[3]. Шулар арасыннан ул, мәсәлән, Язучылар Союзы турында болай ди: «...нәшриятларны монополияләштергән, тиражларны һәм гонорарларны бүлеп чыгарган, фатир, дача, Иҗат йортлары, ризык заказлары һ.б. матди байлык һәм тормыш шартларын көйләгән, үзенә күрә, әдәби министрлык, көчле дәүләт оешмасы. Шундый күренешләрне өйрәнми торып, иҗатның үзенә карата «тышкы як-

[1] Татар әдәбияты тәнкыйте тарихы. Махсус курс программасы / Төз. доц. Т. Гыйлаҗев. Казан: КДУ нәшр., 1999. Б. 6.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 190.

[3] Голубков М.М. История русской литературной критики ХХ века (1920 – 1990-е годы): учеб. пособие для студ. филол. фак. ун-тов и вузов. М.: Академия, 2008. С. 9.

тан» торган әдәби процесс вакыйгаларын һәм андагы тәнкыйтьнең ролен аңлап булмый. Аларда XX гасыр әдәби процессының «нервы» беленә: әдәбият һәм хакимият; сәясәт һәм иҗат; хөкемдар һәм иҗатчы мөнәсәбәтләре»[1]. Совет системасы вакытында активлашып киткән төрле түгәрәкләр, әдәби җомгалар, кичәләр һ.б. тәнкыйтьнең тарихына кереп калырдай фактларның тууына да зур өлеш кerтkәннәр. Нәкъ шушы чорда әдәби тормышта актив катнашып, бай әдәби-тәнкыйди мирас калдырган тәнкыйтьче, әдәбият галиме, язучы, журналист, педагог, Җәлил фәненә нигез салучы, совет чорында урта мәктәпләр өчен чыгарылган татар әдәбияты дәреслек-хрестоматияләрнең авторы Гази Кашшаф – совет чоры татар мәдәнияте, әдәбияты, әдәби тәнкыйте үсешенә мөһим өлеш керткән шәхесләрнең берсе.

Татар әдәбияты тарихын яктырткан алты томлыкта, тәнкыйтьче иҗат иткән чорны гына аерып чыгарсак, биредә әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият белеменең татар әдәбияты тарихының чорларга бүленеше белән тәңгәл килүен күрәбез. Совет чоры рус әдәби тәнкыйте тарихында[2], 1986 елда М.С. Мәһдиев һәм З.М. Мәҗитов тарафыннан төзелгән татар әдәби тәнкыйте тарихы буенча программада татар совет әдәби тәнкыйте дүрт чорга бүлеп карала:

1. Социалистик реализм методын үзләштерү өчен көрәш чорында татар совет әдәби тәнкыйте (1917 − 1934 еллар);

2. Татар совет әдәби тәнкыйтенең икенче чоры (1935 − 1955 еллар);

3. 50 нче елларның икенче яртысы – 70 нче еллар башында татар совет әдәби тәнкыйте (1956 − 1971 еллар);

4. Татар совет әдәби тәнкыйтенең хәзерге торышы[3].

Әлеге бүленеш, нигездә, соңрак чыккан хезмәтләрдә дә кабатлана[4].

---

[1] Голубков М.М. История русской литературной критики XX века. С. 9–10.

[2] История русской литературно-художественной критики XX века. Казань: Казан. гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина, 2003. С. 3.

[3] Татар әдәби тәнкыйте тарихы. Программа. Казан, 1986.

[4] Татар әдәби тәнкыйте тарихы. Программа / төз. Э.Р. Галиева. Казан, 2003. 40 б.

Күрәбез: бу чорлар, нигездә, илдәге иҗтимагый-сәяси үзгәрешләргә бәйле аерып каралган. Шул ук вакытта, тәнкыйтьнең үз эчендә үсү-үзгәрү, аерым бер үзенчәлекләр барлыкка килү, билгеле бер тенденцияләр туу законнары да бар. Алар әдәби процессны, әдәбият тарихын, аерым тәнкыйтьче-галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнгәннән соң гына билгеләнә ала. Белгәнебезчә, совет чорында татар әдәбиятының алга китеше турыдан-туры аның «дөньяда тиңе булмаган бөек» рус әдәбиятыннан үрнәк алу нигезендә бара. XX гасыр рус әдәби тәнкыйтенең тарихын хәзерге әдәбият белеме казанышларына таянып өйрәнгән М.М. Голубков үзенең хезмәтендә әдәбият тарихы һәм әдәби-тәнкыйди процессларның берлеге турында тезис чыгарып, түбәндәге фикерне яза: «Әдәби үзрефлексиянең үзенчәлекле бер формасы булган тәнкыйть әдәби процесс белән тыгыз бәйләнештә үсә һәм әдәби мохитнең принципиаль яңалыгы тәнкыйди фикер яңалыгын да китереп чыгара»[1]. Ягъни рус әдәби тәнкыйтенең совет чоры тарихы бүленеше турыдан-туры совет әдәбиятының чорларга аерымлануына тәңгәл килә. Татар әдәбиятында әлеге сорауга җавап бирер өчен, совет чоры татар әдәби тәнкыйтен тулысынча өйрәнеп, аның тарихын булдырырга кирәк. Татар әдәби тәнкыйтенең совет заманына караган өлешен чорларга бүлү мәсьәләсе тулысынча чишелмәгән. Шул ук вакытта, әлеге бүленеш эшләнелгән булса да, аерым тәнкыйтьченең иҗаты әлеге классификация белән кисешмәскә мөмкин. Моны бары тик әдәби-тәнкыйди мирасны өйрәнгәннән соң гына әйтергә була. Шуңа да Г. Кашшафның эшчәнлеген өйрәнгәндә аны кабул ителгән бүленеш кысаларына кертеп карауны кире кагарга туры килә.

Тәнкыйтьченең әдәби-тәнкыйди мирасын бәяләүдә тагын бер юл – аның язмаларын жанр ягыннан төркемләп тикшереп чыгу. Ләкин ул чакта күбрәк әнә шул жанрларның асылына, аларның эчтәлегенә игътибар итәргә кирәк булачак. Биредә тикшерену объекты итеп турыдан-туры тәнкыйтьченең язма мирасы алынды. Эшне башкару вакы-

[1] Голубков М.М. История русской литературной критики XX века (1920−1990-е годы): учеб. пособие для студ. филол. фак. ун-тов и вузов. М.: Академия, 2008. С. 15.

тында төрле авырлыклар белән кисешергә туры килде. Бердән, тәнкыйтьче тарафыннан тикшерелгән әсәрләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әлеге әсәрләрнең һәрберсенә карата бүген инде бик күп фикер җиткерелгән булуы мөмкин. Әгәр Г. Кашшаф биргән бәяләмәләрне башка тәнкыйтьчеләрнең язмалары белән чагыштыра башласак, хезмәт, гомумән, аерым әсәрләргә карата тәнкыйди фикерләр, дип исемләнә алыр иде. Икенчедән, тарихи вакыйгаларны истә тоткан очракта, тәнкыйтьченең дә ни дәрәҗәдә совет чорына «җайлашуы» турында сүз йөртү шактый авыр. Чөнки Г. Кашшафның карашлары кискен үзгәрмәсә дә, билгеле бер трансформация кичерәләр. Әлеге моментны аның проза әсәрләреннән үк күзәтергә мөмкин. Биографиясен яктыртканда да бу моментларга күбрәк тукталырга туры килде. Шуңа да, нигездә, Г. Кашшафның нинди юллар белән әсәргә якын килүенә, кайсы язучыларга мөрәҗәгать итүенә, совет чорының аерым этапларына нинди бәяләр биргәненә игътибарны арттырып эш итәбез. Шул ук вакытта тәнкыйтьченең эзләнүләре ни дәрәҗәдә фәннилеккә якын булуын да ачыкларга юл ачыла.

Билгеле булганча, «Әдәби тәнкыйтьне бер үк вакытта тарихка һәм теориягә таянган әдәби анализ принципларын яктырткан фән буларак та, әлеге принциплар нигезендә башкарылган һәм сәнгатилек белән аерылып торган иҗат сыйфатында да карау» яшәп килә[1]. Әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме үзара тыгыз мөнәсәбәттә тора. Бер яктан, әсәрнең анализына таянып, ул турыдан-туры әдәбият белеменә бәйләнгән була. Ләкин шул ук вакытта раслауга корылмаган, субъектив нәтиҗәләргә таянган, әсәрне, нигездә, эмоциональ үзләштерүгә багышлаган эссеистик тәнкыйть тә яшәп килә[2]. В.Е. Хализев «Теория литературы» хезмәтендә шундый юллар китерә: «Берсүзсез, әдәби тәнкыйть тарафыннан тудырылган «зәвык хөкеме», логик нигезе булмаса да, үз хокукларына ия була»[3]. Әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми мирасны өйрәнү барышында әнә шул момент та истә тотылды. «Әдәби үсешнең төп

[1] Әдәби тәнкыйть теориясе: махсус фән программасы / Р.Ф. Харрасова. Казан: КДУ нәшрияте, 2007. Б. 7.

[2] Хализев В.Е. Теория литературы: Учебник. М.: Высш. шк., 2002. С. 154.

[3] Шунда ук.

«үлчәү берәмлеге» булып унъеллык тора», – дип яза В.В. Кожинов[1]. Әлеге хезмәт кысаларында тәнкыйтьченең эшчәнлеге ун еллап каралды. Тикшеренү Г. Кашшаф язмаларының язылу чорына да, билгеле бер дәрәҗәдә якын торган жанрларны берләштереп тә, бер үк язучы-шагыйрьнең иҗатына карата язылган берничә язманы бергә күзәтеп тә алып барылды.

Н. Юзиев Г. Кашшафның кырык елдан артыкка сузылган иҗат һәм җәмәгать эшчәнлеген ике чорга аерып карый. Беренчесе – 1928–1941 елларны, икенчесе Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы дәверне үз эченә ала[2]. Әмма, бу бүленешнең барлыгын тану белән бергә, тәнкыйтьченең иҗатын һәм эшчәнлеген чорларга бүлү мәсьәләсе икенче төрле дә хәл ителә ала. Хезмәт-мәкаләләрне күзәтеп чыкканнан соң, әлеге бүленешкә кабат әйләнеп кайтачакбыз.

Г. Кашшафның әдәби тәнкыйть дөньясына кереп китүе очраклы бер күренеш түгел. Биографиясендә язылганча, ул гел язучылар, шагыйрьләр арасына тартылган, аны зур калалар чакырып торган. Шуңа буйсынып, тәнкыйтьче әдәбиятта үз сүзен әйтә башлый һәм укучыга җиткерә. Вакытлы матбугат битләрендә аның мәкаләләре егерменче елларның ахырында ук күренә башлый. Алар, нигездә, аерым бер әсәрне тикшереп чыгу буларак кабул ителә. Арада аерым әдәби жанрларга карата язылганнары да бар. Тәнкыйтьченең 1928 елда «Авыл яшьләре» журналының 10 нчы санында басылган тәүге мәкаләләреннән берсе «Татарда поэма һәм аның үсү баскычлары» дип исемләнә. Гарәп графикасында басылган бу мәкаләдә яшь тәнкыйтьче сәнгать һәм матур әдәбиятның тууына гомуми бер караш чыгарып, Бухаринның фикерләренә таянып, халык иҗаты, әдәби әсәр туу, әдәбиятта поэма жанрының тарихы турында уйлана. Әмма, мәкалә тирән теоретик эзләнүләргә багышлана, дип әйтә алмыйбыз. Тәнкыйтьченең фикер сөреше биредә ачык чагыла: менә хезмәт кешесе күмәк эш башкара, шул вакытта аның эш коралы билгеле бер тавышлар чыгарып ритм хасил итә, тора-бара бу ритм халык авыз

---

[1] Кожинов В.В. Статьи о современной литературе. М.: Сов. Россия, 1990. С.140.

[2] Юзеев Н. Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. Т.5

иҗаты әсәрләренә нигез итеп алына, шул халык сәнгатеннән язучылык осталыгы аерымлана. Ягъни һәр язучы теге яки бу дәрәҗәдә, автор язганча, халык авыз иҗаты әсәрләреннән үрнәк алып эш итә. Дөньякүләм танылган Гомерның «Илиада» белән «Одиссея»сы да әнә шул күмәк халык иҗатыннан килеп чыкканлыгы турында фикер әйтелә. Әлеге әсәрләрнең, үз чиратында, башка халык әдәбиятларына үтеп керүе, ә Шәрык әдәбияты нигезендә татарларда «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет»ләрнең барлыкка килүе турында җиткерелә. Тәнкыйтьче Әхмәд Уразаев (Кормаши) тарафыннан иҗат ителгән бу әсәрләрнең дә халык авыз иҗаты белән бәйләнешен күрсәтелә. Әлбәттә, мәкалә ниндидер ачышка дәгъва итми. Әмма чорга, әлеге мәкаләне укучы аудиториягә игътибар бирсәк, бу рәвешле, гади хезмәт белән чагыштырып, сәнгать, әдәбият белән таныштыру, автор фикеренчә, уңышлы дип саналган. 30 нчы елларда әдәбиятка, әдәби тәнкыйтькә зур зарар китергән вульгар социологизм карашлары, Г. Кашшаф мәкаләләрендә дә чагылыш таба. Аның тагын бер үрнәген Н. Юзиев Г.Кашафның «Кызыл Татарстан»ның 1930 ел, 11 февралендә «Безнең юл» журналы турында язган рецензиясендә күрә: «...ул Г. Галинең Ф. Әмирханны татар буржуазиясе идеологиясен яктырткан язучы итеп күрсәтүе белән, ТАППның Ш. Маннурны «үлүче сыйныфның моңлы кәккүге» итеп бәяләве белән килешә», – дип язып чыга[1]. ТАПП оешмасының уңай эшчәнлеген Г. Кашшаф 1929 елда «Авыл яшьләре»нең бер санында да яктыртып чыга. Журналда ул Казанда инде менә алты ел дәвамында эшләп килгән ТАППның филиалы, «Яшь язучылар түгәрәге» турында яза. Әлеге түгәрәк, тәнкыйтьче фикеренчә, ике яктан хезмәт итә: бердән, зур аудитория белән түгәрәкнең җыелышларын алып бару әдәбият белән кызыксынучыларны күбәйтә, массаны хәзерге татар әдәбиятына якынайта; икенчедән, массаның хәзерге әдәбиятка карашын өйрәнгәннән соң, яшь язучылар массаның соравына җавап бирә алырлык әдәби җимешләр тудыра[2]. Әлбәттә, укучы белән язучы арасында элемтәләрне ныгыту өчен бу оешма – казаныш. Әмма язучылар гел

[1] Кашшаф Г. Безнең юл // Кызыл Татарстан. 1930. 11 февраль.
[2] Кашшаф Г. Яшь язучылар тирәсендә // Авыл яшьләре. 1929. № 2. Б. 15.

«заказ» буенча, өстән кушканча эш итсәләр, матур әдәбияттан ерак торган әсәрләр ишәер иде.

1933 елда Г. Кашшаф Нур Баянның поэма жанрына караган «Роберт» исемле әсәрен анализлый. Әйтергә кирәк, кыскача гына булса да эчтәлеген сөйләп чыкканнан соң, тәнкыйтьче аның тел ягыннан кимчелекле якларын аерып чыгара, авторның хаталарын күрсәтә. Яшь авторга һәм аның яшьтәшләренә әлеге теләкләр киңәш формасында яңгырый. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче әсәрнең кыйммәтен: «Колхозның бай, күңелле тормышына омтылдырырлык эшләнгән», – дип билгеләре[1]. Әмма ике бала язмышын чагыштырып карау бу очракта уңышлы күренми. Гомумән, дөньяны ак һәм кара, яхшы һәм яман, дип кискен икегә аерып кую тәнкыйтьченең беренче язмаларында еш күзгә ташлана. Һәм бу – заман, чор идеологиясе таләпләренә туры килә.

«Әдәби әсәрләрнең сыйфаты өчен» (1934) дигән мәкаләсендә Г. Кашшаф, берничә язучы-шагыйрьнең әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, алардагы «вак буржуадан калган логикасызлык үрнәкләре»[2], абстракт образлар, стилистик хаталар турында хәбәр итә. Аларны ул К. Нәҗминең «Кояшлы яңгыр», «Үч» әсәрләреннән, Сирин, Х. Туфан шигырьләреннән таба. Тәнкыйтьче фикеренчә, теориянең артта сөйрәлүе сәбәпле андый хаталар яшьләргә – Әсгать Айдарга, Мәхмүд Сөндеклегә дә күчә. Шуңа күрә дә ул матур әдәбиятның телен, образларын тикшерү эшенә ныклап тотынырга чакыра.

Утызынчы елларда әдәби процесста барган вакыйгаларны М.М. Голубков түбәндәге юлларда ачыклый: «...нәкъ менә утызынчы елларда әдәби тормыш эстетик плюрализмнан катгый монологизмга күчә»[3]. Әлеге факт тәнкыйтьчеләрнең эшчәнлегенә дә тәэсир иткән. «Утызынчы елларның икенче яртысында Г. Кашшафның эстетик карашларында сизелерлек үзгәрешләр туа. Ул азрак, әмма төплерәк яза башлый, яңа әдәби әсәрләрне пропагандалаучы булуга караганда,

---

[1] Кашшаф Г. Роберт // Кызыл Татарстан. 1933. 22 декабрь.

[2] Кашшаф Г. Әдәби әсәрләрнең сыйфаты өчен // Кызыл Татарстан. 1934. 14 июнь.

[3] Голубков М.М. История русской литературной критики XX века (1920–1990-е годы). М. Академия, 2008. С. 59.

әдәби хәрәкәтнең мөһим мәсьәләләрен күтәреп, алар турында җәмәгатьчелекне җитди уйланырга этәрүче принципиаль тәнкыйтьче, әдәби әсәрләрне бәяләүдә эстетик зәвыгы нык үскән тикшеренүче буларак таныла»[1]. Н. Юзиевның бу фикере тәнкыйди язмаларның үзләренә мөрәҗәгать иткәннән соң тагын да тулырак ачыла.

Менә, мәсәлән, К. Нәҗминең «Кояшлы яңгыр» әсәре соңрак, 1936 елда, тәнкыйтьче Г. Кашшаф тарафыннан тәфсиллерәк тә тикшерелә. Әлеге бәяләмәне аның «Кави Нәҗминең ике повесте турында» дигән рецензиясеннән күрә алабыз[2]. Дөрес, биредә инде язучы үз иҗат җимешләренең җитешсез якларын шактый төзәткән һәм менә шул яңа вариантларга тәнкыйтьче анализ ясый. «Зәңгәр сукмак» һәм «Кояшлы яңгыр» әсәрләре кайсы яктан кызыксыну уята соң? Г. Кашшафның билгеләве буенча, әсәрләрнең икесе дә күмәкләшү чорының уңышлы үрнәкләре. Алар совет кешесенең формалашу, төрле юллар үтеп дөрес юнәлеш сайлавын күрсәтәләр. Әйтергә кирәк, рецензия күләме, тел-стиле ягыннан шактый камил булуы белән аерыла. Биредә тәнкыйтьче әсәрнең эчтәлеген логик эзлеклелек ягыннан килеп анализлый, һәр вакыйганы тормыш чынбарлыгы белән бәйләп карый. Ике әсәрне чагыштырып, уртак һәм шул ук вакытта аермалы якларын тәфсилләп күрсәтә. Г. Кашшаф геройларның типик булуын ассызыклый. Төп каһарманнарның һәрберсенә тукталып уза. К. Нәҗминең юморы, әдәби алымнары да тәнкыйтьченең бәяләмәсеннән читтә калмаган. Шул рәвешле, әлеге рецензия Г. Кашшафның тәнкыйди эшчәнлегендә бер адымга алга китүен күрсәтеп тора.

1938 елда Х. Хәйри белән берлектә тәнкыйтьче «Тукай әсәрләренең бер томлыгы турында» дигән кыска рецензия бастыра. Исеменнән үк аңлашылганча, ул Тукайның китабы басылып чыгу уңаеннан язылган, нигездә, китапның җитешсез якларын санап чыгуга корылган. Тәнкыйди язманың авторлары фикеренчә, бу басманың кереш өлеше бөек Тукайның иҗатына, исеменә лаек

---

[1] Юзиев Н. Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы: 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. Б. 502.

[2] Кашшаф Г. Кави Нәҗминең ике повесте турында // Совет әдәбияты. 1936. № 6. Б. 82–91.

түгел. Әлеге фикер урынлы фактик хаталар, сәяси-иҗтимагый ялгышлыклар белән дә дәлилләнә. Җыентыктагы әсәрләр сайланышы да тәнкыйтьчеләрне канәгатьләндерми, Г. Тукайның биографиясе китерелмәү дә җитешсезлек булып санала. Шагыйрьнең иҗатына киңрәк планда Г. Кашшаф соңрак мөрәҗәгать итә.

Иҗтимагый тормышта тәнкыйтьченең һәр сүзе, һәр анализы укучылар, әдәбият белгечләре тарафыннан бәяләнә. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче үзе дә яңа әсәрнең уңышына яки кире кагылуына, әдәби авторитетлар барлыкка китерү яисә юкка чыгаруга тәэсир итә ала, әдәби танылу һәм зәвык өчен җавап бирә. Шуңа мисалны Г. Кашшафның С. Хәким иҗатына биргән хәер-фатихасыннан китерә алабыз. Ул яшь шагыйрьнең «Беренче җырлар» (1938) дип исемләнгән китабына рецензиясен бастыра. Тәнкыйтьчене яшь автор күтәргән темалар, тел байлыгы, шигырьләрдәге рифмаларның төгәллеге кызыксындыра. С. Хәкимнең иҗаты формалашу юлында дөрес бара, дип билгели Г. Кашшаф[1]. Шул рәвешле, шагыйрьнең беренче иҗат җимешләре үк каләмен чарлый барган тәнкыйтьче тарафыннан уңай бәяләнә.

С. Хәкимнең иҗатына Г. Кашшаф янә соңрак, 1962 елда әйләнеп кайта. Бу юлы да тәнкыйтьче шагыйрьнең бер томлыгына бәя бирә, тик инде бу зур җыентык шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае белән дөнья күрә. Мәкалә башында ук Г. Кашшаф шагыйрьне совет җәмгыятенең үрнәк вәкиле итеп таныта: «Монда бер нәрсәне әйтергә кирәк: кайда гына булмасын, кайда гына йөрмәсен – ул халык белән бергә була, бергә атлый. Сугыш вакытында ул рядовой солдат белән бергә окоп һәм блиндажларда, авыр походта булды, солдат белән бергә Ватан язмышы, халык язмышы өчен борчылып яшәде. Сугыштан соң да Сибгат Хәким Ватан һәм халык язмышы өчен үзен җаваплы санап яшәвен дәвам иттерә»[2]. 1938 елда язылган мәкаләсенә сылтама бирү рәвешендәрәк, тәнкыйтьче С. Хәким «яшь шагыйрьләр» рәтендә йөрүдән бик тиз туктады, дип язып чы-

[1] Кашшаф Г. Сибгат Хәким шигырьләре турында // Кызыл Татарстан. 1938. 8 сентябрь.

[2] Кашшаф Г. Шагыйрь һәм бүгенге көн // Совет әдәбияты. 1962. № 4. Б. 119.

га. Ягъни шагыйрьгә 30 нчы елларда биргән үз бәяләмәсе белән Г. Кашшаф еллар үткәч тә килешә.

Шагыйрь С. Хәким иҗатында тәнкыйтьчене тема-идеялар, шигырьләре уяткан хис-тойгылар кызыксындыра. Аерым алганда, ул шагыйрьнең иҗат җимешләреннән мәхәббәт, Бөек Ватан сугышы темаларын, сагыну, юксыну, ярату, ачыну, борчылу кебек хисләрне барлый. Мәкаләдә шактый киң планда суд залыннан язылган шигырьләр циклы тикшерелә. Алар аша С. Хәкимнең иҗатында гәүдәләнгән проблемалар калкып чыга: шәхеснең формалашу мәсьәләсе, матурлык һәм үлем проблемасы. Тәнкыйтьче «Суд залыннан» циклына нәтиҗә ясап, мондый җөмлә китерә: «Аларда матур яшәү, бәхетле тормыш кору фәлсәфәсе бирелә, эшчән таза тормыш өчен көрәш идеяләре сурәтләнә, шундый тормышны ул декларатив төстә түгел, риторикасыз сурәтли, кабарынкы сүзләрдән башка йөрәгең белән тоярга һәм шуны расларга мәҗбүр иттерә»[1].

Тәнкыйтьче С. Хәким иҗатының үсешен Бөек Ватан сугышы еллары белән бәйли. Сугыш елларында шагыйрь аз яза, әмма нәкъ менә шушы сугыш вакыйгалары аны дөньяны башкача танып белергә өйрәтә. Сугыштан соң язылган «Курск дугасы», «Дала җыры» кебек поэмаларны исә Г. Кашшаф «шагыйрьнең иҗатында үзенә башка бер нур белән балкыган әсәрләр», – дип билгели[2].

Тәнкыйтьче С. Хәкимнең Ленин, Тукай образларын тудыруга мөрәҗәгать итүен дә читләтеп үтми. Аеруча Тукайга багышланган әсәрләренә туктала. Г. Кашшаф С. Хәкимнең иҗатында бөек шагыйрьнең образы һәрдаим чагылып килүен искәртә. Хәтта турыдан-туры Тукай образы бирелмәсә дә, тәнкыйтьче фикеренчә: «Ул Тукай хисләре, аның борчылулары белән яши һәм һәрбер уңайлы очракта Тукайны җырда сагынуын дәвам иттерә»[3]. Мәкалә С. Хәким иҗаты гыйльми тикшеренүгә лаеклы дип тәмамлана. Куанычлы хәл, бүгенге көндә шагыйрьнең иҗатын һәм иҗат лабо-

---

[1] Кашшаф Г. Шагыйрь һәм бүгенге көн // Совет әдәбияты. 1962. № 4. 123 б.

[2] Шунда ук, Б. 124.

[3] Шунда ук, Б. 126.

раториясен тикшереп язылган берничә диссертация фәнни җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде.

К.Кашшаф, С. Хәким иҗатыннан тыш, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, А. Алишларның да әдәбият йөзендә өметле киләчәген дөрес күрә алган.

Г. Кашшафның тәнкыйди язмалары арасында еш кына аерым бер әдипнең туу яки үлеменә бәйле басылып чыкканнары да аз түгел. Күрәсең, әлеге язмалар аның мөхәррирлек эшенә бәйле мәҗбүри рәвештә дә тугандыр. Шуларның берсе Һ. Такташның үлүенә җиде ел тулу уңае белән 1938 елда «Кызыл Татарстан»да һәм «Азат хатын»да дөнья күрә. Күләме белән әллә ни зур булмаган мәкаләдә тәнкыйтьче шагыйрь иҗатының үсү юлына, юнәлешенә, аерым бер шигырь-поэмаларына тукталып уза. Әдипнең күзәтүе буенча, Такташ иҗатының характерлы якларыннан берсе – аның заман кешесе образын тудырырга омтылуында. Шагыйрь иҗат итү юлында һәрвакыт «адәмнең» иҗтимагый тормышта алган яки алырга тиеш булган урынын билгеләргә тырыша. Һ. Такташ шигырьләрендә кешенең эше, омтылышы, хисе, тойгылары төрле тирәнлектә биреләләр[1]. Чыннан да, бу эзләнүләр чор таләбеннән дә килеп туа дип әйтә алабыз. Илдә барган күмәк хуҗалыклар оештыру, ил милке дигән төшенчәләр кешенең аңына, көнегелгән тормыш рәвешенә тәэсир итә. Кешенең шәхси түгел, ә, бәлки, иҗтимагый вазифалары алга чыга. Инсан төшенчәсе, аның асылы, иҗатта тудырылган шәхес образларына Г. Кашшаф соңрак та әйләнеп кайта. Ягъни гуманизм, кешелеклелек кебек төшенчәләр тәнкыйтьчене һәрвакыт кызыксындырып килә.

Һ. Такташны искә алу белән бәйле тагын бер мәкалә 1941 елда «Киң күңелле патриот» исеме астында басыла. Өч ел элек язылган фикерләр биредә кабатланмый. Мәкаләдә шагыйрьнең иҗаты патриотизм ягыннан ачыла. Бөек Ватан сугышы көннәрендә Һ. Такташ әсәрләренә игътибарны юнәлтеп, тәнкыйтьче ватанпәрвәрлек хисләре уятырга тырышкан. Шагыйрь тудырган образлар да, Г. Кашшаф уйлавынча, үч, нәфрәт белән дошманга каршы

[1] Кашшаф Г. Һади Такташ // Кызыл Татарстан. 1938. 8 декабрь.

күтәреләләр. «Гази Кашшаф иптәшнең Такташ үлүгә 10 ел тулуга карата язган мәкаләсендә: «Аның (Такташның) сүзләре аша табигать үзе сөйли, табигатьнең шаянлыгы сурәтләнә кебек» дигән юллары, чынлап та, аңа бик тә туры килә»[1]. Әлбәттә, мондый мәкаләләр сугыш елларында үз урыннарын алганнар, аларга ихтыяҗ булган. Шулай да һәрнәрсәне ил өчен, сугышка нәфрәт уятыр өчен дип, Бөек Ватан сугышы башланганчы 10 ел элек вафат булган шагыйрьнең көрәш омтылышларына бәйләп карау бик үк урынлы түгел.

Әдәбиятта яшь һәм олы буынны аеру, алар арасындагы мөнәсәбәт, аларның бер-берсенә тәэсире, традицияләрнең дәвамчанлыгы Г. Кашшафны беренче язмаларыннан ук борчып килә. Әнә шуны күздә тотып, ул башлап язучыларга киңәш бирүне урынлы дип саный һәм «Азат хатын» журналы битләрендә «Башлап язучылар иҗатына карата» консультация бирә. Алда карап узган «Татарда поэма һәм аның үсү баскычлары» дигән мәкаләсендәге кебек үк, Г. Кашшаф биредә дә әдәбият теориясенә, әдәбиятка кагылышы булган сорауларны күтәрми. Ул яшь шагыйрьләрнең иҗатына характеристика бирә, җитешсез якларын ассызыклый, гамәли яктан якын килеп эш итә, хаталарны барлый. Г. Кашшаф яшь авторларны шигырь саны артыннан кууда гаепли. Мәкаләдә очраган шагыйрьләрнең исемнәре бүгенге көндә әдәбият тарихчылары өчен дә әллә ни сөйләми: Ә. Юныс, Ә. Камал, Н. Вафин, Г. Латыйп, М. Вәдүт, С. Гыйлемханов, Н. Сәйфуллина һ.б.[2]. Димәк, тәнкыйтьченең бәяләмәсе дә заманында ук хаклы яңгыраган дигән нәтиҗә чыгарыла.

Әдәби консультацияләрнең дәвамы булып, тәнкыйтьче шул ук «Азат хатын» битләрендә «Яшьләрнең хикәяләре турында» (1939) дигән мәкаләсен бастыра. Хикәя жанрының асылын мәкалә авторы мисаллар ярдәмендә аңлатырга тырышкан. Тәнкыйди язманың башлангыч өлеше хикәяне драма һәм шигырьләрдән аеру, үзенчәлекләрен күрсәтүгә корылган. Яшьләрнең хикәя иҗат итүдә

[1] Хөсни Ф. Моннан шагыйрь узды // Ф. Хөсни. Уйланулар (Әдәби осталык мәсьәләләре). – Казан: Татар кит. нәшр., 1961. Б. 20.

[2] Кашшаф Г. Башлап язучылар иҗатына карата // Азат хатын. 1938. № 18. Б. 8–9.

төп хатасы – бер үк тема, сюжетларны кабатлау, вакыйгаларны артык тормышчан яисә, киресенчә, ясалма итеп бирү тора, дип белдерә тәнкыйтьче[1]. Аның фикеренчә, һәр нәрсәдә чаманы белеп эш итү сорала. Яшьләргә үрнәк итеп Ш. Камал новеллалары, Ф. Хөсни хикәяләре китерелә. Г. Кашшаф яшь каләм тибрәтүчеләргә А.П. Чехов, Ги де Мопассан, М. Зощенко әсәрләренә мөрәҗәгать итергә тәкъдим ясый, хикәянең асыл сыйфатларын исә И. Виноградов, Л. Тимофеевларның әдәбият теориясенә караган хезмәтләреннән өйрәнергә куша.

Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди мирасында аерым бер шәхеснең иҗат портретын еш табып була. Әйтик, М. Галинең иҗат юлын яктырткан тәнкыйди-биографик очеркы. Ул язучының әдәби хезмәтенә егерме биш ел тулу уңае белән язылган. Әдипнең биографиясе биредә иҗат эшчәнлеге белән үрелеп бирелә. Аерым әсәрләргә тукталып, тәнкыйтьче аларга гомуми бәясен җиткерә. М. Галинең башлангыч чорда язылган әсәрләрендә сюжет, вакыйгалар йомшаклыгы күзәтелә. Алга таба язучының әсәрдән-әсәргә каләме шактый чарлана баруы күрсәтелә. Тәнкыйтьче фикеренчә, М. Гали сыйнфый көрәшне, тормыш чынбарлыгын дөрес, матур чагылдыра. Аның үз күзе белән күргән вакыйгалары да иҗатында билгеле бер чагылыш таба. Г. Кашшаф язучыны әдәбият тарихында урын алырга хаклы, дип бәяли. Чынлыкта исә, бүгенге көндә М. Гали әсәрләре үз заман иҗат җимешләре булып теркәлеп калганнар. «М. Гали әдәби хезмәте моның белән генә чикләнми. Ул гыйльми эшче буларак татар әдәбиятына, тел-культура тарихына багышланган гыйльми тикшеренүләр алып бара», − дип, әдип язучының әлеге өлкәдәге эшчәнлеген дә яктырта, аерым алганда сүзлекләрне, Тукайның «Кисекбаш» әсәрен, Сәгыйть Рәмиевнең иҗатын өйрәнүен билгеләп уза[2].

Новелла жанрында «үзлекләрен табып, үзләренә хас алымнарда чыныгып үсеп барган язучылар» арасында Г. Кашшаф Ф. Хөснине аерып чыгара. Күп кенә башка язмаларындагы кебек үк, биредә дә

[1] Кашшаф Г. Яшьләрнең хикәяләре турында // Азат хатын. 1939. № 1. Б. 15.
[2] Кашшаф Г. Мөхәммәт Гали // Совет әдәбияты. 1939. № 12. Б. 100.

тәнкыйтьче тикшеренү эшен язучының биографик фактларын теркәүдән, беренче әсәрләренә мөрәҗәгать итүдән башлый. Заман тәнкыйтьчеләренә хас булганча, язманың башында чор, идеология, партиянең төрле карарларына карашлар да төшеп калмый. Алда язып узган ТАПП оешмасына карата булган Г. Кашшафның фикерләре утызынчы еллар ахырында үзгәрешләр кичерә. Аларны без түбәндәге юлларда ачык сиземли алабыз: «РАПП, ТАПП җитәкчелегендәге тупас хаталар, матур әдәбиятка карата булган зарарлы политика партия һәм совет язучылары тарафыннан тикшерелә башлады һәм шул хаталарны төзәтү өчен күп чаралар күрелде. Чыннан да, РАПП җитәкчелегенең сәнгатьнең, художество сүзенең көчен юкка чыгару политикасы әдәбият, сәнгать өлкәсендә күп кенә зарар иткән иде»[1]. Әмма шушы ук мәкаләдә тәнкыйтьченең революциягә кадәр татар әдәбияты тарихы белән кызыксынуын да сиземли алабыз. «Буржуа идеологиясенә ятышлы» кечкенә хикәяләр иҗат итүчеләр арасында ул Ф. Әмирхан, Г. Газиз, Г. Рәхим кебек шәхесләрне аерып чыгара. Һәм совет чорында шушы жанрдагы әсәрләр язуның дәвамчысы итеп Ф. Хөсни күрсәтелә.

Язучының беренче чәчмә әсәрләрендә тәнкыйтьче кеше образын бирүдә «корылык»ны сиземли: ул «начар мәгънәдәге романтикага чума, формализмга бирелә һәм алар кызыклы вакыйгалар астында яткан социаль сәбәпләрне күрми узарга яки ялгыш күрергә булышалар»[2]. Шулай да төп игътибарны тәнкыйтьче язучының новеллаларына юнәлтә.

«Фатыйх Хөсни новеллаларның үзенчәлекләрен баштан ук аңлау юлыннан бара һәм ул инде бу жанрны тәмам үзләштереп эш итә. Без аны әдәбиятта үз йөзен тапкан бер язучы итеп карыйбыз. Ул – новеллист. Аның соңгы хезмәтләре моны ачык күрсәттеләр»[3]. Мәкаләдә Ф. Хөснинең «Җир тыңлый» исемле романы каты һәм рәхимсез тәнкыйтькә очрап, язучыны күп нәрсәгә өйрәтүе турында да сүз йөртелә. Тәнкыйтьче фикеренчә: «Иң элек ул хәзерге чынбарлык

---

[1] Кашшаф Г. Үсү юлы // Совет әдәбияты. 1939. № 7. Б. 80.
[2] Шунда ук. Б. 79.
[3] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 86.

белән хисаплашырга өйрәнде; коры талантка таянып кына, тормышны белмичә торып, яхшы әсәр тудырып булмавын аңлады»[1]. Әнә шуннан соң язучы үзенең дөрес кыйбласын таба. Шул ук вакытта, беренче чорга караган әсәрләрендә Г. Кашшаф кимчелекләр, хаталар тапса да, Ф. Хөснинең язучылык сәләтен инкяр итми. «Кайнар кан тибеп торган сүзләр», кызып китү, тәэсирләнү, хыялга бирелү, хисләнү – бу чор новеллаларга хас үзенчәлекләр.

Ф. Хөсни иҗатының икенче чоры 1934 еллардан соң башлана, дип билгеләнә. Бу дәвердә язылган «Идел тынычсызлана», «Парикмахерскийда», «Минем беренче елмаюым», рәссам Наил Ишморатовка багышланган «Якшәмбе көн», «Ана хикәясе» һ.б. новеллаларга тәнкыйтьче тәфсиллерәк туктала, образларга мөрәҗәгать итә. Биредә дә Г. Кашшаф язучының тел байлыгын, җанлы сөйләмне куллану осталыгын билгели, алымнарны, канатлы сүзләрне, тасвирларны барлый. Тел белгечләрен, әдәбиятчыларны Г. Кашшаф яшь язучының иҗатына күбрәк игътибар итәргә чакыра. Хикәяләрдә кабатланган бер үк фразалар, образлар, күренешләрне мәкалә авторы игътибарыннан читтә калдырмый.

Гомумән алганда, тәнкыйтьченең үсеп баручы язучыга бирелгән бәяләмәсе уңышлы гына килеп чыга. «Г. Кәшшафның Ф. Хөсни турындагы мәкаләсе байтак эшлекле замечаниеләрне эченә ала. Анда Хөснинең йомшаклыгы әсәрнең әдәби-идеологик йөзен ачу белән урынлы гына күрсәтелә. Ләкин Г. Кәшшафның бу мәкаләсендә дә аерым әсәрләрне еллар тәртибендә характерлаудан яки аларга теге-бу күрсәтмәләр ясаудан теоретик гомумиләштерүгә бару, язучы иҗатының бөтен әдәби торышындагы төп тенденцияләрне ачып бәяләү юк дәрәҗәсендә»[2]. Иҗатта яшь талантларның әсәрләрен бәяләү җиңел эш түгел. Монда сак кына эш йөртергә кирәк. Тәнкыйтьче үзе карап чыккан новеллаларны үсеш этабы буларак билгеләп, алга таба Ф. Хөснигә зур өметләр баглый. Әмма язучыга карата бирелгән билгеләмәләр белән К. Фасиев килешми һәм бу хакта

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 87.

[2] Халит Г. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. № 1-2. Б. 135.

1949 елда «Совет әдәбияты»нда язып чыга. Г. Кашшаф тәнкыйтенең хатасын ул «формалистик-эстетлык позиция»дә торуында күрә: «Я, бу төче сүзләр укучыга нәрсә бирәләр соң? «Хисләр», «нечкә кыллы йөрәк», «моң», «серле күренешләр», «темперамент» һ.б. – бу төшенчәләр үз-үзләренә генә, тормыштан, материал чынбарлыктан, политикадан аерым хәлдә нәрсә булса да аңлаталармы? Әлбәттә, юк. Кашшаф иптәш боларны белергә тиеш иде»[1]. Г. Кашшаф Ф. Хөсни иҗатына биргән бу бәяләмәсеннән К. Фасиевның бу сүзләреннән соң да кире кайтмый, үз карашында нык тора.

Г. Кашшаф үз каләме җимешләрен вакытлы матбугат битләрендә генә теркәп калдырырга ашыкмый. Инде 1940 елда аның бер-бер артлы ике китабы басылып чыга. Бу китаплар татар әдәбиятының мәйданына яшь, кыю сүзле тәнкыйтьче килүен раслый.

Хезмәтләренең берсе «Каләм мастерлары» дип атала. Бу китап Г. Кашшафның газета һәм журналларда басылган мәкаләләренең иң уңышлыларын туплаган. Эчтәлеге үзе үк безне бөек шәхесләребез исемнәре белән игътибарны җәлеп итә: «Тукай турында», «Галиәсгар Камал», «Шәриф Камал», «Һади Такташ», «Шәйхи Маннур», «Үсү юлы» (Ф. Хөсни), «Капитан кызы» (А.С. Пушкин әсәре тәрҗемәдә), «Гасырлар аша ишетелгән халык авазы» (әрмән халык эпосы «Давид Сасунлы»ның 1000 еллыгына карата).

Г. Тукайга багышланган мәкаләне Г. Кашшаф шагыйрьнең әдәбиятта тоткан урынын билгеләү, иҗатына бәя бирүне күздә тотып яза: «Тукай көннәре бөтен халыкны җанландырды. Бу көннәрдә язучылар да үзләренең иҗат көчләрен арттырдылар. Үзләренең иҗат планнарыннан тыш күп кенә әсәрләр язуга керештеләр»[2]. Алга таба Тукай иҗатын өйрәнүдә яңа көчләр күтәрелеп чыгуы, дистәләрчә мәкаләләр, гыйльми тикшеренүләр ясалуы турында искәртелә, Г. Халит, Л. Җәләй, Х. Хәйри, Ф. Хөсни, А. Әхмәт, И. Газый, Ү. Гыймадиев, Ф. Абдрахманов һәм башкаларның хезмәтләре турында әйтеп уза. Әмма, тәнкыйтьче

[1] Фасеев К. Совет әдәбиятының һәм сәнгатенең яңа, көчле күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1949. № 6. Б. 140.

[2] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 4.

фикеренчә, бу хезмәтләрнең барысы да Тукайны өйрәнү юлында башлангыч чор гына.

«Тукайның милләтчелеге, аның «либераль буржуа» белән аралашып эшләве кебек нәрсәләрнең зур проблема итеп куелуларын күрергә була. Бу, әлбәттә, тарихи фактларны булып үткән тарихи вакыйгалар обстановкасы шартлары күзлегеннән карап эшләмәүне ачык раслый», − дип ассызыклый Г. Кашшаф[1]. Әлбәттә, укучы алдында үзен җаваплы тоеп, тәнкыйтьче шагыйрьнең иҗатын халыкка якынайтырга тырыша. Әдип Тукайның тулы бер образын бирергә, аның омтылышларын, характерын, фикер-карашларын, кичерешләрен гәүдәләндерергә чакыра. Бу юлда беренче адым ясаучы булып Ә. Фәйзи санала. Әмма тәнкыйтьченең төп максаты ул түгел. «Безне Тукайның бөеклеге кызыксындыра. Чыннан да Габдулла Тукайның бөеклеге нәрсәдә соң? Бу – гаять җитди сорау. Моңа ике сүз белән генә җавап биреп булмый. Моны аңлау өчен Тукайның бөтен тормышын, эшен, көрәшен, күп төрле иҗатын күз алдында тотарга кирәк. Алай гына да түгел, моның өчен аны чолгап алган тормышны, кешеләрне, язучыларны да онытмаска кирәк»[2]. Г. Кашшаф шагыйрьнең бөеклеген аның матур шигырьләр язуында, югары художестволы әсәрләр бирүендә, халык әдәбиятын яхшы белүендә һәм аңардан оста файдалана алуында гына түгел, ә бәлки: «халыкның прогрессив омтылышына җавап бирә алуында, үзе яшәгән чорның барлык интереслары белән яшәвендә», – күрә[3]. Шушы урында Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» исемле мәкаләсен искәртик. Билгеле булганча, «Татар шагыйрләре»ндә Г. Тукайның иҗаты кискен тәнкыйтькә очрап, Дәрдемәнд, С. Рәмиев иҗатларыннан соң тикшерелә. Совет чорында каләмен сынаган Г. Кашшафның карашлары (ул да шушы өч шагыйрьне янәшә куеп караса да) Г. Ибраһимов фикерләреннән шактый аерыла. Тәнкыйтьче әлеге саналган шагыйрьләр арасына Ф. Әмирхан иҗатын да кертеп җибәрә: «Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, С. Рәми кебек фигуралар Тукай заманында

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 4.
[2] Шунда ук. Б. 7.
[3] Шунда ук.

гаять популяр язучылар. Аеруча Ф. Әмирхан белән С. Рәминең баштагы иҗатлары гомуми хәрәкәт өчен гаять прогрессив булдылар. Ләкин алар Тукай кебек еракка карый алмадылар. Алар халыкның көчен, энергиясен күрә белмәделәр. Алар үзләрендә реакция кысрыклавыннан, аның тырнакларыннан котыла алырлык көч тапмадылар. Шуңа күрә дә, мәсәлән, Ф. Әмирханның халыкка мөрәҗәгать итүе һичбер уңыш китермәде, чөнки ул халыкның реакцион өлешенә таянды», – дип белдерә[1]. С. Рәмиев иҗатының җитешсез ягы итеп тәнкыйтьче аның, көчле талантын халык хәрәкәте белән кушып үстереп җибәрә алмавында, дип билгели. «Ул ялкынлы протестларын, бунтарьлыгын, анархистик кыюлыгын шыңшу белән тәмам итте», – дип яза Г. Кашшаф[2]. Бу урында тәнкыйтьченең Г. Ибраһимов мәкаләсенә карата туган фикерләрен белү кызык булыр иде. Мәкаләне дәвам иттереп, тәнкыйтьче Дәрдемәнднең иҗат дөньясына кереп китә. Билгеле бер дәрәҗәдә Г. Ибраһимов тарафыннан җиткерелгән карашларны Г. Кашшаф кабул итә. Моны түбәндәге җөмләләр раслый: «Саф сәнгать ноктасыннан караганда, Дәрдемәнднең идеаль төстә язылган шигырьләре бар. Без аның зур мастерлыгын, зур стилист булулыгын юкка чыгармыйбыз. Ул татар әдәбиятында аерым бер урында үзенең соклангыч стиле һәм өмитсез фәлсәфәсе белән тора. Аның кыска, ләкин тирән һәм киң мәгънәле шигырьләре бөтен дөньяга һәм бөтен кешелеккә баглы фәлсәфи фикерләр кузгата. Ул бөтен дөнья өчен хас булган проблемаларны актарып чыгара. Аларны ул үзенә генә хас бер виртуозлык күрсәтеп, укучыны таң калдырып, кыска-кыска җөмләләр эченә сыйдыра белә. Ул безнең татар әдәбиятында, шигырь хосусиятенең иң нечкә оттенокларын саклап эш итә торган шагыйрь булып тора»[3]. Әмма тәнкыйтьче Дәрдемәнднең иҗаты демократик рухта булмавы, массага мөрәҗәгать итеп язылмавы белән Тукайныкыннан аерыла, дип белдерә. «Ул дөньяның фанилыгын, тирә-ягыңны чолгап алган тормыш белән ризаланырга кирәклеген гәүдәләндерде. Шуңа күрә аның

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 8.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

шигырьләре халыкка барып җитмәде, популяр булмады. Аның шигырь стиле күпертелгән матурлык эчендә бикләнеп калды»[1], – дип яза. Әгәр искә төшерсәк, Г. Ибраһимов исә Тукайны тел, стиль чуарлыгында гаепләп чыга.

Г. Кашшаф Тукайны бу язучылардан өстен куя. Аның сүзләре буенча, шагыйрь халык тарафыннан кабул ителгән, аның үз кешесе, үз җырчысы, үз даһие.

Әлеге язучы-шагыйрьләрне берләштерүче тагын бер үзәк – аларның җәмәгатьчелек эшләрендә катнашулары. Тәнкыйтьче әнә шул якны да калкытып чыгара һәм шагыйрьнең эшчәнлеген яктырта: «Тукай бу яктан да, үзенең замандашларыннан бик күп өстен тора. Ул инде, башкалар кебек берьяклы һәм беркатлы гына җәмәгатьчел түгел. Аның җәмәгать эше аерым кешеләр интересына, үз мәнфәгатен саклауга буйсынмый, бөтен халык интересларын кайгыртуга буйсына»[2]. Ягъни әдип, шагыйрьнең кайсы гына өлкәдәге эшчәнлеген алмасын, һәрвакыт халыкка якын торуның дәрәҗәсен күрсәтә. Совет җәмгыяте таләпләренең берсен Г. Кашшаф билгеле бер тикшеренү үрнәге итеп ала.

Ахырдан үзе куйган сорауга җавап рәвешендә Г. Кашшаф Тукайның бөеклек сәбәпләрен санап чыга: «Реакция еллары аның лирикасына үз печатен суккан. Ләкин халык эчендә хәрәкәт башлану белән Тукайның рухы яңадан күтәрелеп киткән, ул яңа рухлар, яңа дәртләр белән «кояшның чыгасына ышанып», «хөр яшәү даулашларының» киләчәгенә күңелен беркетеп, заманының, киң масса хезмәт халкының рупоры булып әверелгән. Менә аның бөеклеге дә шунда!», – дип тасвирлый[3]. 1949 елда К. Фасиев тәнкыйтьченең бу шагыйрьләргә бирелгән бәяләмәсенә кискен тәнкыйть белән каршы чыга. Г. Кашшафның язганнары бөтенләй ялгыш бәя, дигән фикер үткәрелә. Аеруча бу хата Дәрдемәнд иҗатына кагыла: «Совет тәнкыйтьчесе буларак, Г. Кашшаф иптәшкә сәнгать, матурлык, вкусны канәгатьләндерә алырлык мас-

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 9.
[2] Шунда ук. Б. 16.
[3] Шунда ук. Б. 18.

терлык мәсьәләләренә совет кешеләре күзлегеннән, партиянең дөньяга карашыннан чыгып якын килергә кирәк иде. Әгәр дә Дәрдемәнднең әсәрләрендә черек идея хөкем сөрә икән, аның поэзиясе совет тәнкыйтьчесен сокландыра алмый. Ә Кашшаф иптәш Дәрдемәндне күкләргә күтәрә... Гаҗәп, Г. Кашшаф Тукайның фикердәшләрен һәм дусларын, Тукай белән бер чорда яза башлаган Г. Камалны, Г. Коләхмәтовны, Ш. Камалны һәм татар революционерларын, Тукайның якын дусты Х. Ямашевны, ничектер, оныткан?»[1]. К. Фасиев биредә төп хата – партия принципларын онытудан килә, дип ачыклый. «Тәнкыйть мәсьәләләренә карата» дигән мәкаләсендә Г. Кашшаф С. Рәми, Дәрдемәнд, Ф. Әмирхан иҗатларына чамадан тыш бәя бирүен, аның берьяклы булуын язып, үзенең хатасын таный[2]. Димәк, ул яздым – оныттым принцибына нигезләнеп эш итми, ә бәлки чын осталарча үз сүзе өчен еллар үтеп тә җаваплы булуын тоеп яши.

Татар театрының бөек шәхесе Г. Камал иҗатына Г. Кашшаф 30 нчы еллар ахырында мөрәҗәгать итә. «Г. Камал әсәрләрендәге кайбер типлар», И. Вахитов белән берлектә язылган «Галиәсгар Камал», «Татарның бөек драматургы» мәкаләләре бер-бер артлы «Совет әдәбияты», «Кызыл Татарстан» кебек газета-журналларда басылып чыгалар. Типлар турында сүз йөрткәндә, Г. Кашшаф түбәндәге фикерен җиткерә: «Г. Камал демократик карашларда торып, реакцион көчләрне фаш итте. Кадимче байлар, сәүдәгәрләрне һәм аларның хатын-кызларын тулы характерлар белән дөрес рәвештә гәүдәләндерде. Алар төгәлләнгән типлар булып, җанлы кешеләр булып биреләделәр»[3]. Калган ике мәкаләдә Г. Камал бөек драматург, татар театрын оештыручы, җәмәгать эшлеклесе, комедия тудыручы буларак тәкъдим ителә.

---

[1] Фасеев К. Совет әдәбиятының һәм сәнгатенең яңа, көчле күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1949. № 6. Б. 139.

[2] Кашшаф Г. Тәнкыйть мәсьәләләренә карата // Совет әдәбияты. 1949. № 7. Б. 95.

[3] Кашшаф Г. Г. Камал әсәрләрендәге кайбер типлар // Совет әдәбияты. 1938. № 6. Б. 70.

1939 елда тәнкыйтьче Г. Камалның «Беренче театр» исемле китабына кереш мәкалә авторы буларак чыгыш ясый[1]. Рус телендә басылган бу китапның кереш сүзенең дәвамы булып татар телендәге мәкаләләр дә дөнья күрә. «Каләм мастерлары»нда урын алган ике тәнкыйди мәкалә Г. Камалның тормыш һәм иҗат юлын яктырта. Алар татарның зур җәмәгать эшлеклесе, классик язучысы, татар театры һәм драматургиясенең нигезен салучыларның берсе – Г. Камалның тууына 60 ел тулу уңаеннан язылган. Биредә тәнкыйтьче әдипнең биографиясенә туктала, аның киңкырлы эшчәнлегенә басым ясый: «Татар театрын нигезләүгә, әсәр белән генә түгел, киемнәрем, уеннарым белән дә күп кенә ярдәм иткән идем. Татар буржуасы моның өчен мине кырый гына какты. Ул байгуралар театрны үстерүгә ярдәм итү түгел, бәлки һаман без башлаган эшләрне сүндерергә тырышалар иде.

Совет безнең эшләргә бик зур мөмкинлекләр ачты. Мин революциянең беренче көннәреннән башлап ук каләмем белән катнаштым. Һәм язып килдем»[2]. Әлбәттә, заман шартларында татар интеллигенциясе вәкилләре төрле юнәлешләр, иҗтимагый-сәяси шартларга ияреп, илдәге вакыйгаларны бертөрле кабул итмиләр. Шуңа күрә бу чорда хаталар җибәрү күренеше бүген табигый күренә.

Газета-журналларда язышу, сәяси яктан актуаль шигырьләре белән Совет хөкүмәте өчен көрәш алып баруы өстенә, Г. Камал яшь совет татар театрын үстерүдә актив катнаша. Г. Кашшафны әдипнең менә бу ягы аеруча кызыксындыра. Аның «Көндәш», «Өйләнәм – ник өйләндем» кебек комедияләре өстенә, 1921 елда беренче тапкыр татар операсын – «Корсын балам, бу кала»ны иҗат итүе турында яза[3]. Моннан тыш Г. Камал рус һәм Көнбатыш Европа драматургларының дистәләрчә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Алар арасында М. Горький, Мольер, Лопе де Вега һ.б. сәхнә

---

[1] Камал Г. Первый театр. 1939. С. 32.
[2] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 31 .
[3] Шунда ук.

әсәрләре бар. 35 ел хезмәт итү дәверендә драматург оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләрдән 102 пьеса язган.

Г. Кашшаф Г. Камалның татарда комедия тудыручы булуын танып, аның бу өлкәдә классик үрнәкләр калдыруын билгеләп уза: «Беренче театр», «Банкрот», «Бүләк өчен», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек әсәрләре көчле сатира кулланып язылган, дип өсти тәнкыйтьче. «Г. Камал иҗаты зур бер эпоханың көнкүрешләрен, тормышын һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрен чагылдыра. Ул татар иҗтимагый тормышының революцион чорларын аерым бер мастерлык белән гәүдәләндереп бирә», – дип яза Г. Кашшаф. Аның фикеренчә, Г. Камал әсәрләре аша без билгеле бер тарихи чорның тулы бирелешен күрәбез, татар халкының иҗтимагый фикерләрен, тормыш, көнкүрешләрен өйрәнүдә бу әсәрләр зур роль уйныйлар.

Мәкаләдә драматургның тел мастеры икәне, чын сәнгатьнең, миллионнарны тәрбияли торган сәнгатьнең, халык телендә гәүдәләндерелергә тиешлеген аңлап эш итүе дә ассызыклана[1]. «Г. Камал, Г. Тукай белән берлектә татар әдәби телен эшләде, аның чәчәк атуы өчен күп көч куйды. Г. Камал теленең халыкка ничаклы якын торуын теләсә нинди әсәреннән күрергә була. Алар барысы да җанлы, художестволы, һәркемгә аңлашыла торган җиңел формада биреләләр. Югарыда күрсәтелгән мисаллар моңа үрнәк була алалар. Ләкин бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый. Г. Камал геройларның телен бер үк калыпка салып бирми. Ул аларны индивидуальләштереп бирә. Һәркемнең телендә булган оттенокларны тота һәм шулар аша әсәрнең җанлылыгын көчәйтә», – дип бәяли тәнкыйтьче[2]. Шул рәвешле, мәкалә авторы Г. Камалның иҗаты әлегә чаклы тиешле дәрәҗәдә бәяләнмәде, дигән нәтиҗә чыгара.

«Каләм мастерлары»нда драматург әсәрләрен анализлаган мәкалә «Г. Камал әсәрләрендәге кайбер типлар» дип атала. Аның «Совет әдәбияты» журналында басылып чыгуы искәртелгән иде инде. Әлеге язмада драматургның театр, сәхнә өчен тудырылган әсәрләре тикшерелә. «Г. Камалның кыйммәте бала тәрбияләү проб-

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 38.

[2] Шунда ук.

лемасын куюда гына түгел. Камалның кыйммәте аның татар сәхнәсе тудыруында, татар сәхнәсенә репертуар булдыруында, татар әдәби телен художество теле итеп эшләп бирешүдә, комедия тудырышуда, халык фикерен яклап, халыкка дошман булган байларның, сәүдәгәрләрнең, гомумән халык җилкәсен кимерүче паразитларның чын йөзләрен фаш итүдә», – дип белдерә тәнкыйтьче[1]. Шул ук вакытта турыдан-туры драматик әсәрләргә мөрәҗәгать итеп, Г. Камал тудырган типлар әлегә өйрәнелмәгән, дип яза. Г. Кашшаф моңа чаклы драматургның типлары гомумиләштереп аңлатылуын аерып чыгара. Әмма, тәнкыйтьченең күзәтүе буенча, Г. Камалның чын мастерлыгы һәрбер әсәрендә яңа образ тудыруда ачыла. Менә, мәсәлән, дүрт төрле әсәрендә ул дүрт төрле кадимчене тасвирлый алган («Бәхетсез егет»тә Кәрим бай, «Безнең шәһәрнең серләре»ндә Әхмәтҗан, «Банкрот»та Сираҗетдин, «Беренче театр»да Хәмзә бай). Моны Г. Кашшаф драматургның осталыгы дип бәяли.

Әлбәттә, тәнкыйтьче бу мәкаләсе белән Г. Камалның барлык иҗатын күзәтеп чыкмый. Ул: «Без Г. Камал биргән типларның иң характерлыларына гына тукталдык. Ләкин болар – Г. Камалның ни дәрәҗәдә зур һәм киң колачлы язучы икәнен ачык күрсәтәләр. Бу типлар иҗтимагый тормышның билгеле бер тарихи чорын дөрес итеп гәүдәләндерәләр, аның социаль көчләрен күрсәтәләр», – дип, әдип үз мәкаләсенә нокта куя[2].

«Каләм мастерлары»нда урын алган «Галиәсгар Камал», «Г. Камал әсәрләрендәге кайбер типлар» исемле мәкаләләре «Күңел көзгесе»ндәге «Халык художнигы» дигән язма белән кисешә. Драматургның татар театры өчен тырышлыгы, күрсәткән хезмәтләре Г. Кашшаф тарафыннан макталып тасвирлана.

«Каләм мастерлары» җыентыгында Ш. Камалга, Һ. Такташка, Ш. Маннурга, Ф. Хөснигә багышланган бүлекләр, нигездә, аларның биографияләренә һәм иҗатларына күзәтү рәвешендә язылган, язылу сәбәпләре дә юбилейларына бәйләнгән.

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б.41.
[2] Шунда ук, Б. 56.

«Һади Такташ» мәкаләсендә Г. Кашшаф бәяләгән «Җир уллары» трагедиясенә карата Г. Халит түбәндәгеләрне белдерә: «Газый Кәшшаф бу әсәрдәге проблеманы Такташтагы кешене сурәтләү идеалын күрсәтү дип аңлатмак була. Газый Кәшшаф ул турыда әнә шул абстракт положениеләрнең иң абстракты булудан тыш бер нәрсә дә әйтми»[1]. Әмма Г. Кашшаф Һ. Такташ иҗатының характерлы якларыннан берсе булып кеше эзләвен билгели, шуннан чыгып кешенең иҗтимагый тормышта алган яки алырга мөмкин урынын билгеләргә тырыша. Алга таба дәвам итеп, Г. Халит: «Безнең тәнкыйтьләрдә кеше термины бик күп очрый. Моны артык яратучылардан – Г. Кәшшаф. Теория әйтүенчә, сәнгатьтә үзәк урында торган объект – кеше; шулай булгач, сәнгать кешене сурәтләүгә әһәмият бирергә тиеш. Г. Кәшшаф менә шуны ала да, барысына да – Ш. Камалга да, Г. Камалга да, Һ. Такташка да, Г. Тукайга да кеше проблемасы абстракциясен ябыштыра башлый»[2]. Шушы юлларга нисбәтле «Литературная газета» һәм «Молодая гвардия» журналында эшләгән тәнкыйтьче А.Н. Макаров сүзләрен китерү урынлы булыр. Аның фикеренчә, әдәби тәнкыйтьнең предметы булып кеше һәм аның иҗтимагый тормышы тора һәм һәрбер тәнкыйтьченең үз иҗади тәҗрибәсе һәм үз темасы бар[3].

«Каләм мастерлары»ндагы Ш. Маннур турындагы биографик очерк: «Талантлы шагыйрьләр бик тиз танылалар. Беренче әсәрләре белән үк игътибар казаналар һәм укучылар тарафыннан кабул ителәләр. Маннур шундый шагыйрьләрдән булды», – дип башланып китә[4]. Мәкалә кыскача Ш. Маннурның биографиясе, төрле өлкәләргә караган эшчәнлеген яктырта. Шул исәптән, аның К. Паустовский, Л. Толстой, А. Чехов, А. Пушкин, М. Лермонтов, Н. Некрасов һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итүе, тәнкыйть өлкәсендә каләм сынавы да ассызыклана: «Ул 1939 елда татар Совет шагыйре

---

[1] Халит Г. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. № 1-2. Б. 142.

[2] Шунда ук, Б. 143.

[3] История русской литературной критики: учеб. для вузов / под ред. В.В. Прозорова. М.: Высш.шк., 2002. С. 318.

[4] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 76.

Һади Такташ шигырьләренә тулы анализ ясады һәм Такташ иҗатына дөрес бәя биреп, кыю фикерләр әйтте»[1]. 1939 елда Ш. Маннурның дөнья күргән ике җыентыгын («Шигырьләр», «Казан утлары») Г. Кашшаф, җитдилек, логика көче белән аерылалар, дип бәяли.

Китапка кергән ике мәкаләнең берсе «Капитан кызы» дип атала. Ул – танылган рус әдибе А.С. Пушкин әсәренең тәрҗемәсе турында. Г. Кашшаф А. Шамов тәрҗемә иткән бу әсәрнең татар әдәбияты үсеше өчен зур вакыйга булуын белдерә. Гомумән, Г. Кашшаф татар теленә дөньякүләм танылган әсәрләрне тәрҗемә итү ягында тора. Шул рәвешле, аның фикеренчә, алдынгы фикер-карашлар татар әдәбиятына да үтеп керә ала, халыкка җиткерелә. Соңрак язылган мәкаләләренең тагын берничәсендә Г. Кашшаф тәрҗемә мәсьәләсенә аерым туктала. Г. Камал тәрҗемәсендә Н.В. Гогольнең «Ревизор»ы, Л.Толстойның А. Шамов тәрҗемә иткән «Яңадан туу»ы, М. Мәхмүднең «Сугыш һәм тынычлыг»ы (шулай ук Л. Толстой әсәре) тәнкыйтьчене татар әдәбиятында тәрҗемә мәсьәләләрен күтәрергә өнди. «...Тәрҗемә турында сүз киткәч, шуны әйтергә кирәк: И. Гази, Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, С. Әдһәмова кебек өлкән буын язучыларның хезмәтләрен дә без бик югары бәяләргә тиешбез. Шигъри тәрҗемә өлкәсендә Ә. Исхакның хезмәтләре бик зур»[2]. Әмма шушы югары бәя бирү белән беррәттән, Г. Кашшаф тәрҗемә итү процессында киткән отышсыз сүзләрне, мәгънәләре икеле булган фразаларны да барлый. Шуңа күрә ул тәрҗемә өлкәсенә караган төрле тикшеренүләр алып барырга тәкъдим итә. Тәнкыйтьченең мондый проблемаларны күтәреп чыгуы очраклы гына түгел. Заманында ул үзе дә берничә әсәрне тәрҗемә итеп бастырган әдип.

«Гасырлар аша ишетелгән халык авазы» мәкаләсен Г.Кашшаф әрмән халык эпосы «Давид Сасунлы»ның 1000 еллыгы уңае белән яза. Игътибар итик: бу мәкалә 1939 елда басылып чыга һәм анда шундый караш алга сөрелә: «Татар халкы өчен бу эпосның аеруча

---

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 80.
[2] Кашшаф Г. Культурабызга зур хәзинә // Совет әдәбияты. 1960. № 6. Б. 136.

якын булуын әйтергә кирәк. Бу якынлык «хатын», «пәһлуан» һ.б. шуның кебек аңлашыла торган сүзләр куллануда гына түгел, эпосның бөтен төзелешендә, батырларның хәрәкәтендә, уйлау формаларында, көнчыгышлыкта сизелә. Ниндидер юллар белән бу татар халык иҗатына да тәэсир иткәндер кебек тоела. Ниһаять, ирек һәм бәхет турында өметләнү – барлык халык өчен уртак нәрсә»[1]. Ун ел узып, Г. Кашшаф татар әдәбиятының «Нуры содур», «Нәһҗел-фәрадис», «Идегәй» әсәрләренә каршы чыгыш ясый, хәтта бу өлкәдә тикшеренү алып баручы Л. Җәләй, Н. Исәнбәтләрне гаепләп чыга[2]. Билгеле инде, монда тәнкыйтьченең тарихи чикләнгәнлеге, чор сәясәтенә тугры калуы сизелә. Әмма бер халык ядкярләрен мактап, үз халкың мирасын сызып ташлау, бүгенге көн күзлегеннән караганда, Г.Кашшаф эшчәнлеген акламый.

Әдәби тәнкыйтьнең төп бурычы шунда ки, ул һәрбер әдәби фактны тарихи чынбарлыкка мөнәсәбәттә, тирән һәм дөрес анализлауны күздә тотарга тиеш. «Демократик язучыларга дан бирәбез дип, без кайчак әдәби хәрәкәтләр исеменнән дә тотнаксыз сөйли башлыйбыз. М. Гали дә, Г. Кәшшаф та андый алымнарны бик яраталар. Очсыз-кырыйсыз әдәби хәрәкәтләр яки икенче төркем язучылар исеменнән С. Рәмиевне генә характерлау түгел, башкаларга мөнәсәбәттә дә бу ачык сизелә»[3]. Әлеге фикерләр Г. Кашшафның бу чорда язылган мәкаләләренә, шул исәптән «Каләм мастерлары»нда урын алганнарына да карый. «Г. Кәшшаф та, Х. Хәйри дә һ.б. да, Энгельсның типик характерларны типик шартларда бирү турындагы конкрет положениесен абстрактлаштырып, бу язучы типик характерлар бирә, үзенчәлекле итеп, типик итеп сурәтли, дип, бик күп мәртәбәләр бер үк нәрсәне әйләндереп торалар. Ләкин язучыдагы шул положениенең эстетик дәрәҗәсен ачу, тану белән тирәннән һич

[1] Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 86.

[2] Кашшаф Г. Тәнкыйть мәсьәләләренә карата // Совет әдәбияты. 1949. № 7 Б. 90–96.

[3] Халит Г. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. № 1-2. Б. 137.

тә кызыксыныылмый»[1]. Г. Кашшаф Тукайның пролетариат карашыннан читтә булуын сөйли дә: «Менә шушы хәлләр Тукай әсәрләрендәге типларны билгелиләр, кеше образларындагы характерларны утырталар (?), Тукай әсәрләрендәге кеше образына почетлы урын бирелә... күбесенчә Тукай гомуми образлар бирә... Тукай, гомумән, гаять киң карашлы, катлаулы характерлы, җанлы кеше булып тора. Зур хәреф белән языла торган кешенең рухын гәүдәләндерә! дип укучыны шаккатырмак була. Тәнкыйтьче иптәш, язучы фамилиясен генә үзгәртеп, шул ук концепциясен Ш. Камалга да тага»[2]. Индивидуаль фикер йөртү мәсьәләсенә артык әһәмият бирмәгәнлектән, Г. Халит Г. Кашшафны урынсыз сүзләр куллануда, кабатлануда гаепли: «Аның образлары тулы килеш гәүдәләнә... Алар сыйнфый көрәшкә чаклы күтәрелеп җитә алмыйлар. Әсәрнең һәм язучының кимчелеге дә – шул сыйнфый көрәшне күрсәтмәүдә... һ.б. шикелле чеп-чи абстракциядән торган һәм миллион художникны «бәяләүгә» ярачан трафаретларны бутап торырга мәҗбүр»[3]. Әлбәттә, Г. Халитның сүзләре белән күпмедер дәрәҗәдә килешергә дә була. Тик истән чыгармыйк: җыентыкка кертелгән мәкаләләр төрле елларда язылган. Шунысы кызык: тугыз ел үткәннән соң да «Каләм мастерлары»нда ясалган хаталарны Г. Кашшаф төзәтергә ашыкмаган. Бу хакта К. Фасиев 1949 елда үзенең тәнкыйди язмасында искәртә: «... китап моннан 9 ел элек чыккан, ләкин аның фаҗигасе шунда: Кашшаф иптәш үзенең китабындагы ул хаталарны моңа кадәр беркайда да төзәтмәде, хәтта хәзер дә, космополит тәнкыйтьчеләрне фаш итү уңае белән үзенең бөтен эшен яңадан карап чыгу кирәк булганда да, моны эшләмәде. Шуның өстенә, бу китаптан әле бүген дә мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында файдаланалар»[4]. Г. Кашшафның шулай «космополит»ларга ташлама ясавын К. Фасиев партиялелек хисе җитмәүдән, халык тарафыннан йөкләтелгән

---

[1] Халит Г. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. Б. 136.

[2] Шунда ук, Б. 137.

[3] Шунда ук. Б. 143.

[4] Фасеев К. Совет әдәбиятының һәм сәнгатенең яңа, көчле күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1949. № 6. Б. 139.

җаваплылыкны тиешенчә һәм тирәнтен аңламаудан, марксистик-ленинчыл эстетикага таянмаудан күрә. Тәнкыйтьче тарафыннан җиткерелгән бу сүзләрне укыгач кына, Г. Кашшаф үзенең кайбер хаталарын тануы турында «Совет әдәбияты» битләрендә яза.

«Каләм мастерлары»нда бирелгән мәкалә белән чикләнмичә, тәнкыйтьче шул ук 1940 елны Ш. Камал иҗатына багышлап аерым китап чыгара. Хезмәт «Тормыш юлы» һәм «Иҗатына характеристика» дип исемләнгән ике бүлектән тора. Үз чиратында беренче бүлекне аерым бүлекчәләр тәшкил итә. «Яшьлек, ата-ана һәм туганнар» дигәнендә, мәсәлән, Г. Кашшаф: «Шәриф Камал үзенең ата-анасына булган мөнәсәбәтен хикәяләрендә ачык яза. Аның күп кенә әсәрләре автобиографик материалларга нигезләнеп язылалар», – дип билгеләп уза[1]. Калган бүлекчәләрдә китап авторы укучыны Ш. Камал кичкән сукмаклардан йөртеп чыга. Менә Ләбәҗә мәдрәсәсе (Пенза губернасы), Рига, Төркия, Мисыр, Петербург... 1910 елда Ш. Камал Төркестан якларына чыгып китә. Фатих Кәрими аны Оренбургтагы «Шура» журналы, «Вакыт» газеталарының редакцияләренә эшкә чакыра. Дәрдемәнд һәм Ф. Кәрими ярдәме белән 1914 елда Ш. Камалның хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Бу хакта Г. Кашшаф язган шушы җөмләләр кызыклы: «Дәрдемәнд һәм Фатих Кәрими, «кирелеген» сындырып булмый торган Шәриф Камал әсәрләрен басалар. Алар үз сыйныфларының көчлелегенә һәм бара-бара Шәрифнең дә «рәткә» килүенә ышаналар»[2].

1925 елда Ш. Камал Казанга күчеп килә. Биредә ул иҗат эшчәнлеген дә киң планда җәелдереп җибәрә. Беренче бүлекне тәмамлап, Г. Кашшаф түбәндәге нәтиҗәләрне чыгара: «Шәриф Камал иҗаты интернационализм принципларына нигезләнгән, аңа милләтчелек карашлары һәрвакытта чит булды һәм һәрвакыт ул аның белән көрәшеп килде. Шуңа күрә Ш. Камал әсәрләре башка милләтләр тарафыннан да яратылып укылалар...»[3]. Әйе, бу чор

---

[1] Кашшаф Г. Шәриф Камал. Казан: татгосиздат, 1940. Б. 5.
[2] Шунда ук, Б. 37.
[3] Шунда ук. Б.142.

өчен Г. Кашшаф сүзләре бик урынлы кулланылган. Алар татар совет әдәбиятында Ш. Камал иҗатын сыйфатлаучы төп билгеләмә булып торалар. Әмма шунысын да онытмаска кирәк: Ш. Камал әсәрләре тормышның ачысын, газабын авторның үз күргәннәреннән чыгып язылганнар. Шуңа да аларның укучыга тәэсир итү көче сизелеп тора. Илдәге авыр тормыш шартларында яшәгән халыклар өчен бу әсәрләр, аларда күтәрелгән тема-проблемалар да шуңа актуаль. Тәнкыйтьче Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен, иҗатының беренче чорын йомгаклый торган иң матур әсәрләреннән берсе, дип атый.

Беренче бүлеккә бирелгән Ф. Абдрахманов бәясенә тукталып узыйк: «Ш. Камал укучының алдына, нәкъ әсәрләрендәге шикелле, сабыр темпераментлы, намуслы, самими йөрәкле, нечкә юморлы, шуның белән бергә, партиянең, халыкның эшенә нык бирелгән, туры язучы һәм чын кеше булып килеп баса»[1].

Китапны язучының иҗатына характеристика дәвам итә. Тәнкыйтьче фикеренчә, татар әдәбияты тарихында Ш. Камал исеме халык шагыйре Г. Тукай һәм татар театры атасы Г. Камал исемнәре белән янәшә тора. «Татар халкының җәмәгатьчелек фикерен, иҗтимагый аңын үстерүдә шушы өч язучы гаять зур роль уйнадылар. Поэзия өлкәсендә Тукай, драматургиядә – Галиәсгар Камал, прозада – Шәриф Камал татар әдәбиятының классик үрнәкләрен күрсәттеләр»[2].

Ш. Камал әсәрләренең үзенчәлеге нәрсәдә соң? Моны билгеләр өчен, Г. Кашшаф аның проза һәм драма әсәрләрен тикшерә. Ул авторның «Уяну», «Козгыннар оясында», «Акчарлаклар», «Сулган гөл», «Тормыш көе», «Күңелсез эш», «Эч пошулы», «Көзге яңгыр астында», «Депутат», «Сәмруг кош», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Таң атканда», «Ут», «Томан арты», «Матур туганда» һ.б. әсәрләренә анализ ясый.

Г. Кашшаф билгеләвенчә, язучы тормышны дөрес чагылдыра, капиталистик җәмгыятьнең характерлы якларын күрсәтә, ләкин

---

[1] Абдрахманов Ф. Шәриф Камал // Совет әдәбияты. 1941. № 5. Б. 85.

[2] Кашшаф Г. Шәриф Камал. Казан Татгосиздат, 1940. Б. 57.

тиешле нәтиҗә чыгара алмый. Аның геройлары да ялганны, бозыклыкны, җәберне күрәләр, кемнеңдер алдаганын, кемнеңдер алар хисабына яшәвен сизәләр. Вакыт-вакыт аларга нәфрәтләре кузгала, изүчеләргә каршы ачу уяна, капиталистик системага ризасызлык туа. Ләкин бу хисләр, мондый тойгылар аларның күнелләрендә генә саклана. Ничаклы изелсәләр дә, алар ачуларын кемгә каршы юнәлдерергә, кем белән һәм ничек көрәшергә белмиләр. Алар сыйнфый көрәшне күз алдына китерә алмыйлар, шуңа күрә көчләрен берләштерү зарурлыгын аңламыйлар.

«Ләкин драмаларның әһәмияте көндәлек вакыйгалар эчендә генә калмады. Ул – Шәриф Камал иҗатында үзе бер зур үсү чоры булып, татар совет театры үсешенең билгеле бер этабы булып танылды һәм шуңа күрә дә безгә ул хезмәткә күз салырга кирәк»[1]. Г. Кашшаф Ш. Камал драматургиясен Г. Камал, Т. Гыйззәт, Ф. Бурнаш һ.б. язучыларның иҗатыннан аерып куя. Аның уенча, Ш. Камал драмалары темалары белән дә, художество ягыннан формалашуы белән дә үзенчәлекле әсәрләр. Алар, башлыча, производство эшчеләрен, аларның катлаулы образ-характерларын күрсәтәләр. Ш. Камалга чаклы татар драматургиясе мондый образларны белми диярлек. «Ул беренче буларак чынбарлыкны тар рамкаларда күрсәтүдән чыкты, геройларның бикләнеп яшәүләрен бирүдән котылды. Ул образ-характерларны барлык катлаулылыгы белән сурәтләде: алар сәхнәдә яшәделәр, көрәштеләр, сөйделәр, газап чиктеләр, бәхеткә, иреккә омтылдылар, тик шәхси омтылышларын халыктан аермадылар, халык бәхетенә, халык омтылышына бәйләнеп килеп чыктылар»[2].

Әлеге китапта анализланган әсәрләргә карата заманында Г. Халит түбәндәге фикерләрен җиткергән: «Г. Кәшшафның Ш. Камал әсәрләрен характерлавы күбрәк шул примитив аннотацияләрдән, турыдан-туры эчтәлек сөйләү колы булудан һәм

---

[1] Кашшаф Г. Шәриф Камал. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 112–113.
[2] Шунда ук, Б. 114.

өзекләр китерүдән тора»[1]. Бу чыннан шулай. Китап әсәрләргә тулы бәяләмә бирүне дәгъва итми. Г. Кашшаф бу максатны куймый да. Алга таба Г. Халит Ш. Камалның «Уяну» әсәренә бирелгән бәяләмә белән килешми: «Ш. Камалның хәсрәт, җафа, сыкрау белән тулган аеруча «Уяну» новелласында Горький кешеләренең мәгърур яңгыравын табу – кеше турындагы бүгенге терминнар белән Ш. Камал иҗаты өстендә шаяру гына һәм бер художникның уңай характеристикасын, үзенчәлеген моны бөтенләй таләп итмәгән икенче язучыга механик күчерү генә бу. Тәнкыйтьче, шул «бөек» булып күренгән фикерләренә чынлап та ышанса, бик ялгыша. Әдәбият тарихына, әдәби хәрәкәткә һәм икенче вәкилләргә таянып эшләнә торган «концепцияләр» тәнкыйтьченең кайвакыт язучы иҗатындагы аерым моментны гына алып уйлавы, эләктерүе белән дә бәйләнгән. Чөнки бездә язучының теге яки бу ягын гына тотып мөгез чыгару да гадәт булып йөри»[2]. Әмма әлеге фикерләр белән килешеп бетеп булмый. Монографияда: «Шәриф Камал, Максим Горькийның иң яхшы шәкертләреннән берсе буларак, кешедә иҗат итү көче күрде. Кешенең нечкә хисле шагыйрь булуын, бай табигатьле, тирән фикерле булуын ачып салды», – дигән юллар да бар. Әлеге юллардан аңлашылганча, Г. Кашшаф бер язучы сыйфатларын икенчесенә күчерергә ашыкмый, ә бәлки М. Горькийны остаз итеп күрсәтә.

Г. Халитның фикере белән Ф. Абдрахманов та килешә күрәсең. Китапның икенче бүлеген ул, ашыгып язылган, йомшак, дип бәяли. Моны ул тәнкыйтьченең Ш. Камалны язучы буларак мастерлыгын ачып бетерә алмавында күрә. Кимчелекләрдән Ш. Камалның яза башлау вакытын ике урында ике төрле бирүгә, заманында нинди язучы-шагыйрьләр белән аралашканын күрсәтмәүгә, аңа кемнәр, нәрсәләр тәэсир итүен билгеләмәүгә аерым туктала[3]. Бу юллар белән тулысынча килешеп булмый. Менә, мәсәлән, 26 биттә тәнкыйтьче Ш. Камал Горькийны укытучысы

---

[1] Халит Г. Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. № 1-2. Б.144.

[2] Шунда ук. Б. 137.

[3] Абдрахманов Ф. Шәриф Камал // Совет әдәбияты. 1941. № 5. Б. 85-86.

итеп таный һәм аның тәэсиренә бирелә, 61 – 62 битләрдә, язучының иҗатына М. Горький, А.П. Чехов йогынты ясый, дигән фикер үткәрелә. Китаптагы фикерләр, кыскача булса да, шул ук елны «Кызыл Татарстан» газетасында басылалар. Әлеге мәкалә «Образлар мастеры» дип исемләнә.

Г. Кашшафның Ш. Камалга багышланган бу кечкенә китабын күләме ягыннан арттырырга да мөмкин булыр иде. Әмма без бу монографиянең язылу тарихына Г. Кашшафның 1974 елда язылган бер мәкаләсендә әйләнеп кайтабыз. Ш. Камалның тууына 90 ел тулуга багышланган елда Г. Кашшаф аның иҗат портретына штрихлар белән «Совет әдәбияты» битләрендә мәкалә бастыра. Ф. Абдрахмановның язганнарына кайтаваз рәвешендә, түбәндәгеләрне җиткерә: «1939 елның азакларында без Шәриф абыйның утыз еллык хезмәт бәйрәменә әзерләнә башладык. Иптәшләр миңа аның иҗатын өйрәнергә, тулырак итеп биографиясен язарга куштылар. Иҗаты азмы-күпме билгеле булса да, аны яңача күз салып укырга кирәк иде. Чөнки биш ел элек кенә, аның 25 еллык иҗат бәйрәмен билгеләү уңае белән, матбугатта капма-каршы фикерләр күп әйтелгән иде. Үз вакыты өчен хас булган вульгар социологизм тәнкыйте революциягә чаклы булган иҗатын вак буржуа лагерена аударып калдыра, комедиясеннән уңай образлар эзли, М. Горькийча пролетариат әдәбияты тудыра алмавы өчен шактый үтемле сүзләр әйтә. Шуның белән бергә, Ш. Камалның язучылык гомере 1909 елдан исәпләнеп йөртелә, чөнки аңа чаклы газеталарда басылган публицистик характердагы әсәрләрен, янәсе, язучы «үзе серьез эшкә хисапламый»[1]. Г. Кашшафның үз сүзләренә караганда, ул Ш. Камалның иҗатына бәйләп, биографиясен язарга тырышкан. Ул вакытта Ш. Камал турында хезмәтләр юк, булганнары да әйләнешкә кертелмәгән. Ш.Камал тәнкыйтьченең барлык язганнары белән ризалаша. Ш. Камал турындагы бу кечкенә китап – үз вакытында автор тарафыннан эшләнгән хезмәтләрнең иң җаваплысы.

[1] Кашшаф Г. Иҗат портретына штрихлар // Казан утлары. 1974. № 2. Б. 176.

Г. Кашшафның Бөек Ватан сугышына кадәр әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эзләнүләренә йомгак ясап, Р. Нуруллина түбәндәге фикерләрне җиткерә:

1. Тәнкыйтьче әдәбиятның тарихын һәм хәзергесен бер дәрәҗәдә өйрәнә һәм шуларны язып чыга (Тукай иҗатын өйрәнүгә басым ясап);

2. «Гази Кашшаф утызынчы еллар ахырында һәм кырыгынчы елларның башында татар әдәбиятында проза хәлләре белән дә кызыксынды, аны өйрәнде» (Ш. Камал, Ф. Хөсни, А. Алиш, М. Гали, К. Нәҗми иҗатларына мөрәҗәгать итү мисалында)[1]. Шулай да бу берьяклы бәя, чөнки Г. Кашшаф беренче язмаларыннан ук төрле жанрларга мөрәҗәгать итә, драматургия, шигърият тә аның игътибар үзәгеннән читтә калмый.

Н. Юзиевнең бүленешен искә төшерсәк, сугыш башланганнан соң Г. Кашшаф эшчәнлегенең яңа этабы башлана. Билгеле, без моны тәнкыйтьченең биографик материалларыннан да чыгып раслый, илдә барган үзгәрешләр аркылы да күрсәтә алабыз.

Г. Кашшафның «Иҗтимагый моңнар җырчысы» (1943) мәкаләсе Г. Тукайның «Аң» шигыреннән алынган юллар белән башлана да, алга таба мәкалә авторы, озак кына, укучыга илдәге сәяси вакыйгаларны сөйли. Шушы иҗтимагый тормышта шагыйрь үз юлын, кыйбласын дөрес аңлады, халыкка якынайды, ди тәнкыйтьче: «Тукай иҗаты татар җәмәгатьчелегенә яңалык алып килде: шагыйрь новатор иде! Коллык, вәхшилеккә, явызлык, мәкерлеккә каршы юнәлгән тапкыр фикерләре шигъри моң аша хезмәт халкының йөрәгенә барып керде...»[2]. Шагыйрьнең милләт, мөселман сүзләрен нинди мәгънәдә куллануга автор аеруча басым ясый. Бу инде укучыга, чор, заман таләбенә таянып, Тукай иҗатын якынайту. Күрәбез: мәкаләдә урын алган сүзләр «Каләм мастерлары»ндагы фикерләр белән кисешә. Бары тик мәкалә ахырында, нәкъ Һ. Такташ иҗатына бәйле кебек, сугышка, фашистларга кара-

---

[1] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 20-21.

[2] Кашшаф Г. Иҗтимагый моңнар җырчысы // Совет әдәбияты. 1943. № 5. Б. 45.

та нәфрәт уяту теләге ачык сиземләнә. Сугыш елларында язучыларга, гомумән каләм тибрәтүчеләргә кытлык чоры тәнкыйтьчене тарихи мирасыбызга да мөрәҗәгать итәргә этәргәндер.

Г. Кашшафның тәнкыйть өлкәсендәге тагын бер юнәлеше – төрле җыентыкларга язылган бәяләмәләре. Мәсәлән, 1941 елда аның «Ленин-Сталин турында» җыентыгына язылган рецензиясе бар. Китапка кергән авторларның әсәрләре тикшерелә, аларга бәя бирелә. Тәнкыйтьче язганча, Ленин, Сталин – ул безнең чынбарлык. Ни генә булмасын, тарих үз урынында кала. Бүгенге сәнгатьтә тарихи шәхесләр турында төшерелгән фильмнар, язылган әсәрләр укучы тарафыннан зур кызыксыну белән кабул ителә. Яңа буын әлеге шәхесләрне ишетеп, укып белә. Чынлыкта исә сәхнәдә, әдәбиятта тудырылган образлар тарихи шәхесне тирәнрәк аңларга, халыкның ни өчен аның фикерләренә ияреп китүе турында күбрәк белергә ярдәм итәләр. «Ильичка багышланган уңышлы шигырьләр рәтендә С. Хәкимнең «Володя ант итә» һәм Н. Дәүлинең «Ильич» исемле шигырьләре матур, оригиналь алымнар белән язылганнар... М. Җәлил, Ш. Маннур, Н. Баян, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Ә. Исхак, Г. Хуҗи, З. Гәрәй иптәшләрнең шигырьләре Ленин-Сталин эшенә чиксез бирелеп эшләү тойгыларын, юлбашчыларга ихтирам итүнең иң гүзәл күренешләрен чагылдыралар»[1]. Җыентыкның ике хикәя белән чикләнүе тәнкыйтьче тарафыннан кимчелек булып санала. Шуларның берсен – Г. Кашшафның «Ана шатлыгы» исемлесе инде тикшерелде. Мәкаләнең ахырында ил башлыклары әкияти батырлар белән чагыштырыла: «Язучы Г. Разин татар халкы тарафыннан чыгарылган «Алмас батыр белән Корыч батыр» исемле әкиятне язып алган һәм аны шушы җыентыкка биргән. СССР халыклары фольклоры арасында бу әкият зур почетлы урын алачак, ул татар халкының юлбашчыларны никадәр зурлавын, никадәр тирәннән аңлавын раслый торган бер әсәр булып тора»[2].

[1] Кашшаф Г. Ленин-Сталин турында // Совет әдәбияты. 1941. № 1. Б.90.
[2] Шунда ук. Б. 91.

Бөек Ватан сугышы елларында әдәбият дөньясының хәле турында Г. Кашшаф һәрдаим Язучылар союзында чыгышлар ясый. 1943 елда СССР Язучылары союзы Президиумы чакыруы буенча татар совет язучыларыннан Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми, Г. Кашшаф Мәскәүгә баралар. Бу җыелышка фронттагы язучылардан Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, Г. Галиев, М. Садри да катнашалар. Мәскәүдә әдәби кичә, радио аша әдәби тапшыру, үзәк нәшриятлар белән татар әдәбиятын рус телендә бастыру турында сөйләшү, Татарстан Язучылар союзының хисап докладын тикшерү үткәрелә. Авыр сугыш елларында Мәскәүгә барып кайту нәтиҗәләрсез калмый. Бу хакта Г. Кашшаф «Кызыл Татарстан» битләрендә язып чыга: «1944 елда Гослитиздат рус телендә татар шигъриятенең Антологиясен бастырып чыгарачак. Антология XII йөздән алып бүгенге көнгә чаклы булган иң яхшы шигырь үрнәкләрен эченә ала. Моның өстенә, халык эпосы «Идегәй», Г. Тукайның бер томлыгы, Г. Разинның «Сиваш» исемле повесте, М. Җәлил шигырьләре басылачак. «Советский писатель» нәшрияты татар совет поэзиясе, татар совет прозасын эченә алган зур гына күләмле ике әсәр бастыруны планлаштырды. «Искусство» нәшрияты Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясен һәм Т. Гыйззәтнең бер драмасын бастырып чыгарачак»[1].

Сугышка кадәр һәм сугыш елларында татар әдәбияты зур югалтулар кичерә. 1942 елда татар совет әдәбияты классигы Ш. Камал үлеп китә. 1944 елда аның алтмыш еллыгы уңаеннан Г. Кашшаф «Совет әдәбияты»нда мәкалә белән чыгыш ясый. Язмада Ш. Камалның да сугышка карата нәфрәт белән иҗат итүе ассызыклана[2]. Иҗатына караган фикерләр яңалык алып килми. Ә менә Г. Кутуйны югалтканнан соң язылган мәкаләне игътибарсыз калдырып булмый.

Әлеге язмада тәнкыйтьче яңа яктан ачылып китә. Биредә шагыйрь укучы алдына кеше, гади инсан буларак килеп баса. Мәкаләдә китерелгән күпсанлы хатлардан өзекләр, Г. Кутуйның холык сыйфат-

---

[1] Кашшаф Г. Татар әдәбияты яңа борылышта // Кызыл Татарстан. 1943. 23 ноябрь.

[2] Кашшаф Г. Шәриф Камалның тууына 60 ел тулу уңае белән // Совет әдәбияты. 1944. № 2-3. Б. 86.

лары бүгенге заман укучысы өчен дә кызыклы. Шул ук вакытта, Г. Кашшаф «Рөстәм маҗаралары», «Тапшырылмаган хатлар»ның язылу тарихы белән дә таныштырып уза. Гомумән, бу фактлар – әдәбият тарихы өчен әһәмиятле. Тәнкыйтьче, Һ. Такташ, К. Нәҗми, А. Шамов, М. Максуд, М. Җәлил һ.б. белән беррәттән, Г. Кутуйны да татар совет-пролетар әдәбиятына 1918 – 1920 еллардан ук нигез салып, аны гомуми совет-пролетар әдәбиятының күренекле отряды дәрәҗәсенә үстерү өчен иҗат көче куючылар арасына куя[1]. Шигырь, драма, проза төрләрендә каләм көчен сынаган Г. Кутуйның иҗаты, тормыш юлы, мәкалә авторы фикеренчә, аерым бер роман язарлык. Шагыйрь-солдатның дулкынланып язган хатлары да күпләр өчен гыйбрәт алырлык. Дустының портретын сурәтләү тәнкыйтьче тарафыннан отышлы эшләнгән.

Большевистик җитәкче һәм тәрбияче образын сурәтләгән М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасына бәяләмәне «Патриотизм көче» мәкаләсендә табабыз. «Миңлекамал» драмасы сугыш чорындагы колхозчылар массасын объектив гәүдәләндергән художество әсәре һәм ул татар совет әдәбиятының бүгенге юнәлешен характерлавы белән дә әһәмиятле», – дип яза Г. Кашшаф[2]. Мәкалә авторы Миңлекамалны яңа образ, советчыл патриотизмны чагылдыручы герой буларак тәкъдим итә. Кыскача һәм өстән-өстән генә әсәр сюжетына тукталганнан соң, башка образларга да гомуми бәя бирелә. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче укучының игътибарын әледән-әле патриотизмга юнәлтә. Аның фикеренчә, публицистик ялкын әсәрнең сәяси әһәмиятен көчәйтә. Миңлекамалның исә ниндидер реаль булмаган шәхес түгел, ә нәкъ менә җир кешесе, сәләтле хатын-кыз җитәкче, тәрбияче итеп күрсәтелүе драманың ышандыру көчен арттыра. Әлбәттә, тәнкыйтьче җитешсез якларны да төшереп калдырмаган: артык картиналардан, вакыйгалардан читләшү – әнә шундыйлардан. Шуңа да карамастан, Г. Кашшаф М. Әмирнең бу әсәрен сугыш тематикасын яктырткан иң уңышлы үрнәкләрнең берсе, дигән нәтиҗә чыгара.

[1] Кашшаф Г. Гадел Кутуй // Совет әдәбияты. 1945. № 7. Б. 60.
[2] Кашшаф Г. Патриотизм көче // Совет әдәбияты. 1945. № 5. Б. 65.

1945 елда тәнкыйтьче Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» җыентыгына карата бәяләмә белән чыгыш ясый. Язучы әлеге җыентыктагы әсәрләрен, сугыш чоры «чебешләре», дип атап, укучысы алдында үзенә күрә аклана сыман. Менә шул керештә китерелгән сүзләр Г. Кашшафка хикәяләрне тикшерә башлау ноктасы булып тора. Әсәрләрне кимсетеп бәяләү белән тәнкыйтьче килешми. Аның уенча, сугыш елларында да Ф. Хөсни югары дәрәҗәдәге сәнгать җимешләре иҗат итә, мисал итеп ул «Хуторда», «Түбән оч» хикәя-очеркларын китерә.

Ф. Хөснинең иҗатына хас төп фикерләр «Авылда яз» очеркында түбәндәге юлларда ачыла, дип яза тәнкыйтьче: «Чырайсыз җитдилек дәгъва итмим мин, әгәр тормышның вак кына лепердәүләре һәм йөрәкнең тиле шуклыгы дөрес эләгеп кала икән, мин бик канәгать»[1]. Әмма барлык әсәрләр дә әлеге таләпләргә җавап бирми. Тәнкыйтьче, аларның күбесенә тукталып, шушы хакыйкатьне укучыга да җиткерергә тырышкан. Шулар арасында «хисләнү җимеше» – «Йөзек кашы» повесте. Г. Кашшаф бу әсәргә киң туктала. Әсәрнең сюжеты, Айдар образының холкы, эш-гамәлләре тәфсилле тикшерелә. Тик мәкалә авторы әлеге образның кайбер адымнарын чынбарлыкка туры килми, совет чынбарлыгын дөрес, реаль чагылдырмый, дип белдерә. Айдар әсәрдә үзенең кискен гамәлләре белән хискә бирелә, артык хыял белән мавыга. Тәнкыйтьченең язучыны аклавы түбәндәге юлларда күренә: «Авторның каршы килүе мөмкин: «Айдарның бу адымнары революциягә чаклы эшләнә һәм караңгы тормышта яшәгән кеше теләсә нинди акылсызлык күрсәтергә хәзер», диюе бар. Бу кадәресе дөрес. Ф. Хөсни яктырткан тормыш әле тулысы белән революциягә чаклы бара»[2]. Инде дә килеп, сугыш вакытында кичкән вакыйгалардан соң да геройларның әнә шул «революциягә чаклы канатланган» хыялларының әсәрдә мул итеп бирелүе тәнкыйтьче тарафыннан язучының нәтиҗәләр ясый белмәвеннән, «чебешләрне иртә чыгаруыннан», дип санала. Әлбәттә, бүгенге укучы өчен әлеге анализ сәер

[1] Кашшаф Г. Чырайлы җитдилек һәм реаль хисләр өчен // Совет әдәбияты. 1945. № 8. Б. 69.

[2] Шунда ук. Б. 71.

булып тоелыр иде. Заман, совет хакимиятенең әдәбиятта да үз сәясәт үткәрүе исә нәкъ менә шуннан күренеп тора. Язучы-шагыйрьләрнең һәр иҗат җимеше марксистик-ленинчыл тәгълиматка туры килергә тиеш була. Тәнкыйтьчеләрнең дә бу чор вазифалары – әнә шундый тикшерүләр үткәреп, әдәбиятның «дөрес» юлдан үсешен тәэмин итү.

Г. Кашшаф язучының хатын-кызларга карата булган тупас карашы белән килешми. Ул моны берничә героиня мисалында аңлатып күрсәтә һәм Ф. Хөснине рус әдәбияты классикларыннан, татар әдәбиятында бирелгән матур образлардан үзенә нәтиҗәләр чыгарырга чакыра.

Мәкаләдә Ф. Хөснинең тел-стиль чараларына шактый урын бирелгән. Тәнкыйтьче аның әле эзләнә баруын, авторның теле төрле кытыршылыклардан азат булмавын, кайбер хикәяләрдә хәтта бер үк җөмләләр дә кабатлануын билгели. Әсәрдәге тел байлыгы, канатлы сүзләрнең, урынлы эпитетларның кулланылуына карата Ф. Хөсни үз фикерен «Җанлы образны яклап» исемле мәкаләсендә Л. Җәләй белән әдәби бәхәскә кереп яза: «Эчтәлеге буш, формасы эшләнмәгән чиле-пешле бер әсәрне, әгәр ул матур тел белән язылса, рәхәтләнеп аклап һәм укучының каты тәнкыйтеннән саклап алып калып була имеш! Нәрсәдер бирәдә очы-очка ялганмый, Җәләй ага! әдәби әсәрдә тел үзеннән-үзе генә матур да була алмый. Әдәби әсәр бик күп кисәкләрдән торган бөтен бер организм ул»[1]. Г. Кашшаф мәкаләсендә әнә шундый фикерләрнең бирелүе уңышлы килеп чыккан. Шуның аша без авторның иҗатка, һәр тудырган әсәренә нинди мөнәсәбәт белән каравын сиземли алабыз. Бу исә укучыны иҗат дөньясына чакыра, аның асылы турында уйланырга мәҗбүр итә.

Г. Кашшафка хас сыйфатларның берсе – үз эшенә тугры булу, таләпчәнлек. Әлеге күренеш аеруча аның хатларында, язып барган көндәлекләрендә чагылыш таба. Язмаларында тупланган уйлану-борчылуларын ул укучысы белән дә бүлешә. «Куен дәфтәреннән» мәкаләсе шундый фикерләрнең кайберләрен җиткерә.

[1] Кашшаф Г. Чырайлы җитдилек һәм реаль хисләр өчен // Совет әдәбияты. 1945. № 8. Б. 74.

1946 ел. Тукайның тууына 60 ел тулган булыр иде. Яшьли дөньядан киткән һәм татар халкы өчен бай мирас калдырган шагыйрьгә багышланган әдәби әсәрләрнең аз булуы борчый тәнкыйтьчене. Г. Кашшаф фикеренчә, укучы Ә. Фәйзи трагедиясе белән генә канәгать булып калырга тиеш түгел. Бөек Тукайның хатлары, кульязмалары, аның аралашу даирәсе тиешенчә тикшерелмәгән. Шуңа да тәнкыйтьче аның биографиясен тулысынча өйрәнеп, яшәү мохитен күзәтеп чыкканнан соң, Тукайның җанлы образын тудырырга өнди.

Мәкаләдә күтәрелгән проблемаларның тагын берсе әсәрләрнең паспортларына кагыла. Тәнкыйтьче, әдәбият белеменә, аның тарихына бу паспортларны булдыру мөһим эш, дип саный. Әсәрләрнең язылу вакыты, язылу урынына карап, чорны, иҗтимагый тормышны, шәхесләрнең бер-берсенә карата булган мөнәсәбәтләрен тулырак аңларга мөмкин. Әлеге фикерен дәлилләп, ул Дәрдемәнд һәм замандашы С. Хәким иҗатларына игътибарын юнәлтә. Чыннан да, әгәр без Дәрдемәнднең кайбер шигырьләренең язылу вакытын белгән булсак, аның күп кенә сәяси карашлары, җәмгыятькә, тормышка булган мөнәсәбәте безнең өчен ачыграк күзалланыр иде. Бөек Ватан сугышы елларында С. Хәким шигырьләренең кайсы фронтта, нинди вакытта язылуыннан чыгып, тәнкыйтьче белдерүенчә, тарих өчен дә, сугыш чоры әдәбият тарихы өчен дә кызыклы һәм чыннан да реаль булган фактларны теркәү мөмкинчелеге ачыла. Әлбәттә, Г. Кашшафның әдәби әсәрләрнең паспортларын булдыру турында язылган бу күзәтүләре хәзер дә урынлы һәм мөһим.

Алда билгеләп үтелгәнчә, совет чорында әдәбият илдәге идеологияне пропагандалау, аны дөрес юлга юнәлтүнең бер чарасы булып торган. Шуңа да ул елларда әдәби журналларның эчтәлегендә, шул исәптән «Совет әдәбияты»нда да, юлбашчыларның төрле чыгышлары, партия карарлары, съездларның нәтиҗәләре һ.б. белән очраша алабыз. Г. Кашшаф та партия карарларын алга сөрү, сайлау кампанияләре алдыннан вакытлы матбугат битләрендә чыгышлар ясый. Аеруча 1946 елда аның мондый мәкаләләре активлашып китә. Мәсәлән, «Сайлау кампаниясе һәм язучылар» дигән

язмасында язучыларның агитколлективларда актив катнашуы катkат ассызыклана.

Сугыш кырында батырларча һәлак булган Ф. Кәримнең үлүенә бер ел тулуга багышланган мәкаләсендә Г. Кашшаф аны: «... үз тормышында да шаян табигатьле, шат күңелле, күзләре белән көлеп, авыз кырыйларына иркәләү, ярату һәм юмор сызыклары чыгарып йөри торган шагыйрь иде. Бу сыйфат аның иҗатында да тулы чагыла», – дип характерлый[1]. Менә бу юллар шушы мәкаләдән алынган иң кыйммәтле мәгълүмат.

Бөек Ватан сугышы еллары безнең илдә төрле өлкәләрнең ни дәрәҗәдә үсеш алуына игътибарны юнәлтергә мөмкинлек бирә. Әйтергә кирәк, әдәбият хаклы рәвештә менә шушы сугыш елларында халыкка аеруча якынайды. Сугыш елъязмалары, хатлар, очерклар... – болар барысы да авыр фронт вакыйгаларын сурәтләделәр һәм халык тарафыннан якын кабул ителделәр. Сугыш елларында татар әдәбиятының торышы хакында Г. Кашшаф «Татар совет әдәбиятының мөһим бурычлары» дигән мәкаләсендә язып чыга. Беренче чиратта, «Совет әдәбияты» журналының тиражы өч мәртәбә артты, дип куана автор. Икенче яктан исә, борчылыр сәбәпләр дә шактый икән. Тәнкыйтьче фикеренчә, сугышка кадәр һәм сугыш елларында да татар прозасы бик артта кала, балалар әдәбияты һәм драма әсәрләре үсеш алмый. Моның сәбәпләре дә ачык кебек: күп кенә язучы-шагыйрьләр Ватан данын яклаучы булып фронтка китә, ә андагы шартларда иҗат итү һәркемнең дә хәленнән килә торган җиңел эш түгел. Әмма Г. Кашшаф партия, Ленин-Сталин наказларын истә тотып, язучыларны активрак иҗат итәргә чакыра. Татар әдәбияты, аның үсеше һәм киләчәге өчен борчыла.

Тәнкыйтьче әдәбиятка кагылышлы һәр яңалыкны отып калырга тырыша сыман. Әнә шул сүзләрне раслагандай, ул Сахаб Урайскийның «Яз таңында» җыентыгына бәя бирә. Совет идеологиясенең асылына төшенеп, иҗат методын дөрес сайлау пропагандасыннан башланган мәкаләдә, алга таба, С. Урай-

[1] Кашшаф Г. Ул көрәш моңнарын җырлады // Совет әдәбияты. 1946. № 2. Б. 114.

скийның шигырьләре әнә шул таләпләргә җавап бирми, дип кискен бәя бирелә. Шуннан соң гына мәкалә авторы шигырьләргә күчә. Шагыйрь иҗатын Такташ традицияләрендә үстерергә тырышкан, әмма бу бик үк уңышлы килеп чыкмаган. Шигырьләрнең күбесе мәхәббәт турында. Тәнкыйтьче, С. Урайский тасвирлаган хисне чынбарлыкка туры килми, ясалма булып күренә, дип яза[1]. Гомумән, бу җыентык С. Урайскийның ашыгып язылган әсәрләре тупланмасы, дигән нәтиҗә чыгарыла, шуңа автор мәкаләсен «Ил авазы булып яңгырый алмаган җыентык» дип исемли.

Шул ук 1946 елда Г. Кашшаф Т. Гыйззәтнең пьесалар җыентыгына бәяләмә бирә. Китапта революциягә чаклы булган татар тормышын чагылдырган һәм хезмәт ияләренең яктылыкка, гаделлеккә омтылуларын күрсәтүне максат итеп куйган «Шомлы көннәр», «Даулы көннәр», «Кыю кызлар», «Ялкын» («Чаң») исемле әсәрләр тупланган. «Даулы көннәр»дән кала башкалары Татар дәүләт академия театрында куелганнар. Тәнкыйтьче һәр әсәргә аерым тукталуны кулай тапкан. Нигездә, әсәрләрнең сюжетына, аларда чагылган совет чоры дөреслегенә зур басым ясала, тәнкыйтьче персонажларның теленә, берничә әсәрдә кабатланган фразаларга игътибар итә, язучыны бу җитешсезлекләрдән арынырга чакыра. Әмма әсәрләрнең сәнгати кыйммәте тиешенчә бәяләнгән дип әйтеп булмый. Конфликт бирелеше, проблемалар актуальлеге бер яклы гына карала. Мәсәлән, «Җиде кыз» исемле бәеткә нигезләнеп язылган «Кыю кызлар» комедиясен алыйк. Г. Кашшаф аңа аз туктала, тик шунда да бер үк фикерне кабатлый: «Автор үзе дә моны халык экиятеннән файдаланып язуын әйтә. Ләкин бу «әкият»нең нигезендә феодализм чорының чынбарлыгы ята»[2]. Комедия мәдрәсә, андагы бозык күренешләрне, мулла-ишаннарның катып калган карашларын, хатын-кызга булган мөнәсәбәтне гәүдәләндерә. Ягъни язучылар әле һаман шул үткән заманны фаш итеп яшиләр, бүгенге көннең таләпләренә җавап

[1] Кашшаф Г. Ил авазы булып яңгырый алмаган җыентык // Совет әдәбияты. 1946. № 9. Б. 120.

[2] Кашшаф Г. Пьесалар җыентыгы // Совет әдәбияты. 1946. № 10. Б. 96.

бирердәй әсәрләр тудырылмый, дигән нәтиҗәгә килә тәнкыйтьче. Мәкалә ахырында Т. Гыйззәт «бытовой драмалар» иҗат итүдә уңышка иреште, диелә. Шуларга мисал итеп «Шомлы көннәр», «Кыю кызлар» китерелә. Әмма хәзерге тарихи чынбарлыкны чагылдыру юлында драматургка күп тырышырга кирәк әле – тәнкыйтьче аңа әнә шундый киңәшен бирә.

Г. Кашшафның иҗатташларына багышлап язылган тәнкыйди язмалары бар. Ул аларны, очерклар, дип атый. Шуларның икесе 1947 елда «Совет әдәбияты» битләрендә басыла. Әйтергә кирәк, әлеге мәкаләләр очерк дип аталса да, аларда без язучыларның иҗатларына бәяләмәне дә күзәтәбез. Дөрес, бу – очеркларда үзмаксат түгел, ләкин әдипнең эшчәнлегеннән аның иҗатын аерып алып булмый. Т. Гыйлаҗев бу тәнкыйть жанрын, иҗат очеркы, дип атап уза[1]. Г. Кашшаф очерклары Н. Баян һәм К. Нәҗми турында. Икесе дә язучыларның биографияләренә кагылышлы фактлардан башланып китә. Бу җөмләләр гади тел белән язылган, сыйфатлауларга күп урын бирелә. Автор укучысын датадан датага күчеп ялыктырмый. Иҗтимагый тормышның активлыгыннан кызып киткән иҗат дәрте яшь каләм тибрәтүчене беренче әсәрләрендә хаталардан азат итми. Бу хакта түбәндәге юллардан беләбез: «Форма белән мавыгып китеп, әсәрләренең эчтәлегенә, идеясенә зарар китергән вакытлар да булды. Иҗатының беренче адымнарында биргән хикәяләре күп кенә кимчелекләрне, ялгышларны эчләренә алалар»[2]. Үзендә көч табып, К. Нәҗми бу хаталарны төзәтү юлына баса һәм Бөек Ватан сугышы елларында профессиональ язучылар рәтенә керә. Язучының тәнкыйтьче-публицист буларак үзенчәлеген Г. Кашшаф болай билгеләде: «Үз вакытында татар совет матбугатын шаулаткан «???» билгеләре астында басылган фельетоннары, буржуаз вкусларга, обывательчелеккә каршы юнәлгән публицистик мәкаләләре, буржуаз язучыларның чыгышларына отпор бирә торган тәнкыйть мәкаләләре – Кави Нәҗмине үткен телле, кыю фикерле публицист итеп, совет

---

[1] Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 157.

[2] Кашшаф Г. Кави Нәҗми // Совет әдәбияты. 1947. № 2-3. Б. 135.

әдәбиятының сафлыгы өчен килешмәүчән, принципиаль көрәшче итеп чыныктыралар»[1]. Очеркта аның иҗаттан тыш эшчәнлегенә басым ясалган: «аеруча мәхәббәт һәм ярсулык белән» ул «Батырлар китабы»н төзү эшендә катнаша, Советлар Союзы Герое исеме алган данлы көрәшчеләр турындагы китапны чыгаруда күп көч куя. Шулай ук ул язучының матур тәрҗемә үрнәкләре бирүен, язучыларның партия оешмасы секретаре булып эшләвен, әдәби хәрәкәттә актив катнашуын да ассызыклап уза.

Ике язучыны берләштерүче нокта – Хәрби мәктәп. Егерменче елларда биредә К. Нәҗми мәктәпнең комиссары була һәм курсантларга әдәбият укыта. Бу дәресләр Н. Баянның да әдәбиятка булган мәхәббәтен үстерәләр. Тәнкыйтьче язганча, шагыйрьнең беренче иҗат җимешләрендә җитешсезлекләр булса да, алар безгә шул чор яшьләренең аң чагылышын өйрәнү өчен әһәмиятле. Чыннан да, әдәбият совет хакимиятенең күрсәтмәләре буенча яши башлаганчы, иҗатчыларның чын йөзләре, әле яңа формалашып килүче дөньяга карашлары әсәрләрендә чагыла.

Мәкаләдә шулай ук укучы өчен Г. Кашшафның да Н. Баян белән дуслыгы ачылып китә. 1944 елда шагыйрь фронтта язган шигырьләрен тәнкыйтьче исеменә җибәрә һәм аларны сугыш беткәнче сакларга куша. 1947 елда, шагыйрь үлүенә ике ел тулганнан соң, Г. Кашшаф бу шигъри юлларны укучыга җиткерә. Шул рәвешле, бу кечкенә генә мәкаләдән дә без язучылар, иҗатташлар арасындагы мөнәсәбәтләр, совет чоры татар әдәбиятының тарихы язылуын күрә алабыз.

К. Нәҗми кебек үк, Н. Баян да оста каләм иясе буларак күзаллана. «Нур Баянның әдәби мирасы шактый бай һәм киң. Ул Такташ шигъри мәктәбенең иң якты вәкилләреннән һәм иң эшлеклеләреннән иде. Такташның шигъри стилен, аның оптимистик рухын, романтик җылылыгын иҗади төстә үзләштергән Баян, совет чынбарлыгын чагылдырып, дистәләрчә әсәрләр бирде»[2].

---

[1] Кашшаф Г. Кави Нәҗми // Совет әдәбияты. 1947. № 2–3. Б. 137.
[2] Кашшаф Г. Нур Баян // Совет әдәбияты. 1947. № 4. Б. 90–94.

К. Нәҗминең хикәяләр җыентыгы басылып чыгу уңаеннан, Г. Кашшаф «Кызыл Татарстан»да мәкаләсен бастыра. Тәнкыйтьче: «Язучы баштагы елларда пролетариат әдәбиятының стиль, формаларын эзләп, төрле экспериментларга бирелде. Шуның нәтиҗәсендә ул формаль алымнар, натуралистик детальләр белән мавыгып, хикәяләренең идеясен сыекландырды, социаль эчтәлеген тоныкландырды», – дип билгели[1]. Бу җыентык язучының әнә шул хаталарны төзәтү юлына басуын күрсәтеп тора. Кайбер хикәяләр яңадан эшкәртелсә, җыентыктагы аерым хикәяләр совет чоры укучысы таләпләренә тулысынча туры килә, дигән нәтиҗә чыгарыла. Мәкалә авторы К. Нәҗминең тел байлыгы үсешен «мавыктыра торган музыкаль тел, оригиналь, куе образлар, әйбернең бер характерлы деталеннән катлаулы чагыштырулар, тапкыр метафоралар табып, җанлы картиналар» бирүендә күрә.

«Ул үзен тапканчы, үзенең хисләрен бер тәртипкә салганчы байтак эзләнде, иҗат тәҗрибәләре ясады», – дип яза Г. Кашшаф Ә. Фәйзи турында. «Әхмәт Фәйзинең поэтик йөзе» дигән мәкаләне без шулай ук әдәби очерк дип атый алабыз. Язма зур күләме, киң тикшеренү алып баруы белән аерылып тора. Ә. Фәйзине тәнкыйтьче гаять үзенчәлекле шагыйрь дип карый. Әлеге үзенчәлек берничә моментта ачыла:

1) аның иҗаты романтик күтәренке рухта ага, шигъриятендә утлы пафос, рухи ялкын, фикри көч бар;

2) гаять киң мәйданда, чикләнмәгән киңлек һәм иркенлектә йөзәргә, эпохалар, эралар белән эш итәргә, космик масштабларда очарга ярата;

3) ул космополит шагыйрь, ул милләт, билгеле бер төбәк рамкаларыннан атлап чыга, гомуми кешелек интересларына, космик киңлеккә омтыла;

4) контрастлар сөюче шагыйрь;

---

[1] Кашшаф Г. Кави Нәҗми хикәяләре // Кызыл Татарстан. 1947. 19 апрель.

5) эпик җырлар шагыйре, тирән фикерләрне алга сөрүче, акылны алгы планга этәрүче шагыйрь[1].

Шушы юлларда кулланылган космополитизм сүзе тәнкыйтьчеләр тарафыннан Г. Кашшафның хатасы итеп табыла. Бу хакта, мәсәлән, К. Фасиев сүзләрен китерик: «Татар совет әдәбиятында күренекле тәнкыйтьчеләрнең берсе – Гази Кашшаф. Ләкин, әйтергә кирәк, ул да хаталардан һәм идеологик абынулардан азат түгел. Г. Кашшаф иптәшнең Ә. Фәйзи поэзиясендә космополитизмны күрүе һәм аны уңай бер нәрсә итеп тануы турында матбугатта язылган иде инде»[2]. Моңа җавап рәвешендә тәнкыйтьче түбәндәгеләрне яза: «Әхмәт Фәйзинең поэтик йөзе» исемле мәкаләдә партияле таләпчәнлек, принципиальлек җитми. Мәкаләмдә «космополит» дигән сүз Ә. Фәйзигә карата хата алынган. Ләкин ул сүзне куллангач, аңа политик бәя бирергә кирәк иде. Космополитизмга политик бәя биреп, аның гаять дәрәҗәдә зарарлы булуын һәм патриотизм белән һичбер алыш-биреше юклыгын, черек буржуа идеологиясе өчен генә хезмәт итүен фаш итәсе урында, мин, космополитизмга планетар аңлатма биреп, аны географик космизм төсендә күрсәткәнмен. Мәкаләнең төп хатасы шунда»[3]. Шушы нәтиҗәләрдән соң, тәнкыйтьче шагыйрьнең әсәрләрен тикшерүгә күчә. 1933 елда «Флейталар» поэмасын иҗат иткәнгә чаклы Ә. Фәйзинең шигърияте йомшак дип бәяләнә. Нәкъ менә шушы поэмадан соң шагыйрь иҗатында яңа – үсеш чоры башлана. «Дала һәм Кеше», «Кара таш ник дәшми?» – Ә. Фәйзинең сәләтен ачкан иҗат җимешләре дип кабул ителә. Сугыш елларында иҗат ителгән балладалары, әкиятләре дә алда каралган үзенчәлекләргә ия. Иҗат очеркының ахырында тәнкыйтьче, үзенең алдагы язмаларына каршы килеп, кыскача биографик материалларга да тукталып китә, игътибарын Ә. Фәйзинең Тукай һәм Пугачевка багышланган драмаларына юнәлтә. Бу язмада татар сәнгате өчен тарихи факт – Ә. Фәйзинең Пугачев әсәре

---

[1] Кашшаф Г. Әхмәт Фәйзинең поэтик йөзе // Совет әдәбияты. 1947. № 6.

[2] Фасеев К. Совет әдәбиятының һәм сәнгатенең яңа, көчле күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1949. № 6. Б. 139.

[3] Кашшаф Г. Тәнкыйть мәсьәләләренә карата // Совет әдәбияты. 1949. № 7. Б. 90.

нигезендә «Качкын» либреттосын язуы, Н. Җиһановның шушы либретто буенча беренче операсын иҗат итүе һәм шул опера белән 1939 елның 17 июнендә Казанда Татар дәүләт опера һәм балет театрының тарихы башлануы хәбәр ителә.

Г. Кашшафның тәнкыйте аша узган тагын бер җыентык – Г. Әпсәләмовның «Зәңгәр кыя»сы. Әлеге китапка төрле вакытта газета-журналларда басылып чыккан хикәяләр тупланган. Тәнкыйтьче фикеренчә, язучы тәнкыйтьне кабул итеп, шактый төзәтүләр ясаган, әсәрләрне тиешенчә эшкәрткән. Мәкаләдә «Зәңгәр кыя», «Байрак», «Хәйбулла солдат», «Зәңгәр иртә», «Кызыл ракета» һ.б. хикәяләрнең эчтәлекләрен, геройларның эш-гамәлләрен күзәтеп барышлый, тәнкыйтьче һәр күренешне логик, чынбарлыкка туры килү-килмәү ягыннан аңлатып барырга тырыша. Ул әсәр геройларының хәленә кереп, барлык вакыйгаларны алар белән бергә кичерә. Монда, билгеле, авторның бик күп вакыйгаларны сугышта күреп кичерүе дә үз урынын алгандыр. Г. Кашшаф тарафыннан ук шундый нәтиҗә бирелә: «Әпсәләмов туплаган хикәяләрдә – безнең чорның геройлары сурәтләнә. Аларның батырлыгы табигый итеп бирелгән, мораль яктан өстен булулары, рухи байлыклары, патриотик сыйфатлары, кешелек характерлары: халыклар дуслыгы, окоп дуслыгы, туганлык, мәхәббәт һ.б. – боларны һәрбер хикәядән табарга мөмкин. Алар реаль буяуларда биреләләр, ышандыралар, табигый килеп чыгалар»[1]. Әлбәттә, җыентыкка бәя бирүче кимчелекле якларны да барлый: читкә тайпылу, ясалмалык («Ана йөрәге»), «очерксыман сөйләп чыгу» («Кызыл ракета»), әмма, гомумән алганда, Г. Әпсәләмовның әлеге иҗат җимешләре тәнкыйтьчедә язучы өчен куану тойгысы уята.

1947 елда «рус әдәбияты тәэсирендә формалашкан» татар совет әдәбияты да үзенең 30 еллыгын билгеләп уза. Бу дәвердә ниләр эшләнгән, әдәбиятта нинди үрләр яуланган? «Татар совет әдәбиятының 30 еллыгы» дип аталган күзәтү мәкаләсе нә шул хакта. Әлеге 30 еллык тарихи яктан аерым унъеллыкларга бүленеп тикшерелә. Тәнкыйтьче шушы елларда иҗат иткән әдипләрне,

[1] Кашшаф Г. Зәңгәр кыя // Совет әдәбияты. 1947. № 7. Б. 100.

язылган әсәрләрне барлый, аларның чор өчен кыйммәтле һәм кимчелекле якларын ачарга тырыша. Утызынчы еллардагы һәм сугыш чорындагы әдәбиятка урын шактый киң бирелә. Аерым алганда, автор М. Әмир, Ф. Хөсни, Ә. Ерикәй, Г. Кутуй, Т. Гыйззәт, Ә. Исхак, К. Нәҗмиләрнең аерым әсәрләренә туктала, кыскача бәя бирә, М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасына туктала. Күзәтү мәкаләсендә гомуми планда бик күп язучыларның исемнәре атала. Тәнкыйтьче татар совет әдәбиятының үсешен рус әдәбияты белән параллельләр үткәреп чагыштырып бара. Г. Кашшаф татар әдәбиятының да үзенчәлекле үсеш баскычларын күздән ычкындырмый. Мәсәлән, сугыш елларында тарихи драмаларның иҗат ителүе, очеркның активлашуы, «зур полотнолы» чәчмә әсәрләрнең юклыгы. Тик болар барысы да рус әдәбияты ирешкән «бөек»лектән карап тикшерелә. Гомумән алганда, тәнкыйтьченең бу күзәтү мәкаләсен алда язылып килгән күп кенә язмаларына бер нәтиҗә рәвешендә кабул итәргә кирәк.

Язучылык, фәнни эш белән шөгыльләнү өстенә, Г. Кашшафның редакторлык эшен алып баруы хакында беренче бүлектә әйтелгән иде инде. Бу юнәлештә ул күп кенә язучыларның китапларына кереш сүзләр дә яза. Шундыйлардан Г. Кутуйның сайланма әсәрләр җыентыгын атап китәргә була. Әлеге кереш сүздә тәнкыйтьче шагыйрь-язучының биографиясен һәм тормыш юлын киң планда яктыртуны күздә тоткан. Материал Г. Кутуй, аның бертуган апасы Зәйнәп Кутуева истәлекләренә нигезләнеп язылган. Биредә шагыйрь һәм язучының ата-анасы, укытучылары, дуслары турында шактый бай мәгълүмат бирелә. Пушкинга ияреп язган беренче шигырьләре, Маяковский әсәрләре белән мавыгу – тәнкыйтьче барысын да җентекләп барлап бара. Г. Кашшаф шулай ук язучының иҗаты үсешенә йогынты ясаган моментларга да туктала: «Футуризм төсендә тагылган иске дөнья Г. Кутуйның беренче иҗат чорында үзен бик нык сиздереп торды. Үтә сул фразалар артына яшеренгән сугышчан формализмны популярлаштырган «ЛЕФ» журналыннан юнәлеш алып, ул 1942 елның башында «Сулф» (Сул фронт) исемле әдәби оешманы формалаштырды, аның җитәкчеләреннән булды. Г. Кутуй үзен «мин – футурист» дип игълан итте, футуризм аша гына яңа культура, яңа

әдәбият тудыру мөмкин дигән карашны яклады һәм яңа – совет социалистик культурасын төзү өчен узган культураның роле барлыгын күрә алмады»[1]. Ягъни тәнкыйтьче язучының беренче чор иҗатында күзәтелгән ялгыш карашларын билгели. Алга таба исә әлеге зыянлы фикерләрдән арыну юлы күзәтелә. Г. Кашшаф Г. Кутуйның төрле жанрларда актив иҗат итүен дә ассызыклый. Бигрәк тә проза әсәрләренең сюжет, тема бирелешенә игътибар итә, әхлакый-эстетик казанышлары турында куанып сөйли. Аеруча ул совет семьясының гармонияле яшәвен калкытып куйган әсәрләргә туктала (Г. Кутуй «Фарзана», «Тапшырылмаган хатлар», Һ. Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе», «Югалган матурлык», Ш. Камал «Ут»). Нәсер-очерклары арасында Г. Кашшаф «Без – Сталинградчылар» исемле нәсергә югары бәя бирә, аны «аеруча уңышлы, публицистик ялкын белән язылган» әсәр буларак бәяли. Әйтергә кирәк, Г. Кашшаф үз максатына ирешә алган: кереш сүздә Г. Кутуй шәхесе – ялкынлы шагыйрь-патриот, сюжетлары үзенчәлеккә ия әсәрләр авторы, актив җәмәгать эшлеклесе буларак та күз алдына килеп баса. Тәнкыйди караш биредә күпмедер дәрәҗәдә чагылса да, ул бик урынлы кулланылган, Г. Кутуйны социалистик реализм методын үзләштергән чын совет язучысы итеп таныта.

1953 елда М. Гафуриның «Сайланма әсәрләр» җыентыгы дөнья күрә. Китапның кереш сүз авторы шулай ук Г. Кашшаф. 1905 – 1907 ел революцияләре заманында әдәбиятка килгән М. Гафури иҗатына тәнкыйтьче гомуми күзәтү ясый, аны укучыга халык язучысы итеп таныта. Сәяси лирикага караган шигырьләр иҗат иткән Г. Камал һәм М. Гафури татар әдәбиятының совет чорын башлап җибәрүчеләр рәтенә кертелә. М. Гафуриның Октябрь революциясенә кадәр натурализм элеменлары, дидактизм, схематизм, ярлылар язмышы, яхшылык, гуманизм идеяләре белән сугарылган иҗатын Г. Кашшаф тәнкыйтьләп чыга. Шулай ук, Г. Камал, Ш. Камал, М. Фәйзи, М. Гали кебек, революцияне һичбер икеләнүсез кабул иткән М. Гафурига совет хакимияте чорында

---

[1] Кашшаф Г. Гадел Кутуй (Язучының тормыш һәм иҗат юлы) // Кутуй Г. Сайланма әсәрлә. – Казан: Татгосиздат, 1953. Б. 6.

чын язучы буларак үсәргә мөмкинчелек тууын билгеләп үтә. Аның азатлык көрәше, иҗтимагый-сәяси көрәш идеяләре белән януын һәм шуларны әсәрләрендә дә ачык чагылдыруын ассызыклый. М. Гафуриның бер үк вакытта прозаик һәм шигырьләр авторы булып, ике юнәлештә дә уңышлы иҗат итүен дәлилли.

Г. Кашшаф рус телендә дә мәкаләләр яза. Аларның күбесе «Красная Татария» газетасында басылып киләләр. Мәсәлән, 1948 елда «Наш друг» исемле мәкаләсендә М. Горькийның татар совет әдәбиятына якынлыгы, йогынтысы ассызыклана. Г. Коләхмәтов белән, Ш. Камалның бөек рус язучысының иҗаты, шәхесе белән горурланып, татар әдәбиятына да матур үрнәкләр бирүе турында хәбәр ителә.

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1946 елгы 14 август «Звезда» һәм «Ленинград» журналларына карата чыккан карарга 2 ел тулу уңае белән, Г. Кашшаф «Кызыл Татарстан»да шушы ике ел буена күзәтүләрнең нәтиҗәсе хакында мәкалә белән чыгыш ясый. Әлеге карар нигезендә язучылар әдәби әсәрләрне партиянең төп идеологиясенә таянып язарга тиеш булалар. Тәнкыйтьче мондый иҗат җимешләре арасында Г. Бәшировның «Намус», А. Шамовның «Миңнур карт», М. Әмирнең «Тормыш җыры», И. Гази белән, Г. Әпсәләмовның сугыш турындагы повестьларын санап уза. Социалистик җәмгыятьне дөрес чагылдыру, сугыш темасы белән беррәттән, мәкалә авторы тарихи темага да аерым туктала. Аның фикеренчә, сугышка кадәр татар әдәбиятында тарихи шәхесләрне сурәтләгән уңышлы әсәрләр арасында бары тик Ә. Фәйзинең «Тукай» әсәрен һәм М. Гали белән Х. Уразиков иҗат иткән «Каюм Насыйри» драмасын атап була. Бу тема татар әдәбиятында барлык жанрларда да чагылмый, ди тәнкыйтьче. Шушы соңгы ике елда басылган Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов», К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары гына исә бу җитешсезлекне тутыра алмый. Г. Кашшаф әдәби очерк жанрының җанлануын (Г. Әпсәләмов, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, Ф. Хөсни, Г. Галеев һ.б.ның әсәрләре), ә «көчле политик лирика, социаль пафоска ия булган поэмалар, сюжетлы җырлар тудыру юлында» татар әдәбиятының әле шактый эшлисе барлыгын раслый.

Шушы урында кырыгынчы елларның әдәбияты һәм тәнкыйтенә бер нәтиҗә чыгару максатыннан, Г. Кашшаф «Тәнкыйть мәсьәләләренә карата» исемле күзәтү мәкаләсендә мондый хакыйкатьне ача: «Кызганычка каршы, совет әдәбиятының сугышчан бер тармагы – әдәби тәнкыйть үз бурычларын бик йомшак үтәп килә. Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть безнең җәмгыятебезне үстерү, алга илтү чарасы һәм көче булып тора икән, әдәбиятта да тәнкыйть гаять зур корал һәм юнәлеш бирүче көч... Ләкин безнең татар әдәбияты өлкәсендәге тәнкыйть бик зәгыйфь һәм тәнкыйтьчеләребез дә сан ягыннан бик аз. Соңгы берничә ел эчендә аерым китап булып чыккан әдәби тәнкыйть материалларыннан бары Г. Халитнең «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре» исемле әсәрен генә күрсәтергә мөмкин»[1]. Алга таба мәкаләдә тарихи ядкярләрне кайтару юлында күп тырышлык куйган Н. Исәнбәт һәм Л. Җәләй эшчәнлеге, Г.Сәгъдинең 1926 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» кискен тәнкыйтьләнә. Әдәбият тарихы китабын ул, гыйльми, марксистик концепциясе нигезендә язылмаган хезмәт, дип бәяли.

1950 елда М. Гафуриның тууына 70 ел тулу уңае белән тәнкыйтьче, аның иҗат үсешен укучының исенә төшереп узу максатыннан, «Кызыл Татарстан»да мәкалә бастыра. Әлбәттә, мондый кечкенә күләмле язмалар да чор өчен, әдәбият тарихы өчен мөһим роль башкаралар, язучының иҗатына яңадан мөрәҗәгать итәргә бер этәргеч тә булып торалар.

1950 елда язучыларның әдәби хәрәкәтенә йомгак ясап, Татарстан совет язучыларының II съезды булып уза. Анда Г. Кашшаф «Татарстанда әдәбиятның яңа күтәрелеше өчен» дигән чыгыш белән катнаша[2]. Татарстан язучыларының I съездыннан соң 16 ел узгач язылган бу доклад аерым игътибарга лаек, чөнки анда Г. Кашшаф татар әдәби процессының тулаем бер чорына бәяләмә бирә.

---

[1] Кашшаф Г. Тәнкыйть мәсьәләләренә карата / Совет әдәбияты. 1949. № 7. Б. 90-91.

[2] Кашшаф Г. Татарстанда әдәбиятның яңа күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1950. № 8. Б. 65–84.

Мәкаләнең татар язучыларына кагылышлы өлеше аларның шушы елларда саны икеләтә үсүе, идея-художество ягыннан бик нык югары күтәрелүләре, күп кенә язучыларның әдәби хәрәкәтнең алгы сафына килүе турындагы хәбәр белән башланып китә. Тәнкыйтьче сугыш елларында зур күләмле әсәрнең бик аз иҗат ителүен ассызыклый. Аның фикеренчә, Ш. Камал романнарыннан соң татар әдәбиятында зур күләмле әсәрләр тумый. Бары тик К. Нәҗминең М. Горькийдан бик нык өйрәнеп, аның күрсәтүләрен истә тотып язылган «Язгы җилләр» романы гына шушы елларда партия карарларын тормышка ашыру юнәлешендә иҗат ителгән романнарның берсе булып тора. Зур күләмле әсәргә икенче мисал итеп, И.Газинең революциягә чаклы татар авылы тормышын һәм революция елларындагы күтәрелешне сурәтләгән «Онытылмас еллар» повесте китерелә. Сугыштан соң Ә. Фәйзинең «Пугачев Казанда», Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» кебек тарихи драмаларының барлыкка килүен Г. Кашшаф күңелле фактлар буларак билгеләп уза.

Г. Бәшировның социалистик хезмәт темасын яктырткан «Намус» романыннан тыш, тәнкыйтьче М. Әмирнең «Тормыш җыры», Г. Гобәйнең «Замана балалары», Г. Галиевнең хикәя-очеркларын барлый. Поэма жанрында уңышлы эшләп килүче М. Садри, Ш. Маннур, Ә. Юныс, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис, Б. Зернит иҗатлары искә алынса, драматургиядә бары тик Р. Ишморат һәм А. Әхмәтнең ике әсәре атала.

Чор әдәбиятының иң зур темаларыннан берсе буларак Г. Кашшаф Ватанны саклау темасын аерып куя. Г. Әпсәләмовны ул Бөек Ватан сугышы елларында иң актив иҗат итүче язучыларның берсе дип таный. Әлеге темага мөрәҗәгать иткән язучылар арасында И. Гази, К. Лебедев, Т. Гыйззәт, Ш. Маннур, С. Хәким һ.б ның әсәрләренә игътибар бирелә. Шул ук вакытта, язучылык эшләрен шактый акрын җәелдергән А. Шамов, Г. Иделле иҗатлары тәнкыйтьләнә, Ф. Хөсни әсәрләрендә сәнгати җитешсезлекләр күрсәтелә. Г. Кашшафның Ә. Еникигә биргән бәяләмәсе кискен яңгырый: «Ә. Еники җанлы тормыштан шактый ерак яши, шуңа күрә, бердән, ул бик акрын темп белән иҗат итә,

шуның өстенә, тормыштагы матур якларны күреп тә бетерә алмый. Вакыт-вакыт язучы тормыштан алган тәэсирен аңлатып бирүдә ялгыш юлга кереп китә; характерлы булмаган вакыйгалар, күренешләр белән мавыга»[1].

Татар совет драматургларының театрлар репертуарына шактый күренекле, тамашачы тарафыннан яратып кабул ителгән әсәрләр бирүе Г. Кашшафны сөендерә. Ләкин бу эшчәнлек, аның сүзләренә караганда, бик акрын темп белән бара һәм сыйфаты турында сүз йөртергә бәхәс калдыра. Шундый әсәрләр арасында ул Т. Гыйззәтнең «Изге аманәт», А. Әхмәтнең «Серләр», М. Әмирнең «Җыр дәвам итә» драмаларын атый. Драматургиядәге җитешсезлекләрне Г. Кашшаф бу өлкәдә тәнкыйтьнең юклыгы белән аңлата.

Әдәби тәнкыйтькә килгәндә, тәнкыйтьче түбәндәге фикерләр белән уртаклаша: «Аз булса да, әледән-әле чыгып килә торган мәкаләләр, рецензияләр, обзорлар бу өлкәдәге эшне күрсәтәләр. Х. Хәйринең «Такташ» турындагы монографиясен, Г. Халит, М. Максуд, М. Әмир, Г. Гобәй, Г. Кашшаф, М. Гайнуллин, Ш. Сайкин һ.б. мәкаләләрен күрсәтергә була. Соңгы елларда И. Нуруллин, Ә. Нигъмәтуллин, Б. Гыйззәт, Сайганов, Н. Гыйззәтуллин һ.б. яшьләрнең үсеп килүләрен әйтергә була»[2]. Г. Кашшаф язучыларның үзара тәнкыйтен дә читтә калдырмый, аның уңышлы нәтиҗәләр алып килүен, үзенең тәнкыйди иҗатына да тәэсир итүен билгеләп уза.

Тәнкыйди мәкаләләргә һәм социалистик реализм методының татар әдәбиятында җәелүенә карата Г. Кашшаф түбәндәге фикерләрен әйтә:

1) социалистик реализм мәсьәләләре тәнкыйтьчеләр тарафыннан бөтенләй яктыртылмаган;

2) әдәбиятның партиялелеге, форма һәм эчтәлек берлеге тикшерелми;

3) мәкаләләр, күбесенчә, әсәрнең реалистик булуын яки чынбарлыктан ераклашу-ераклашмавын әйтү белән чикләнәләр;

---

[1] Кашшаф Г. Татарстанда әдәбиятның яңа күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1950. № 8. Б. 73.

[2] Шунда ук. Б. 79.

4) язучыларның художество осталыгы өйрәнелми.

Бу юлларны ул, әлбәттә, билгеле бер дәрәҗәдә үз тәнкыйтенә карап та яза. Шул ук вакытта, чорның танылган тәнкыйтьче-галиме Г. Халит эшчәнлегенә дә игътибар итә. Ул аның «Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре» хезмәтенә мөрәҗәгать итеп, җитешсез якларны күрсәтергә тырышкан. «Татар әдәбиятында 20 нче еллардагы гыйсъянчылыкны Г. Халит прогрессив күренеш итеп аңлатуы белән дә социалистик реализмны боза. Такташ, Максуд, Шамов һ.б. – барысы да гыйсьянчылар булып күрсәтеләләр. Һәм гыйсъянчылык – реализмга бару итеп аңлатыла. Моның өчен ул Такташның иҗат мисалын ала. Бу – дөрес түгел. Чынлыкта гыйсъянчылык Такташны реализмга алып бармады, киресенчә, гыйсъянчылык аңа реализмга килергә комачаулап торды. Гыйсъян белән реализм арасында һичбер уртаклык юк»[1]. Гыйсъянчылык мәсьәләсен күтәргән Х. Хәйринең «Такташ» турындагы монографиясе дә кискен тәнкыйтьләнә. Шулай ук Г. Кашшаф Г. Халитның Ш. Камал һәм Ф. Кәрим иҗатларына бирелгән бәяләмә белән килешми, чөнки, аның фикеренчә, аларда социалистик реализм карашлары үзләштерелмәгән. Әдәби тәнкыйтькә кагылышлы фикерләрен йомгаклап, мәкалә авторы нәтиҗә чыгара: «Совет әдәбиятының үсеше һәм аның чәчәк атуы яшь көчләрдән башка мөмкин түгел. Яшь авторлар белән эшләүне кискен рәвештә яхшыртасы бар. Әдәби тәнкыйтьнең койрыкта сөйрәлеп баруын бетерергә, бу өлкәдә эшнәлек, семьячылык күренешләрен булдырмаска кирәк. Әдәби тәнкыйть совет язучыларының идея-художество ягыннан күтәрелүләренә булышырга тиеш»[2]. Гомумән, Г. Кашшаф татар әдәбияты алдында бик күп бурычларның киләчәктә башкарылуына өмет тота.

«Чорыбызга лаеклы художество әсәрләре бирик» мәкаләсендә тәнкыйтьче язучыларның кыска хикәяләрне аз иҗат итүенә, тәнкыйтьчеләрнең поэзиягә күз салмавына һәм шуннан үсеп чыга торган «конфликтсызлык теориясе»нә игътибар итә, әсәрләрнең

---

[1] Кашшаф Г. Татарстанда әдәбиятның яңа күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1950. № 8. Б. 81.

[2] Шунда ук. Б. 85.

сәнгатьчә эшләнеше партия тәкъдимнәренә таянып язылырга тиешлегенә басым ясый[1]. Әлеге сораулар «Тормышны тирәннән һәм дөрес чагылдыру» өчен дигән күләмле мәкаләдә дә күтәрелә. Партиянең XIX съезды һәм аның нәтиҗәләре мәкаләдә киң яктыртыла. 1951 елда «Большевик» журналында басылып чыккан Г. Бәшировның «Намус» һәм К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романнары – татар совет әдәбиятының зур казанышы буларак билгеләнә. Совет чорында әсәр кыйммәтен билгеләү критерийларын Г. Кашшаф түбәндәге юлларда ачып бирә: «Әдәби әсәрләрнең сәнгатьчә көчен һәм художество кыйммәтен рус теленә тәрҗемә ителү факты белән үлчәү көндәлек гадәткә кереп бара. Бу – бик табигый. Рус укучысы – иң культуралы, югары таләпле, нәфис вкуслы укучы. Рус телендәге әсәр башка телләргә дә тәрҗемә ителә. Шуңа күрә рус телендә басылып чыгарлык әсәр тудырырга омтылу татар совет язучысы өчен законлы күренеш»[2]. Рус әдәбиятына югары бәя биреп, татар язучыларын русчага тәрҗемә итәрлек әсәрләр иҗат итәргә этәрү, әлбәттә, зыянлы эш түгел. Тик шулай да, һәр әдәбиятның, шул исәптән татар әдәбиятының да, үз тарихы, үз үзенчәлекләре бар. Ул бары тик татар телендә генә үз кыйммәтен тулысынча саклап кала ала.

Мәкаләдә, «конфликтсызлык теориясе»нең зарарлы күренеш икәнен ассызыклау белән бергә, «кечкенә» кеше проблемасы күтәрелә. Революциягә кадәр Ш. Камал әсәрләрендә аеруча күп урын алган «вак» кешеләр, тәнкыйтьче фикеренчә, совет чоры әдәбиятында да бар. «Хәзерге көндә «вак» кеше – ул үз аңындагы капитализм калдыкларын бетерә алмаган, иске гадәтләр, искергән карашлар колы булып яшәүче кеше. Шул карашлары белән алар безнең үсешебезгә комачаулык итәләр»[3]. «Вак» кеше образын Г. Кашшаф М. Әмирнең «Кысыр хәсрәт» хикәясендә күрә.

---

[1] Кашшаф Г. Чорыбызга лаеклы художество әсәрләре бирик // Совет Татарстаны. 1952. 4 декабрь.

[2] Кашшаф Г. Тормышны тирәннән һәм дөрес чагылдыру // Совет әдәбияты. 1952. № 12. Б. 93.

[3] Шунда ук. Б. 104.

Тәнкыйтьче «конфликтсызлык теориясе»нең сатираны да «кысрыклап чыгаруы» турында яза. Аның фикеренчә, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Насрый, Ә. Камал әсәрләрендәге юмор-сатира элементлары «... төбендә беркатлы, пешеп җитмәгән олы кешеләрнең балалык кыланышларын күрсәтү белән эшләнде»[1]. Шул ук вакытта, Г. Кашшаф М. Әмирнең «Җыр дәвам итә» драмасындагы комик урыннарны да аерып чыгара.

Мәкаләдә поэзия үсешен билгеләгәндә, тәнкыйтьче шигырь структурасына, канатлы сүзләргә, поэтик көчкә, күләмгә игътибар бирә. С. Хәким, Ә. Исхак, Н. Арсланов, Н. Дәүли һ.б ның. шигъри юллары мисалында заман шигъриятенә гомуми бәя бирелә. Г. Кашшаф шигырьләрнең күләмле, әмма эчтәлекләре «сыек» булуга игътибар итә, шагыйрьләргә татар әдәбиятына хас традицияләрне, рус әдәбияты ирешкән казанышларны кулланырга чакыра.

1952 елда Г. Кашшаф эшчәнлегендә иң күләмле хезмәт – Ш. Камалның дүрт томлыгының ике китабына язган кереш мәкаләләре. Билгеле, Ш. Камалның иҗат һәм тормыш юлына карата тупланган фактологик, биографик материал 1940 елда басылган хезмәттән алынган. Әмма «Шәриф Камал» китабында язучы иҗатына бирелгән анализ кереш мәкаләләрдә тулылана, шактый тирәнәйтелә. Мәсәлән, тәнкыйтьче М. Гафури тарафыннан иҗат ителгән ярлылар образын Ш. Камал әсәрләрендә психологик яктан катлаулырак итеп сурәтли башлый, дип билгели. Г. Кашшаф язучының иҗат үсешен партиялелек, сыйнфыйлык принципларында торып күзәтә, әсәрләрдә күтәрелгән проблемаларны калкытыбрак куя. «Матур туганда», «Акчарлаклар», «Таң атканда» һ.б. әсәрләре мисалында социалистик революция алып килгән яңа тормыш, хезмәт ияләренең уңышлары күрсәтелә.

Икенче томның кереш сүзе Ш. Камалның сәхнә әсәрләре турында: «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Ут», «Төеннәр», «Козгыннар оясында», «Таулар», «Габбас Галин» (һәм «Карчыга» дип исемләнгән варианты), «Матур туганда». Биредә тәнкыйтьче образлар бирелеше,

---

[1] Кашшаф Г. Тормышны тирәннән һәм дөрес чагылдыру // Совет әдәбияты. 1952. № 12. Б. 103.

эчтәлек белән бергә, әсәрләрнең язылу тарихына, язучы тарафыннан камилләштерүгә дә игътибарын юнәлтә. Шул рәвешле, Ш. Камалның драматург буларак үсеше, табышлары барлана.

Еллар үткән саен, тәнкыйтьченең каләме шомара бара. Ул инде ашыгып нәтиҗәләр чыгарырга тырышмый, хаталарын төзәтергә омтыла, һаман әдәби мохитнең сулышын тоеп яши. Хәзер ул аерым бер әсәрләрне генә тикшерү белән канәгать түгел. «Совет әдәбияты» кебек журналда эшләү дә моны таләп итә. Г. Кашшаф сугыштан соңгы елларда, нигездә, аерым язучы-шагыйрьләрнең иҗатларына тулы бәя бирүне күздә тота, әдәбиятның гомуми торышына анализлар ясый. Аның шушы өлкәдәге хезмәтләре башка әдипләр тарафыннан да кабул ителә һәм алар татар әдәбиятыннан төрле дәреслекләр, студентлар өчен төзелгән программалар, дәреслек-кулланмалар әзерләүдә файдаланыла.

Аеруча Ә. Фәйзи, К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Җәлил, Н. Баян, Ш. Маннур иҗатлары Г. Кашшаф тарафыннан өйрәнелеп, күп кенә басмаларда нәшер ителә. Ләкин тәнкыйтьченең күңеле һаман тынычлана алмый. Әнә шул борчылуларын ул үзенең «Әдәбиятта уңай герой мәсьәләсенә карата» дигән мәкаләсендә җиткерә. 40 – 50 нче елларда «Әдәбият белеменең тырышлыгы, беренче чиратта, шул чор әдәбият үсешенең объектив кыенлыкларын, схематизм һәм төп әдәби концепцияләрне, аерым алганда, уңай герой мәсьәләсенең дөрес эчтәлеген һәм иҗтимагый мәгънәсен томалаган, шулай дип исемләнгән «конфликтсызлык теориясен» абстрактлаштыруны аңлау һәм җиңеп чыгуга юнәлтелә»[1]. Шулай да татар әдәбияты фәнендә уңай герой мәсьәләсе Г. Кашшаф тарафыннан тиешле дәрәҗәдә калкытып куела.

Г. Кашшаф чит геройларны күчереп алып сурәтләүне кире кага. Аныңча, татар әдәбиятының үз йөзе булырга тиеш. Менә шуннан соң гына ул да дөнья әдәбиятының мирасына кереп кала алырлык үрнәкләр бирәчәк. Үз чиратында халкыбызның үз геройларын, милли характерларны булдыру өчен язучының халыкка

[1] Проблемы социалистического реализма. М.: Изд-во Московского ун-та, 1975. С. 33.

җиткерелгән сүзе дә мөһим, ди ул. Шул рәвешле, аралашу ике яктан да барырга тиешлеге исбатлана.

М.М. Голубков фикеренчә, 1940 – 1950 елларда сәяси-идеологик басым үзенең кульминацион ноктасына килеп җитә. Әдәби тәнкыйть яңа функцияләргә ия була башлый һәм язучы белән укучыга сәяси-идеологик яктан тәэсир итә[1]. Ә бу – штамп образлар тудыруга, әсәрләрдә бары тик тормыштан алынган вакыйгаларны күрсәтеп, большевиклар партиясенең карарларына таянуга, чорның алга китешен, илнең, хакимиятнең бөеклеген сурәтләүгә һәм башкаларга китерә. Укучыларга бары тик бер фикер җиткерелә: совет язучылары чынбарлыкны, бернинди кире кагу була алмый торган дөреслекне чагылдыралар. Бары шушы юл гына совет кешеләрен бәхетле киләчәккә, коммунизм чорына алып керәчәк.

Күпмедер дәрәҗәдә Г. Кашшаф чор таләпләренә буйсына, дип әйтә алабыз. Әмма ул бу фикерен укучысына бәхәссез дип тәкъдим итми. Г. Кашшаф әдәбиятның үсеп бару чорында төрле карашларны кисештерү мөһимлеген ассызыклый. Белгәнебезчә, заман героен эзләү хәзерге «Казан утлары»на да чит нәрсә түгел. Буыннар бәйләнеше, фикер сөрешенең дәвамлы бер агымга керүе шуннан күренә.

«Хәзерге әдәби тәнкыйтебезнең торышына карата» исемле мәкаләсендә Г. Халит тәнкыйтьченең бу язмасын хуплап чыга: «...Г. Кашшафның уңай герой мәсьәләсенә карата кызыклы гына хезмәте басылган. Анда беренче тапкыр хәзерге татар әдәбиятында уңай геройны чагылдырудагы уңышлыклар һәм кимчелекләр турында, тартынып кына булса да, кайбер кыю фикерләр әйтелгән. Уңышларга һәм кимчелекләргә социалистик реализмның каты таләпләре ноктасыннан һәм аның эстетик идеаллары югарылыгыннан караганда, без язучылар һәм тәнкыйтьчеләр тагын да кыюрак иҗади уңышларга этәрә торган күп кызыклы проблемалар күтәрә алабыз»[2].

---

[1] Голубков М.М. История русской литературной критики XX века (1920−1990-е годы): учеб. пособие для студ. филол. фак. ун-тов и вузов. М.: Академия, 2008. С. 13.

[2] Халит Г. Хәзерге әдәби тәнкыйтебезнең торышына карата // Совет әдәбияты. 1954. № 8. Б. 61.

Г. Халитнең тәнкыйтендә Г. Кашшаф эшчәнлегенә бәя бирелгән кебек, Г. Кашшаф та 1975 елда Г. Халитне «Үзенчәлекле талант» дип атый. Шул исемдә чыккан мәкаләдә түбәндәге юлларны укыйбыз: «... Гали Халит бер урында туктап кала торган тәнкыйтьчеләрдән түгел. Ул үзен дулкынландырган проблеманы төрле яклап җентекләп өйрәнә, кирәк икән, шул проблемага яңадан әйләнеп кайта; татар матбугатында гына түгел, рус әдәби дөньясына да чыгып, үз авазын ишеттерә белә»[1]. Совет чорында Г. Кашшаф белән бер дәрәҗәдә актив иҗат иткән Г. Халитнең эшчәнлеге дә бүгенге әдәбиятта тулырак өйрәнелергә хаклы. Г. Кашшаф үзенең мәкаләсендә тәнкыйтьченең аерым хезмәтләренә тукталып, аларның кыйммәтен ассызыклый («Тукай халык шагыйре», «Тукай үткән юл», «Мәҗит Гафури иҗаты» һ.б.). «Үзенчәлекле талант»ка ия булу өстенә, Г. Кашшаф Г. Халитнең полемист тәнкыйтьче икәнен таный һәм үз фикеренең дөреслеген Г. Халитнең аргументларын кире кагарлык дәлилләр табу читенлегендә куәтли. Г. Халиткә бәйле истәлекләр китерелгәннән соң, Г. Кашшаф аңа әдәби тәнкыйтькә кагылышлы бер теләген белдерә: «...безнең әдәбиятта әдәби тәнкыйть методлары һәм методология проблемалары бөтенләй кул тимәгән килеш ята. Бу мәсьәләләр тирәсендә уйлансын иде ул һәм аның эрудициясе, таланты бу мәсьәләләрне хәл итә алыр, шулар турында язар дип ышанырга нигез бирә»[2]. Кызганычка каршы, 1975 елда Г. Кашшаф тарафыннан күтәрелгән мәсьәләләр бүген дә өйрәнүне таләп итә.

Г. Кашшаф шулай ук Х. Госманның да гыйльми-педагогик эшчәнлеген бәяли. «Гыйльми авторитеты зур булган» Х. Госман эшчәнлегенә мәкаләдә гомуми бер күзәтү ясала. Г. Кашшаф тәнкыйтьче-галимнең төп хезмәтләрен санап чыга, аларның әдәбият белеме өчен алып килгән яңалыгы һәм шул ук вакытта бәхәсләр уятырлык язмалар икәненлеге күрсәтелә. Х. Госманның үзенчәлеге, тәнкыйтьче фикеренчә, үз юлын, кыйбласын сайлый белүдә: «Матбугатның турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итү аркасында, Хатип Госман бик күп онытылган исемнәрне әдәбиятка, фәнгә кайтара, за-

[1] Кашшаф Г. Үзенчәлекле талант // Казан утлары. 1975. № 6. Б. 117.
[2] Шунда ук.

манында теге я бу рәвештә ярлык тагып, тарихи урынын ала алмый калган шигъри әсәрләргә бүгенге көн әдәбият фәне күзлегеннән чыгып, объектив гыйльми бәя бирелә»[1].

1954 елда Татарстан совет язучыларының III съезды булып узганнан соң, Г. Кашшаф «Совет Татарстаны»нда «Әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсен күтәрик» дигән мәкалә бастыра. Тәнкыйтьче чор әдәбияты алдында торган түбәндәге мөһим мәсьәләләрне барлый: уңай герой проблемасы, сатирик әсәрләрнең табигате һәм сатира коралыннан файдалану, конфликт үткенлеге (драматургия), балалар әдәбияты һәм әдәби тәнкыйть, социалистик эчтәлек һәм милли форма берлеге. Куелган мәсьәләләрне чишү юлын Г. Кашшаф Ш. Камал, Г. Тукай, К. Насыйри, М. Гафури кебек язучыларның иҗатларына мөрәҗәгать итүдә күрә. Иҗаттагы пассивлыкның сәбәпләрен тәнкыйтьче «Иҗат эшебезне көчәйтә төшик» язмасында тикшерә. Аныңча, алда карап үтелгән мәсьәләләрне (уңай герой проблемасы, сатира әсәрләре булмау һ.б.) чишү өчен язучылар теоретик әзерлек узарга тиеш. Әмма татар әдәбияты Октябрь революциясенә үз традицияләрен алып керми, чөнки ул патша Россиясе шартларында тулысынча үсә алмады, дигән фикер үткәрә Г. Кашшаф[2].

1955 елда «Совет Татарстаны» газетасында кечкенә күләмле хикәяләргә конкурс уздырыла. Шул конкурс нәтиҗәсендә «Кыска хикәяләр» исемле җыентык дөнья күрә. М. Шәйми тарафыннан төзелгән китапка һәм танылган язучылар, һәм каләм көчләрен беренче тапкыр сынаган язучыларның әсәрләре тупланган: Р. Саттаров, Ф. Мостафин, М. Хәсәнов, Ә. Еники, М. Шәйми, С. Сабиров, Г. Әпсәләмов, Г. Галиев, И. Усманов, Ә. Фазылҗанов, Ф. Хөсни, Г. Насрый, И. Миңлебаев, М. Хөсәенов, Г. Минский, С. Таһиров, Р. Төхфәтуллин. Г. Кашшаф аларның берничәсенә

---

[1] Кашшаф Г. Хатип Госман // Казан утлары. 1968. № 5. Б. 132.

[2] Кашшаф Г. Әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсен күтәрик // Совет Татарстаны. 1954. 14 август.

игътибарны юнәлтеп, тематик төрлелекне билгели, авторларның үзенчәлекләрен күрсәтә[1].

1955 елда Мәскәүдә рус телендә Татарстан совет поэзиясе үрнәкләрен үз эченә туплаган җыентык дөнья күрә. Г. Кашшаф әлеге китапка кереш сүз язган. Мәкалә күпмилләтле совет әдәбиятының аерылгысыз өлеше булган татар әдәбиятына, 1905 – 1907 еллар революциясе Г. Тукай кебек күренекле шагыйрьне һәм Г. Коләхмәтов шикелле татар пролетар әдәбиятын башлап җибәрүчене бирде, дигән фикердән башлана[2]. Алга таба совет җәмгыятендә тарихи вакыйга-үзгәрешләргә бәйле рәвештә татар әдәбияты үсеше күзәтелә. Г. Тукайны иҗтимагый тормышның актив вәкиле итеп күрсәтеп, Г. Кашшаф аның киләчәк социалистик реализм әдәбиятына алдынгы образ – коммунист, халык массалары җитәкчесе образын 1912 елда ук алып килүен билгели. Тукай иҗат мәктәбенең күренекле вәкиле итеп М. Гафури тәкъдим ителә.

Гражданнар сугышы чорында идея-сәнгати яктан шигъриятта кимчелекләр күзәтелсә дә, тәнкыйтьче татар поэзиясенең силлабо-тоник шигырь төзелешенә күчүен әйтеп уза. Әлеге елларның танылган шагыйрьләре арасында Г. Камал һәм М. Гафури исемнәре атала.

Мәкаләдә шулай ук Татарстанда барлыкка килгән «Октябрь» әдәби берләшмәсе, Г. Кутуй җитәкләгән «Сулф» әдәби төркеме турында, төрле юнәлешләр белән мавыккан шагыйрьләр санала. Татар совет әдәбиятының үсешенә мөһим йогынты ясаган М. Горький, В. Маяковский иҗатлары да читтә калдырылмый.

«Поэзия Советской Татарии» җыентыгына барлыгы 24 татар шагыйренең шигъри үрнәкләре тупланган. Г. Кашшаф татар совет язучылары еш мөрәҗәгать иткән темаларны, проблемаларны аерып чыгара, тел-стиль чараларын, шагыйрьләрнең иҗади үсеш баскычларын билгели. Сугыш чоры поэзиясендә тәнкыйтьче төп урынны М. Җәлил һәм Ф. Кәрим иҗатларына бирсә, сугыштан соңгы елларда әдәбият мәйданына Ә. Давыдов, З. Нури, З. Мансур,

[1] Кашшаф Г. Кыска хикәяләр // Шәйми М. Кыска хикәяләр. Казан, 1955. Б. 3–7.

[2] Кашшаф Г. Предисловие // Поэзия Советской Татарии. М.: Гослитиздат, 1955. С. 5.

М. Хөсәен һ.б ның. шигърияте чыга, дип яза. Мәкаләдә М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Ф. Кәрим, Һ. Такташ, К. Нәҗми, С. Хәким поэзиясенә гомуми күзәтү бирелә. Рус әдәбиятын тәрҗемә итүдә Тукай традицияләрен дәвам иткән шагыйрь-тәрҗемәчеләр арасында М. Җәлил, Ә. Исхак, Ә. Фәйзи, Ш. Маннур, К. Нәҗми, М. Максуд һ.б. эшчәнлеге яктыртыла.

Илленче елларның уртасында М. Җәлил иҗатына һәм шәхесенә мөрәҗәгать итү белән параллель рәвештә, Г. Кашшаф шагыйрьнең көрәштәше А. Алиш исемен дә читтә калдырмый. А. Алишның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан язмалар бер-бер артлы «Яшь сталинчы», «Совет әдәбияты», «Ялкын», «Совет Татарстаны» һ.б. басмаларда чыгалар. 1957 елда басылган «Сайланма әсәрләр» китабына Г. Кашшаф кереш сүз яза. Тәнкыйтьче беренче чиратта А. Алишны шәхес буларак таныту ягында: «... ул киң күңелле иптәш, матур йөрәкле язучы, изге омтылышлы совет кешесе иде! Аның тормышны сөюе, киләчәккә ачык йөз һәм ышанычлы күз белән каравы, олы йөрәгенең җылысын балаларга өләшеп бирергә хәзер торуы һәрбер адымыннан сизелә иде. Әйе, ул балаларны аеруча сөя һәм барлык иҗатын аларга багышлый»[1]. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен иҗат иткән экиятләрдә Г. Кашшаф төгәллекне, музыкальлекне, А. Алишның язучылык осталыгын билгели. М. Җәлилнең исемен кайтару тәнкыйтьчегә А. Алишның да Бөек Ватан сугышы елларындагы иҗаты, аяныч язмышы турында сүз йөртергә юл ача. Сугыш елларында шагыйрьнең иҗатына тирән фәлсәфи фикерләр, патриотлык хисләре үтеп керә. Г. Кашшаф аның шигырьләрендә Ф. Кәрим һәм М. Җәлил шигырьләренә аваздаш моментларны күрсәтә[2]. Авыру аркасында вакытсыз вафат булган Ф. Әсгать иҗатын да Г. Кашшаф читтә калдырмый. Аның фикеренчә, әдәбият тарихыннан бу язучының иҗатын сызып ташлау дөрес түгел. Иҗат юлы бик кыска булса да, тәнкыйтьче фикеренчә, аның каләменә җиңеллек, тапкыр-

[1] Кашшаф Г. Язучы һәм көрәшче // Алиш А. Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1957. Б. 4.

[2] Шунда ук. Б. 16.

лык, үткенлек хас. Геройларының эчке сыйфатларына нык игътибар итеп, Ф. Әсгать уңышлы «психологик рәсемнәр ясый»[1].

Г. Кашшаф яшь каләм тибрәтүчеләрнең иҗатларына һәрдаим бәя биреп килә. 1956 елда «Яшьләр иҗатына карата» мәкаләсендә тәнкыйтьче яшь язучыларның төп кимчелекле якларын аерып чыгара: шәхес культы, иллюстрация белән мавыгу, картлар темасын кабатлау, схематизмга ияләшү һ.б. Мәсәлән, Г. Афзал, тәнкыйтьче язганча, бер редакциядә әсәрләрен басмасалар, икенчесенә ашыга, әмма шигырьдәге хаталары турында уйланырга ашыкмый. Нәтиҗә буларак, җитешмәгән әсәрләр барлыкка килә һәм иң аянычлысы, укучы да шул язмаларны кабул итә башлый. Г. Кашшаф яшьләрне иҗади мөмкинлекләрен ачарга чакыра. Шул ук вакытта, талантлы яшь язучылар арасына ул Х. Камалов, Р. Гәрәй, Ш. Галиев, Р. Төхфәтуллин, Р. Әхмәтҗанов, Г. Ахунов, Г. Афзал кебек исемнәрне кертеп карый.

Г. Кашшафның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлегенең тагын бер юнәлеше – төрле конференцияләрдә, съездларда, юбилей тантаналарында татар әдәбиятының торышына гомуми бәя биреп, чыгышлар ясау. Әлеге юлда тәнкыйтьченең каләм көче дә, татар әдәбиятының гомуми торышын, андагы һәрбер әдипне белүе сорала. Бу яктан Г. Кашшафны татар әдәбиятында энциклопедист галим дип атап булыр иде. Язучылар союзында ясалган чыгышлар авторларның әсәрләрен санап чыгу белән чикләнми. Биредә үз сүзеңне дә төгәл, катгый әйтә белергә кирәк. Шул ук вакытта уңышлар белән уңышсызлыкларны да барлап бару сорала. Бу, билгеле, шәхеснең вакытын да, сәламәтлеген дә аямыйча хезмәт итүен таләп иткән. Чыгышлары аның һәрвакыт диярлек хуплап каршы алынган.

«Монографик хезмәтләр кирәк» дип язып чыга Г. Кашшаф 1960 елгы «Совет әдәбияты»ның бер санында. Язучыларның биографияләре, иҗатлары тиешле дәрәҗәдә яктыртылмавы аңа тынгылык бирми. Ул язучы, шагыйрьләрнең мәктәпләрдә гади бер портретлары да булмау мәсьәләсен күтәрә. Г. Кашшаф – чын

[1] Кашшаф Г. Ф. Әсгать // Совет әдәбияты. 1956. № 9. Б. 98.

мәгънәсендә әдәбиятыбызның үсешен кайгыртып, аның киләчәген сиземләп яшәгән шәхес.

Билгеле бер җәрәҗәдә язучының иҗатын тикшереп чыкканнан соң, Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеген түбәндәге чорларга бүлергә мөмкин:

а) 1920 нче еллар ахыры – 1930 нчы еллар уртасы – стиль, юнәлеш өлкәсендә эзләнүләр;

ә) 1930 нчы еллар уртасы – Бөек Ватан сугышы башланганчы – җитлегү чоры;

б) Бөек Ватан сугышы еллары – 1953 елга кадәр – төрле өлкәләргә караган актив эшчәнлек;

в) 1953 нче елдан алып 1975 елга чаклы – төп игътибарны М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына юнәлтү һәм аны өйрәнү.

Заманның күп кенә әдипләре кебек үк, Г. Кашшаф та чор идеологиясенә бирелгән кеше. Ул Ленин, Сталинның әдәбиятта, сәхнәдә тудырылган образлары белән рухланып яши. Әмма ничек кенә булмасын, тәнкыйтьчене беренче чиратта аларның кешелек сыйфатлары борчый. Бу яктан караганда Г. Кашшаф тәнкыйтьче-эссеист буларак таныла дип әйтү дөрес булыр. Идеологиягә буйсынса да, совет кешесе дә матурлыкка, рухи үсешкә омтылып яши. Г. Кашшаф менә шушы якларны күреп ала белүе белән аерылып тора. Димәк, бүгенге көн тәнкыйтьчеләре дә аның хезмәтләренә мөрәҗәгать итеп, бәхәсләшә, аның фикерләрен уртаклаша яисә кире кага ала. Шунысы бәхәссез: язучыларның һәм шагыйрьләрнең, драматургларның һәм башка танылган әдипләрнең биографияләрен туплау, аларны бастырып чыгару, җыентыкларга кереш сүз язу ягыннан Г. Кашшаф эшчәнлеге зур әһәмияткә ия. Тәнкыйтьченең архив материаллары, шул исәптән көндәлек һәм хатлары укучыга өлешчә генә таныш. Г. Ахунов, Н. Юзиев аларның кайберләренә мөрәҗәгать иткәннәр. Мәсәлән, хатларның берсендә Г. Кашшаф Н. Фәттах каләмен шома, талантлы итеп билгели[1]. Г. Кашшафның язучы-әдипләр, татарның мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә эшчәнлек алып барган вәкилләре белән язышкан хатларын барлап, аларны әдәбият

---

[1] Ахунов Г. Гази Кашшаф хатлары // Татарстан. 1994. № 7-8. Б. 76.

тарихына чыганаклар буларак кертеп җибәрү – киләчәктә башкарыласы мөһим эшләрнең берсе.

Г. Кашшаф һәр шагыйрьнең, һәр язучының иҗат үзенчәлеген күрергә омтылган, аны бәяләргә тырышкан. Ләкин бу нигезсез бер тәнкыйтьләү, мактау яки хурлауга кайтып калмаган. Тәнкыйтьче чор таләбенә, әдәбият белеменә дә таянып эш иткән. Чор шаукымына ияреп, ул вульгар социологизм, совет хакимияте идеологиясенә дә бирелеп ала, заманында актуаль яңгыраган «конфликтсызлык» теориясенә, уңай герой мәсьәләсенә, «кечкенә кеше» проблемаларына да кагыла. И. Нуруллин сүзләрен китереп, Г. Кашшаф турында шуны әйтергә мөмкин: «... әдәби иҗатның кухнясында үзе кайнаган тәнкыйтьче, һәм ул язучының иҗатына тыштан торып, әдәбият кануннарыннан чыгып кына түгел, ә бәлки аның ничаклы нечкә һәм кыен эш икәнен акылы белән аңлау өстенә йөрәге белән хис итеп бәя бирә»[1]. Моннан тыш, тәнкыйтьченең үзенең дә, язучы буларак, каләм сынаганын онытмаска кирәк. Гомумән алганда, Г. Кашшафны тәнкыйтьче-библиограф, язучыларның иҗатларын өйрәнгәндә биографик методны алга сөргән, әдәби процесска гомуми күзәтүләр белән һәрдаим чыгышлар ясап торган тәнкыйтьче-галим дип атарга мөмкин булыр иде. Ул төрле жанрлар белән эш итә (рецензия, аннотация, күзәтү мәкаләсе, иҗат портреты һ.б.), әдәбиятның һәр төре аңа яхшы таныш. Мәкалә-язмалардан күренгәнчә, Г. Кашшаф әсәрләрне теоретик яктан түгел, ә бәлки укучының кабул итү-итмәвеннән, чынбарлыкны ни дәрәҗәдә дөрес чагылдыруыннан торып бәяли. Гуманистик аспектка, әсәрдәге кеше образларының бирелешенә ул аеруча басым ясый. Аңа иҗат җимешенең сәнгати, тел-стиль ягы да мөһим. Тәнкыйтьче күп кенә татар совет классикларының иҗатларына мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта татар әдәбиятының гомуми барышын да күзәтә. Күп кенә язучы-шагыйрьләрне Г. Кашшаф әдәбият мәйданына чыгара, хәер-фатихасын бирә.

[1] Нуруллин И. Тәнкыйтьче һәм галим // Социалистик Татарстан. 1967. 14 апрель.

## 3.2. Театр тәнкыйтьчесе буларак Г. Кашшаф

«Театр тәнкыйте ул – агымдагы сәхнә эшчәнлеген чагылдыра торган әдәби иҗатның бер өлкәсе»[1]. Татар театры кебек үк, театр тәнкыйте дә бай мираска ия. Әмма әлеге өлкәнең тарихи үсешен күзәтеп язылган гомуми характердагы хезмәтләр юк диярлек. Совет чорында театр тәнкыйтен өйрәнүче галимнәр һәм театр белгечләре арасында Б. Гыйззәт, Һ. Мәхмүтов исемнәрен атарга тиешбез. Шулай ук, теге яки бу дәрәҗәдә театр тәнкыйте тарихы татар театры тарихы белән кызыксынган һәм аңа махсус тикшеренүләр багышлаган галимнәрнең хезмәтләрендә чагылыш таба. Әлеге сорауны күтәргән вакытта шунысын да истә тотарга кирәк: театр үз эченә күп кенә төрле эшчәнлекләрне берләштерә, ягъни аны актер, режиссер, драматург, постановщик, гример, костюмер һ.б. тәшкил итә. Димәк, аларның эшен бәяләгән вакытта да тәнкыйди карашлар туарга мөмкин.

Билгеле булганча, беренче татар профессиональ театр тәнкыйтьчесе итеп Габдрахман Кәрам (Рәхмәтуллин) санала[2]. Аның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге А.Р. Салихованың кандидатлык диссертациясендә яктыртыла. Г. Кәрам аеруча театр тамашасының беренчел нигезенә – драматик әсәргә игътибарын юнәлтә. Шуңа күрә ул драма әсәренә үзенчәлекле таләпләр куя[3]. Шул рәвешле татар театр тәнкыйтенең беренче адымнары ясала.

Г. Кәрамнан тыш, вакытлы матбугатта Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев һ.б.ның язмалары да дөньяга чыгып тора, театрның милли мәдәниятнең үсешендә тоткан урыны билгеләнә. Бу өлкәдә актив эшләүче тәнкыйтьчеләр арасында шулай ук

---

[1] Махмутов Х.К. Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. С. 90.

[2] Махмутов Х.К. Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. С. 90.; Салихова А.Р. Литературно-критическое наследие Габдрахмана Карама: Автореф. дис. ... канд-та филол. наук. Казань, 1998. С. 5.

[3] Салихова А.Р. Литературно-критическое наследие Габдрахмана Карама: Автореф. дис. ... канд-та филол. наук. Казань, 1998. С. 16.

Г. Ногайбәк, З. Нуркин, И. Биккулов, К. Бәкер, С. Шәрәфетдинов исемнәрен атап узарга кирәк. Алга таба театр тәнкыйте тарихына үз өлешләрен К. Тинчурин, З. Солтанов, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Г. Кутуй һ.б. кертәләр.

Совет чорына күчкәч, Б. Гыйззәт фикеренчә: «Театр тәнкыйте сәхнә сәнгатенең әһәмиятен һәм үзенчәлекләрен аңлату эшен һаман җәелдерә бара: декорациягә, режиссер хезмәтенә, артист уенына караган мәкаләләр дә күренә башлый. Димәк, пьесаның эчтәлеген аңлату белән генә чикләнмичә, бөтен спектакльгә һәрьяктан җентекләп анализ ясауга күчү омтылышы көчәя»[1]. Һ. Мәхмүтов фикеренчә, һәр чор үзенең актив театр тәнкыйтьчесен тудыра[2]. Аларның кайберләре, театр тәнкыйте белән махсус шөгыльләнмәсә дә, берничә җитди хезмәтләре белән генә дә театр тарихында, заманның театраль процессында мөһим роль уйнаганнар. Шундый шәхесләр арасында театр тәнкыйте тарихчысы М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, Г. Кашшаф исемнәрен атап чыга. Һ. Мәхмүтов аеруча Г. Кашшаф эшчәнлегенә басым ясый. Әлеге әдипнең ярты гасыр дәвамында тупланган мирасын ул театрның елъязмасы дәрәҗәсенә күтәрә. Мәкаләдә Г. Кашшафның күп кенә драматургларның, режиссер, актерларның киңәшчесе булуы да әйтелә. Шулай ук тәнкыйтьче аның Г. Кәрам, Г. Камал, Ф. Әмирхан һәм башкалар тарафыннан барлыкка китерелгән уңай традицияләрне уңышлы дәвам иткәнен билгеле[3]. Г. Кашшафның театр тарихына керткән өлеше хакында театр белгече Б. Гыйззәт тә югары фикердә тора: «Театр тәнкыйте өлкәсендә күп еллар нәтиҗәле эшләп килгән К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти, Г. Кутуй, М. Җәлил, Г. Кашшаф, Х. Хәйри һ.б ның. мәкаләләре, чыгышлары, үз чорының театр эстетикасын ча-

---

[1] Б. Гыйззәт. Кереш. // Татар совет театры (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 5.

[2] Махмутов Х.К. Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. С. 96.

[3] Там же. С. 96.

гылдыру белән бергә, сәхнә сәнгате тарихы өчен ышанычлы чыганак хезмәтен дә үтиләр»[1].

Г. Кашшафның татар театры белән бәйләнеше хакында сүз йөрткәндә, еш кына, аның биографиясе фактларына да тукталалар. Озак еллар дәвамында, әдәби тәнкыйть белән бергә, Г. Кашшафның театр тәнкыйте өлкәсендә эзләнүләре, фикерләре матбугат битләрендә басылып килә. Н. Юзиев «Фидакарьлек» дип исемләнгән мәкаләсендә болай дип язып калдырган: «Гази Кашшафның театр тәнкыйтьчесе буларак формалашуында квартирасының театрга якынлыгы нинди роль уйнагандыр, әйтүе кыен. Әмма шунысы ачык – Гази агага театр үз йорты кебек якын булды. Соңгы елларда үзенең фәнни һәм әдәби тәнкыйть эшчәнлеген йомгаклаган китаплар чыгару уе тугач, бу эшен ул театр һәм драматургия турындагы мәкаләләрен туплаган җыентык төзүдән башлады. Ул аны нәшриятка да тапшырды. Тик «Күңел көзгесе» исемендә чыккан әлеге китабын үзенә генә күрергә насыйп булмады... »[2]. 1975 елда басылган «Күңел көзгесе» әдипнең вафатыннан соң гына дөнья күрә.

Г. Кашшафның нәкъ менә театр тәнкыйтенә караган мәкаләләрен бастырырга теләве юктан гына булмаган. Басылып чыккан хезмәтләре арасында үз әсәрләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы белән беррәттән, ул театрны да читтә калдырмаган. Әдип уенча, вакытлар узу, заманалар үзгәрү белән аның төрле газета һәм журнал битләрендә чәчелеп яткан язмалары тарихка кереп югалачак. Ә китап, җыентык бу юлда ярдәм күрсәтә ала. Тәнкыйтьченең үзе тарафыннан бәяләнеп, «Күңел көзгесе»нә сайланып алынган мәкаләләре, чынлап та, аның иң кадерле сүзләрен, төпле фикерләрен дә җиткереп киләләр, заманның рухи агымын тоярга булышалар.

Китап тарихы белеме галиме Ә. Кәримуллинның «Татар сәхнәсе. Әдәбият күрсәткече (1917 – 1967)» дип исемләнгән белешмәлектә Г. Кашшафның театр тарихына, тәнкыйтенә, драматургиягә караган

[1] Б. Гыйззәт. Кереш. // Татар совет театры (Очерклар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 8.

[2] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 131.

алтмыштан артык язмасы теркәлгән[1]. Шулар арасында кыска рецензияләр, тәнкыйди мәкаләләр, гомумән, театраль гастрольләргә, аерым сезоннарга күзәтү язмалары бар. Әйтергә кирәк, 1967 елдан соң да Г. Кашшаф бу юнәлештә шактый күп эш башкара. Ягъни тәнкыйтьчеhistoire иҗатында театр мохитен, драматургия үсешен яктырткан мәкаләләрнең саны йөзгә якын. Шунысын да искәртергә кирәк, татар театры постановкаларыннан тыш, тәнкыйтьче күрше башкорт театрларының гастрольләрен дә бәяли, төрле характердагы чагыштырулар үткәрә. Татар, башкорт драматургларының иҗатларыннан кала, аның тарафыннан, шулай ук, рус драматургларының әсәрләре нигезендә куелган постановкалар да тикшерелә.

Г. Кашшаф өчен театр аерым бер дөнья, мохит буларак күзаллана: «Гаҗәп тылсымлы сәнгать бит ул театр. Минем тормышымда ул зур урын алды, кече яшьтән үк мин аның тәэсиренә бирелеп киттем һәм ул минем күңелемә нур өсти барды. Бу җыентыкны «Күңел көзгесе» дип билгеләүнең мәгънәсе дә шунда. Театр, зур мәктәп буларак, минем өчен генә әһәмиятле түгел. Ул барыбыз өчен дә изге сәнгать бинасы. Ул сине көлдерә һәм сөендерә, уйланырга һәм борчылырга мәҗбүр итә, кеше рухының тирән диңгезләрендә йөздерә, күңел кылларыңны тибрәндереп төрле моңнарга чумдыра, нәфрәтләндерә һәм көрәш уты кабызып җибәрә»[2]. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Г. Кашшафның балачак, яшьлек еллары татар театрының барлыкка килүе һәм үсеше чорына туры килә. Барлык халык күңеленә үтеп кергән театр яшь тәнкыйтьченең дә күңелен битараф калдыра алмаган. Әмма тәнкыйтьче бу сихри дөньяның көченә йотылып, буйсынып яшәми. Аның үз кыйбласы, үткен каләме бар. Театр постановкаларына бәя биреп, ул, беренче чиратта, аның үсешен күздә тота, аңа ярдәм итәргә тели. Теге яки бу спектакльгә бәя бирү җиңел түгел. Моның өчен үз фикерең булу, аны төгәл җиткерә белү сәләте дә кирәк. Сәхнәгә куелган әсәрләр дә тәнкыйтьче тарафыннан

[1] Кәримуллин Ә. Татар сәхнәсе. Әдәбият күрсәткече (1917–1967). Казан, 1979.Б. 332.

[2] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 3.

башта «әдәби тәнкыйть» уза. Шуннан соң гына ул спектакльнең сәхнәдә башкарылуын тикшерү бурычын үз өстенә ала.

«Мин актер да, режиссер да, драматург та түгел, ләкин драматик әсәрләргә килеп тотынуга мин актер да, режиссер да, драматург та булам. Мин аны үземчә хәрәкәтләр, характерлар көрәше эчендә сиземли башлыйм. Кайчак ул сәхнәдән башкача яңгырый, кайчак әсәр минем зәүкыма ярашып бетми, кайчак тирән канәгатьләнү белән кайтасың һәм театрның тылсымлы көчен сизеп рәхәтлеккә биреләсең... », – дип яза Г. Кашшаф[1]. Шундый хисләр аның һәр мәкаләсендә диярлек сизелеп тора. Ф. Әгъзәмов аның театр тәнкыйте өлкәсендәге хезмәтләренә бәя биреп: «Театр сәнгатенә булган сизгер сәләте аның һәр хезмәтендә үзен сиздереп тора. Кыскасы, Гази Кашшаф театрның Мәҗнүне иде», – дип язган[2]. Г. Кашшафны «театрның зур тәнкыйтьчесе» итеп санаган Р. Нуруллина, аны хаклы рәвештә «театр мәгъшугы», дип атый. Тәнкыйтьченең театрга мөнәсәбәте хакында Ф. Әгъзамов басым ясап туктала: «Г. Кашшафның театрны шашып яратуын, режиссер һәм артистларның дусты, киңәшчесе булуын да онытмыйк. Аны милли театрыбызның тарихы кызыксындыра иде»[3].

Г. Кашшафның театр тәнкыйтенә караган беренче тәҗрибәләрен Казанга күченү вакыты белән бәйләп карау дөрес булыр. Татар театрының бу чордагы торышы хакында Б. Гыйззәт түбәндәгеләрне язган: «20 нче елларның икенче яртысында һәм 30 нчы еллар башында татар театры реализм традицияләрен тагын да ныгыту, социалистик идеялелек өчен, сәхнәдә заман героен гәүдәләндерү өчен ныклы көрәш җирлегендә үсә... Театр үзенең эшчәнлеген тагын да киңәйтеп җибәрә: яңа коллективлар барлыкка килә; 1926 елда Татар театр техникумының беренче чыгарылышы була. Академия театры яңа бинага (Горький урамындагы 13 нче йортка) күчә; авылларга һәм промышленность үзәкләренә ул торган саен ешрак чыга башлый; систе-

---

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975, Б. 64.

[2] Әгъзәмов Ф. Тугрылык // Мәдәни җомга. 1997. 25 апрель.

[3]Агзамов Ф.И. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: Сорок лет на Кремлевской: Сборник / Сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 43.

малы рәвештә тамашачылар конференцияләре үткәрелә. Шушы ук елларда үзенең махсус басма органын булдыра: 1927 елда беренче программа-җыентыклар күренә башлый, тиздән алар «Тамашачы» исемле журналга әверелеп китә»[1].

Нәкъ шушы елларда «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә Г. Кашшаф Г. Кутуйның «Җавап» (1929), А.Н Островский әсәре буенча Татар дәүләт эшче художество театры спектакле сәхнәләштергән «Гаепсездән гаеплеләр» (1936), Г. Кутуйның «Шатлык җыры» постановкалары турында рецензияләрен бастыра. Соңрак, 1938 елда, Г.Кашшаф, Ш. Маннур белән берлектә, Т. Гыйззәтнең «Бишбүләк» постановкасына бәяләмә бирә. Гражданнар сугышын яктырткан әсәр 1932 ук язылган булса да, пьесаның премьерасы бары тик 1938 елның 30 апрелендә генә үтә. Тулаем алганда, әсәр дә, спектакль дә, тәнкыйтьчеләр фикеренчә, уңышлы килеп чыккан. Сәхнә әсәре драматургия законнарына туры килә һәм сәнгатьчә эшләнеше белән укучыны канәгатьләндерә. Т. Гыйззәтнең төп герое – Әхмәтҗан образын тудыруы да уңышлы килеп чыккан. Тик әсәргә «тиешле трактовка» бирелеп бетмәгән, кайбер урыннарда картиналарны көчәйтү кирәк була [2]. Төп кимчелекләр әнә шунда билгеләнә. Шушы ук спектакльнең режиссер Г. Йосыпов куйган постановкасына Г. Кашшаф, соңрак, 1949 елда игътибарын юнәлтә. Г. Байкина, Х. Әбҗәлилов, З. Басыйрованың үз рольләрен башкаруы тәнкыйтьчене сокландыра. Г. Болгарскаяга карата исә мондый сүзләр җиткерелә: «...шәфкатьле ана образын Г. Болгарская бәхәссез оста уйный, тамашачыларны дулкынландыра. Ләкин без шушы яхшы уенны икенче якка сөйри торган бер деталь белән килешә алмыйбыз. Г. Болгарская, ананың улына булган мәхәббәтенә басым ясап, кирәкмәгән нечкәлек күрсәтә. Тимеркәйнең чәй эчеп торырга вакыты юклыгын ишеткәч, үксеп еларга керешүендә мәхәббәттән бигрәк нәфрәткә тартым тойгылар өстенлек ала шикелле»[3]. Күрәбез, тәнкыйтьче һәр образның уйналуына ни дәрәҗәдә игъ-

---

[1] Б. Гыйззәт. Егерменче елларның икенче яртысында татар дәүләт академия театры // Татар совет театры (Очерклар). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 101–102.

[2] Маннур Ш., Кашшаф Г. Бишбүләк // Кызыл Татарстан. 1938. 15 май.

[3] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 28.

тибар итә, һәрбер детальне отып калып, аны тамашачы исеменнән бәяләргә омтыла. Беренче вариант тәнкыйть язмасында С. Сәйдәшевнең көйләренә «тирәнлек» җитми диелсә, икенче вариантта бу кабатланмый: оркестр тарафыннан башкарылмаса да, аның көйләрен тамашачы канәгатьләнү белән тыңлый, дип яза рецензия авторы. Театрга кагылышлы беренче язмаларыннан ук Г. Кашшаф үз сүзен тамашачы фикере буларак җиткерә. Бу, әлбәттә, бер яктан әдәби тактны саклау булса, икенче яктан, аның чыннан да сәхнә әсәрен «масса» исеменнән кабул итүе турында сөйли. 1949 елда басылган мәкаләдә кызыклы бер фактка, заман таләпләренең чагылышына тап булабыз: «Режиссерларыбызның чабатага булган мәхәббәтен бу постановкада тагы бер кат күрдек. Тула өмәсенә киенеп-ясанып килгән кызларны чабаталы итеп бирү – бу әле һаман да татарны зәвыксыз итеп күрсәтүнең кирәкмәгән бер күренеше. Мондый «вак» нәрсәләргә игътибар итәргә вакыт инде»[1]. Бу юллар белән килешәсе килми. Чор үзгәрү белән сәхнәдә күрсәтеләсе әсәрләр дә шул заманга яраклашырга тиеш дигән сүз түгел әле. Димәк, тарихи вакыйгаларны дөрес, тарихта булганча итеп бирү – әсәрнең чынбарлыкка туры килү-килмәвен генә ассызыклый. Тәнкыйтьченең постановкага булган бу таләбе акланмый.

1938 елны Г. Кашшаф, Ф. Хөсни, Ә. Исхак тарафыннан Б. Бикбайның Башкорт дәүләт академия театры сәхнәләштергән «Карлыгач» әсәре тикшерелә. Әйтергә кирәк, постановкага бирелгән рецензияне укып чыкканнан соң, әсәрнең кайсы жанрда язылуына карата сорау туа. Мәкалә авторлары бу яктан җавапсыз калалар. Әсәрнең уңышына, эчтәлегенә тукталганнан соң, кимчелекләр барлана: «Мәхәббәт трагедиясе һәм социаль мотивлар әсәрдә параллель сызыклар буенча үсәләр, ләкин боларның кайсысы өстенлек иткәнлеген аеру шактый читен... Боларны бер-берсенә бәйләп алып барырга, берсен икенчесенә буйсындырырга кирәк иде. Гомумән, әсәрдә таркаулык шактый көчле. Бу таркаулык бер эчтәлек ягыннан гына түгел, драматик эшләнеш ягыннан да бар»[2]. Һәм, әлбәттә,

---

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 30.

[2] Хөсни Ф., Исхак Ә., Кашшаф Г. Карлыгач // Кызыл Татарстан. 1938. 21 май.

актерларның уены да, шуңа бәйле рәвештә, югары дәрәҗәдә түгел, дигән нәтиҗә чыгарыла. Ләкин, билгеләп үтәргә кирәк, бу бәяләмә, өч тәнкыйтьче эше булуга карамастан, шактый йомшак килеп чыккан.

Башкорт дәүләт театры тарафыннан куелган икенче постановка – Н.В. Гогольнең «Өйләнү» әсәре буенча. Әлеге спектакльне Ә. Исхак белән Г. Кашшаф бәялиләр. Әмма бу рецензия дә оригинальлеккә дәгъва итми. Тәнкыйтьчеләр постановканы, актерларның уенын мактаудан ерак китмиләр. Шул ук хәл Г. Кашшаф белән Ф. Хөсни бәяләгән «Корыч ничек чыныкты» спектаклендә дә күзәтелә. Бердәнбер җитешсезлек – әдәби әсәрнең уңышсыз тәрҗемә ителүе – хакында гына сүз күтәрелә.

30 нчы еллар татар театры турында фикер йөрткәндә, шунысын билгеләргә кирәк: әлеге чор – социалистик реализм методының урнашу һәм вульгар социологизм карашларыннан котылу вакыты. Б. Гыйззәт бу хакта: «Татар театрының 30 нчы еллардагы үсеше турында сөйләгәннәргә йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: аның идея-художество камиллегенә илткән юлы җиңел булмый. Татар академия театры идеялелек һәм художество осталыгы өчен көрәш билгесе астында үсә, үз заманының мөһим проблемаларын күтәрә. Шуңа күрә дә 30 нчы еллар татар театрында социалистик реализмның ныгып урнашуы өчен хәлиткеч этап була»[1]. Һәм бу юнәлештә әдәби һәм театр тәнкыйтьчеләренең дә өлешләре бар дип әйтү урынлы.

Бөек Ватан сугышы елларында әдәбиятта уңай герой мәсьәләсе проблемага әйләнде. Дошманга каршы торучы совет солдатын сурәтләү, аның тиңсез батырлыгын күрсәтү даими күренешкә әверелә. Билгеле, биредә, сәяси мотивтан тыш кешедәге горурлык хисен уяту, көрәш рухын булдыру максат итеп куела. Һәм нәкъ менә шундый әсәрләр аркылы совет халкында патриотизм, дошманга нәфрәт тәрбияләнә. 1942 елның башында ТДАТ художество җитәкчесе Е.Г. Амантов икенче эшкә күчеп китә һәм театрның баш режиссеры булып Ш.М. Сарымсаков билгеләнә. «Яшь режиссерның килүе репертуарга, шул исәптән аның эзләнүләре юнәлешендә, әллә ни үзгәреш-

[1] Гыйззәт Б. Утызынчы елларда татар дәүләт академия театры // Татар совет театры (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 161.

ләр кертми, – дип яза М.Г. Арсланов. – Элеккечә, сугыш башланган еллардан алып, коллективның иҗади эшчәнлеге халыкның героизмын, ышанычын һәм каршы тору көчен дөрес сурәтләп бирү курсыннан бара. К. Симоновның «Рус кешеләре» театрның героик-патриотик жанрны үзләштерү юлында тагын бер тәрҗибә булды»[1]. Бөек Ватан сугышы чоры татар дәүләт академия театры тарихын өйрәнгән И. Илялова бу пьесаның постановкасы турында түбәндәгеләрне җиткерә: «Иң беренче тапкыр бу пьеса сугышны тышкы чаралар белән генә түгел, бәлки кеше характеры аша тасвирлый алды. Бирегә кыенлыклар бизәкләп һәм җиңеләйтеп күрсәтелмәде. Сугыш бөтен дәһшәте һәм куркынычлыгы белән күз алдына килеп баса. Ләкин бу сугыш безнең өчен гадел сугыш иде. Симонов совет кешесенең героизмын табигый күренеш буларак ачып бирә алды. Пьеса, идеясе һәм художестволы эшләнеше ягыннан игътибарга лаек булганга, тиз арада күп театрларның репертуарына кереп китте»[2]. Әлеге постановкага карата үз вакытында Ә. Камал белән Г. Кашшаф шактый кырыс тәнкыйди фикерләрен җиткерәләр. Соңгысы болай яза: «Татар дәүләт академия театры «Рус кешеләре» әсәрен тиешле югарылыкта күрсәтә алмады. Театр «Рус кешеләре» образларының сәнгатьчә чагылышын барлык көчкә күрсәтеп бетерә алмады. Моның сәбәбе, безнеңчә, коллективның ашыгып эшләвендә түгел. Хәзерлек өчен вакыт җитәрлек булды. Төп сәбәп – драманың эчке, эмоциональ көчен аңлап бетермәүдән килеп чыккан нәрсәгә, коллективның үз көчләрен дөрес оештырмауга кайтып кала»[3]. Шул рәвешле, Г. Кашшаф күпмедер дәрәҗәдә яшь режиссерга да шелтә белдерә.

Билгеле булганча, сугыштан соңгы елларда, күп милләтле совет театрындагы кебек үк, татар театрында да көндәлек тормыш-көнкүрешне тасвирлап бирү өстенлек итә. Д. Гыймранова язганча: «Сәнгатьнең бу чоры өчен реалистик дөреслекне сурәтләү эстетик канун дәрәҗәсенә җиткерелә. Әлеге психологик-көнкүреш стиле татар

[1] Арсланов М. Татарское режиссерское искусство (1941–1956). Казань, 1996. С. 59.

[2] Илялова И. Бөек Ватан сугышы чорында татар дәүләт академия театры // Татар совет театры (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 166.

[3] Кашшаф Г. «Рус кешеләре» // Кызыл Татарстан. 1942. 31 октябрь.

театры өчен бердәнбер һәм какшамас буларак кабул ителә»[1]. Сугыштан соңгы татар театры турында Х. Кумысников та үз уйлануларын җиткерә: «Республикабыз театрлары алдына да яңа бурыч куелды, хәл итәсе яңа проблемалар килеп басты. Драматургларыбыз әле генә ил өстеннән үткән өермәне, шундый зур җиңү яулап алган халыкның куәтен-кодрәтен төрле яклап өйрәнергә керештеләр. Театрлар да көннең кадагына сугарлык репертуар булдыруны кайгырта башладылар. Эшләр һәрвакыт ал да гөл генә булып тормаса да, драматургларыбыз шул заманда туган проблемаларга кагылышлы ярыйсы ук төпле сүзләрен әйтә алдылар һәм шуның белән театрның үсешенә үзләреннән зур өлеш керттеләр»[2]. Ул, биредә тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителгән һәм шактый уңыш казанган Т. Гыйззәтнең «Изге әманәт» һәм М. Әмирнең «Тормыш җыры» постановкаларын атарга мөмкин. Әмма әлеге спектакльләргә карата Г. Кашшаф үз вакытында шактый кырыс тәнкыйть белән чыга[3].Ул, Ф. Мөсәгыйть белән берлектә, "Изге әманәт"кә Ф. Хөсни, Я. Агишев тарафыннан бирелгән бәяләмәләр белән килешми[4]. Хәзерге вакытта театр белгече М. Арсланов исә Г. Кашшафның карашларын «вульгар-социологик позиция»дә торудан, дип билгели[5]. Галим шулай ук тәнкыйтьченең «Тормыш җыры»на карата әйтелгән фикерләре белән дә килешми[6]. Шул рәвешле татар театр тарихы сәхифәләре еллар узган саен яңа яңгырашын ала бара.

Г. Кашшафның соңрак елларда язылган театр тәнкыйтенә караган рецензияләренең күбесе «Күңел көзгесе»ндә урын алган һәм, әйтергә кирәк, биредә чыннан да иң отышлы язмалар тупланган. Җыентыкта

---

[1] Гимранова Д. На сцене – героика (Режиссерские поиски) // Татарский театра (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. С. 43.

[2] Кумысников Х. Сугыштан соңгы елларда татар дәүләт академия театры // Татар совет театры (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 181.

[3] Кашшаф Г. Уңышсызлык һәм аның сәбәпләре // Совет әдәбияты. 1946. № 7–8. Б. 133–144; Кашшаф Г. Тормыш җыры // Кызыл Татарстан. 1947. 5 март.

[4] Кашшаф Г., Мөсәгыйть Ф. Бер уңышсыз спектакль турында // Кызыл Татарстан. 1946. 15 сентябрь.

[5] Арсланов М. Татарское режиссерское искусство (1941–1956). Казань, 1996. С. 151.

[6] Там же. С. 157.

теге яки бу дәрәҗәдә театр тәнкыйтенә караган егерме алты мәкалә тупланган. Алар 1940 елдан алып 1974 елга кадәр төрле журнал һәм газета битләрендә басылып чыкканнар. Әгәр шушы утыз елдан артыкка сузылган чорда якынча утыз спектакль генә тикшерелгән дип күз алдына китерсәк тә, театр тарихы, аның үсеш-үзгәреше турында гомумән мәгълүматы булмаган кеше дә күренеп торган нәтиҗәләр чыгара алыр иде. Г. Кашшаф исә: «...Сезгә тәкъдим ителгән бу материаллар мин язганнарның бик аз өлеше генә, алар – татар театры тарихының бер этабын да яктыртуны дәгъва итмиләр», – дип яза[1].

Г. Кашшаф тарафыннан тәнкыйтьләнгән сәхнә әсәрләренең бер өлеше бүгенге театр тамашачысына яхшы таныш: «Галиябану», «Беренче мәхәббәт», «Хуҗа Насретдин», «Әни килде». Мисал өчен, Х. Вахит әсәре нигезендә Р. Бикчәнтәев сәхнәләштергән «Беренче мәхәббәт» постановкасы өчен режиссер һәм берничә актерга Г. Тукай премиясе бирелә. Галим А. Әхмәдуллин бу пьеса Хәй Вахитка танылу алып килүдән бигрәк, башка кардәш республикалар тамашачысына татар драматургиясенең зур потенциалын да күрсәтте, дип билгеләде[2]. Г. Кашшаф, беренчеләрдән булып, спектакльгә күләмле рецензиясен бирә һәм аның уңышын таный[3].

Драматурглар арасыннан Г. Кашшаф аеруча Г. Камал, Н. Исәнбәт, М. Фәйзи, М. Җәлил, М. Әмир, Т. Гыйззәт иҗатларын аерып куя, аларның әсәрләрен киң планда, төрле яклап тикшерә. Мәсәлән, тәнкыйтьче үз игътибарын «Галиябану» операсына юнәлтә: «Галиябану» кебек драманы зур опера полотносына салу (Ә. Ерикәй либреттосы) – мактаулы һәм гаять җаваплы эш. Үлми торган әсәрнең операсы да үлми торган, классик опера булырга тиеш. Бу – табигый хәл», – дип яза автор[4]. Алга таба сүз композитор М. Мозаффаровның уңышка ирешүе турында бара. Г. Кашшаф Галиябануны С. Садыйкова һәм Г. Кайбицкая башкаруында чагыштырып карый, һәр артистканың бу рольне башкаруда үзенчәлеген билгеләп үтә. Биредә

---

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 4.

[2] Ахмадуллин А.Г. Горизонты татарской драмы. Статьи. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. С. 60.

[3] Кашшаф Г. Яңалык нәрсәдә // Совет әдәбияты. 1960. № 4. Б. 98–105.

[4] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 32.

шунысы да ачыклана: тәнкыйтьче театр постановкаларының һәрберсенә берничәшәр тапкыр йөргән, артистларны да яхшы ук белгән.

Мәкаләләр арасында күләме белән Н. Исәнбәткә багышланганнары аерылып тора. Алар драматургның 70 еллык юбилеена атап язылган. Г. Кашшаф биредә «Мәрьям», «Муса Җәлил», «Һиҗрәт», «Хуҗа Насретдин», «Рәйхан» һ. б. сәхнә әсәрләренә туктала, авторның иҗат уңышларын барлый: «Нәкый Исәнбәт халыкның тарихын иңләп ала торган талантлы язучылар рәтеннән исәпләнергә тиеш. Иҗаты белән бер эзгә салыну белән үк ул үзенә шундый кыю иҗат максаты куя: татар халкының күп гасырлы тарихын әдәби әсәрләрдә чагылдыру идеалы аның яшәү һәм иҗат максатына әверелә»[1]. Н. Исәнбәткә, аның иҗатына ихтирамын тәнкыйтьче шулай ук «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Совет әдәбияты» укучыларына да җиткергән.

Татар драматурглары белән бергә, Г. Кашшаф үз китабында рус, башкорт постановкаларына да урын тапкан. Моны «Сәхнәдә – Островский», «Халыкчан һәм тормышчан», «Салават», «Күрше күзе аша» дигән язмалар раслый.

Әгәр соңгы өчесе Башкорт дәүләт театрының Казанга килеп куелган яисә Г. Кашшафның Уфада карап кайткан әсәр постановкаларын яктыртса, «Сәхнәдә – Островский» дигәне аның татарчага тәрҗемә ителгән сәхнә әсәре булуы турында бара. Бу – Н.Островскийның Н. Дунаев тарафыннан «Агай-эне ак мыек» дигән исем белән тәрҗемә ителгән «Свои люди – сочтемся» комедиясе. Күләме ягыннан тәнкыйди язма зур булмаса да, анда актерлар уены шактый тулы яктыртыла, рәссам М. Сутюшевның эшчәнлеге дә Г. Кашшаф тарафыннан югары бәяләнә.

«Башкорт дәүләт академия драма театрының Казанда гастроль спектакльләрен шагыйрь Кадыйр Даянның «Таңчулпан» драмасы белән башлап җибәрү бик уңышлы һәм мәгънәле, чөнки нәкъ шушы спектакльдә башкорт халкы характерын аңларга мөмкин», – дип яза тәнкыйтьче «Халыкчан һәм тормышчан» дигән мәкаләсендә[2].

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 132.
[2] Шунда ук. Б. 62.

Г. Кашшафның кардәш башкорт театрына битараф булмавы нәкъ менә шушы мәкаләсендә ачык күренә. Китапта авторның: «Кардәш театр коллективы белән очрашу һәрвакыт бәйрәм. Елдан-елга күреп, профессиональ осталыкларын тәкъдир иткән тамашачы быелгы беренче очрашуны да бәйрәм кебек каршылады. Артистлар... халыкның рухи бизәкләрен асраучы сәнгать әһелләре, без тагын очраштык... Тик бу очрашуда сагыш та бар, чөнки безнең яраткан дусларыбызның кайберләре инде килә алмаячак икән... Ләкин шунысы куанычлы – картлар урынын талантлы, җитез һәм темпераментлы яшьләр алган. Димәк, театр хәрәкәттә, ул үсештә, матур традицияләрне баетып баруында дәвам итә», – дигән юллар чын күңелдән әйтелгән сүзләр буларак яңгырый[1].

Тәнкыйтьченең 1951 елда язылган «Матур темалар, җитлекмәгән образлар» исемле мәкаләсендә чор драматургиясенең кайбер мәсьәләләре күтәрелә. Аны без, совет чоры татар драматургиясенә күзәтү, дип атый алабыз. Гадәттәгечә, автор башта «яхшы» әсәрләргә мөрәҗәгать итә. Шулар арасына М. Әмирнең «Тормыш җыры», Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт», Ә. Фәйзинең «Пугачев Казанда» драмалары кертелгән. Алга таба мәкалә авторы татар совет драматургиясенең җитешсез якларын барлауга күчә. Төп сәбәп: «Идея-художество зәгыйфьлеге тормышны белмәүдән, сәнгатьнең идея бурычын аңлап бетермәүдән килеп чыга. Тормышны белмәү аркасында кирәкле тема, кызыклы проблема җансыз, зәгыйфь образ аркылы бирелә һәм идея-художество ягыннан җитлекми... социалистик реализмны тирән һәм киң рәвештә файдалану җитми...», – дип яза тәнкыйтьче[2]. Үз сүзләрен раслау өчен, әлеге җитешсезлекләрне үзләрендә туплаган әсәрләрне барлауга күчә. Алар: Р. Ишморатның «Якын дус» драмасы (проблемаларны художестволы итеп күрсәтүгә бик аз игътибар итү), А. Әхмәтнең «Серләр» әсәре (драматик конфликтның сыеклыгы), М. Әмирнең «Җыр дәвам итә» драмасы (гаять кызыклы конфликтның кинәт сүрелүе), Н. Исәнбәтнең

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 28.

[2] Кашшаф Г. Матур темалар, җитлекмәгән образлар // Совет әдәбияты. 1951. № 6. Б. 104.

«Гүзәл»е (табигый булмаган образлар), М. Әмирнең «Профессор Саматов»ы («серле нәрсәләрнең ишәя башлавы белән») һ.б. Әлеге хәлдән котылу чарасын Г. Кашшаф түбәндәгечә тәкъдим итә:

1) татар драматургиясенең традицияләрен, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, Ш. Камал, Һ. Такташ һ.б. драмаларының үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнү;

2) драмсекциянең эшен яңабаштан коруны таләп итү, театрдагы художество советының эшен үзгәртеп кору;

3) «...конкрет рәвештә театр тәнкыйтен үстерү турында чаралар күрелми. Бу мәсьәләгә Сәнгать управлениесенең үзендә дә җитди карау юк. Инде 10–12 ел буена театрыбызның тарихын язу турында сөйлиләр. Ләкин әле берәү дә бу эшкә керешкәне юк. Драматургларның монографияләре өстендә эшләү юк. Театрның традицияләрен гыйльми өйрәнүне юлга салмыйча торып, бу өлкәдә җитди уңышка ирешү авыр! Тәнкыйтьне гыйльми эш итеп, киң рәвештә аңларга бик вакыт»[1]. Әлбәттә, бу эшкә керешү актуаль. Татар драматургиясенең Г.Кашшаф тарафыннан күтәрелгән проблемалары да дәлилләргә нигезләнгән.

Тәнкыйтьченең драматургиягә кагылышлы язма мирасы аерым авторларның сәхнә әсәрләрен тикшерү, постановкаларга бәя бирү белән генә чикләнми. Театр тәнкыйтьчесен «Татар операсының үсүе», «Бүгенге драма турында» кебек мәсьәләләр дә кызыксындыра. Мәсәлән, аның Татарстан язучыларының дүртенче съездында сөйләгән докладына игътибар итәргә кирәк. 1958 елда басылып чыккан бу язмада автор татар драматургиясенең артталыгына борчыла. Мәскәүдә үткән декада да бу мәсьәләнең ачык чагылышына мисал булып тора. Егерменче – утызынчы елларда куелган спектакльләрнең илленче елларда яңадан сәхнәгә менүе Г. Кашшафны канәгатьләндерми. Ул драматургларны эшкә өнди, аларны иҗат итәргә чакыра. Әмма, икенче яктан, бер үк сәхнә әсәренең озак вакытлар дәвамында тамашачыны җәлеп итә алуы кимчелек түгел, киресенчә, әсәр һәм постановканың уңышы турында гына да фикер йөртергә урын калдыра.

[1] Кашшаф Г. Күңел көзгесе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 115.

Инде әйтеп үтелгәнчә, Г. Кашшафның һәр язмасы актерлар эшчәнлеген яктыртуга да юнәлтелгән. Шуларның берсе турында ул аерым китап булып басылып чыгарлык очерк иҗат итә. Әлеге артистка – Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

1958 елда дөнья күргән бу китап күләме ягыннан да, тиражы ягыннан да зур түгел. Әмма эчтәлеге бик бай. Хезмәт танылган артистканың тормыш фактларын теркәп бару белән генә чикләнми, ә бәлки аны тормышчан, гади бер хатын-кыз итеп сурәтләүгә багышланган. Бу истәлекне язарга ярдәм итүчеләрне дә Г. Кашшаф читтә калдырмый: «Волжская белән байтак еллар бергә хезмәт иткән талантлы артист Шакир Шамильский миңа бик күп истәлекләр сөйләгән иде», – дип яза автор[1]. С. Волжскаяның үзе белән очрашу исә Г. Кашшафта бу талантлы артисткага карата чын соклану хисен уята. Артистканың әңгәмәдәшче сорауларына туры җавап бирүе дә тәнкыйтьче тарафыннан билгеләнми калмый.

Г. Кашшаф театр тәнкыйтендәге эшчәнлеген киң планда алып барган. Ул сәхнә әсәрләрен, аларның постановкаларын тикшергән, актерлар, режиссерлар, рәссамнар, композиторларның эшчәнлегенә үз бәясен биреп барган. Мисал өчен, 1961 елда дөнья күргән «Драматург һәм режиссер» мәкаләсендә татар театры режиссерларының җитди хаталары санала[2]. Вакытлар үтү белән, һичшиксез, татар театры да үзгәрешләр кичергән. Шуңа да карамастан, алга бару, яңа үрләр яулау өчен, театр сәнгате белән кызыксынучылар аның тарихын да белергә тиеш. Бу юнәлештә Г. Кашшафның китаплары, аның басылып чыккан язмалары чыганак булып тора.

Г. Кашшафның киң җәмәгатьчелектә театр белгече буларак танылуы хакында М.Г. Арсланов та искәртә[3]. Тәнкыйтьче спектакльләрне җәмәгать белән берлектә тикшерүләрдә катнаша. Мисал өчен, 1941 елда Ш. Сарымсаков «Таймасовлар» спектаклен сәхнәгә чыгара. Г.Кашшаф андагы кайбер сугыш күренешләрен алып ташларга

---

[1]Кашшаф Г. Беренче артистка. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. Б. 22.

[2] Кашшаф Г. Драматург һәм режиссер // Социалситик Татарстан. 1961. 30 май.

[3] Арсланов М. Татарское режиссерское искусство (1941–1956). Казань, 1996. С. 49.

тәкъдим итә. Шул рәвешле, спектакльнең ахыргы вариантында сугыш кырында узган барлык күренешләр юкка чыгарыла. Тагын бер мисал: 1963 елда «Гөлҗамал» постановкасына уңыш юрый. Әлбәттә, бу аерым мисаллар гына. Театр дөньясында билгеле кеше буларак, Г. Кашшаф һәрдаим актерлар, режиссерлар, драматурглар белән аралашып, киңәшеп яшәгән. Һәм, билгеле, әлеге әңгәмә-аралашулар вакытында да эшнең уңай һәм уңышсыз яклары турында фикер алышулар булмый калмагандыр.

Р. Нуруллина тәнкыйтьченең театрга куйган таләпләрен билгеләп, түбәндәге сыйфатларны аерып чыгара:

1) халыкчанлык принцибының саклануы;

2) тормышчанлык, заманчалык.

Фикерен дәвам итеп, ул болай яза: «Гази Кашшаф спектакль тудыручыларның барысы алдына да сәнгать реализм кысасында торырга тиеш, нинди генә формалистик алымнардан, формалардан файдаланганда да тамашачыны онытмаска, спектакльне аңа аңлашылырлык итәргә кирәк, дигән таләпне куйды»[1].

Г. Кашшафның театр тәнкыйтенә күзәтү ясау шуны ачыклый: тәнкыйтьче һәр постановканы драматургия әсәре буларак та, сәхнә постановкасы, аерым спектакль рәвешендә дә тикшерә (әгәр әсәр тәрҗемә ителгән булса, аңа да игътибар итә). Ягъни, Г. Кәрам кебек, ул да беренче чиратта әдәби әсәргә туктала. Тәнкыйтьче шулай ук режиссер-постановщикларның, рәссам, композитор, дирижер һ.б ның. бердәм эшчәнлегенә зур әһәмият бирә. Артистларның образларны тудыру үзенчәлеген истә тотып, бер үк рольне башкаруда берничә актер уенын чагыштырып карай. Шул ук вакытта әсәрнең совет чоры чынбарлыгына туры килү-килмәве, совет чорының үсешен чагылдыруы һ.б. да тәнкыйтьче игътибарыннан читтә калмый.

Мәглум булганча, Г.Кашшафның утызынчы еллар ахырында язылган рецензияләре йомшак булулары белән аерылып тора. Аларда тәнкыйтьче әле эчтәлек сөйләү, актерның образ тудыру

---

[1] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 25–26.

сәләте белән канәгать булу-булмауга таянып эш итә. Тора-бара аның каләме шомара, рецензияләрнең эчтәлеге киңәя. Бер үк спектакльне берничә мәртәбә карау да үзен сиздерә. Актерлар арасында янәшәлекләр үткәреп, Г. Кашшаф аерым артистларның үсешен дә күзәтеп барган. Аның киң катлам артистлар белән таныш булуын, режиссерларның, рәссамнарның эшчәнлеген бәяләвен дә билгеләп үтми мөмкин түгел. Сәхнәнең һәр детале, спектакльнең һәр образы тәнкыйтьчене шул дөньяга кертеп яшәткән. Р. Нуруллинаның дөрес билгеләвенчә, үз заманында Татар театрының Россиядә иң алдынгылардан саналуында Г. Кашшафның да өлеше бар[1]. Һәм бу сүзләр, һичшиксез, татар театр тәнкыйте тарихына да кереп калырга тиеш.

---

[1] Нуруллина Р. Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 25.

# 4. Г. КАШШАФ – ҖӘЛИЛ ФӘНЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

## 4.1. Васыятьне үтәү юлында

Җәлил фәне бүгенге көндә – үз предметын, методологиясен, тарихын һәм шактый зур библиографиясен булдырган мөстәкыйль һәм киңкырлы фән өлкәсе. 1976 елда Казан университеты нәшрияты тарафыннан чыгарылган библиографик күрсәткечтән мәгълүм булганча, 1919 – 1973 еллар аралыгында М. Җәлилнең шигырьләре аерым басма булып 88 тапкыр һәм 56 телгә тәрҗемә итеп чыгарыла[1]. 40 елга якын вакыт узганнан соң, әлеге санның ике мәртәбә артуы да мөмкин. «Татар гына түгел, Россия шагыйрьләренең бик азы басма, тәрҗемәләр һәм аерым публикацияләр саны ягыннан Җәлил белән тиңләшә алыр иде. Әлеге факт М. Җәлил шигъриятенең гади әдәби генә түгел, иҗтимагый-сәяси фактор икәнен раслап тора», – дип яза Р. Мостафин[2]. Бу өлкәдәге эзләнүләрнең күпчелеге Г. Кашшаф китабының ике басмасына таянып алып барыла, тәнкыйтьче үзе исә Җәлил фәненә нигез салучы, шушы фәннең патриархы буларак таныла[3].

М. Җәлилнең тормышын, иҗатын өйрәнү юлында Г. Кашшаф берничә тармаклы эшчәнлек алып бара. Аларны үз истәлекмәкаләсендә Ф. Әгъзамов санап чыга:

1. Ул патриот шагыйрьнең әсәрләрен җыя һәм бастырып чыгаруга әзерли;
2. Г. Кашшаф Муса Җәлил турында истәлекләр җыю буенча зур эш җәелдерә;
3. Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын матбугат, телевидение, радио аша пропагандалый, лекцияләр укый, күпсанлы оч-

[1]Мустафин Р. Научные публикации о жизни и творчестве Мусы Джалиля (Джалиловедение как наука) // Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века / сост. Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова. Казань: Казан. ун-т, 2006. С. 15.

[2] Там же.

[3] Там же. С. 16.

рашулар уздыра, шагыйрь һәм аның көрәштәшләре белән кызыксынучыларга консультацияләр бирә;

4. Беренчеләрдән булып патриот шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын һәрьяклап теоретик һәм публицистик тикшерүне җәелдереп җибәрә[1].

М. Җәлил һәм Г. Кашшафның танышу вакыты хакында берничә фикер яшәп килә. «М. Җәлил һәм Г. Кашшаф 1937 елда танышалар... Соңрак бергә эшлиләр, шатлыкларын, иҗат сөенечләрен һәм көенечләрен, кайгы-хәсрәтләрен бүлешеп яшиләр. Дуслашып китәләр», – дип яза Ф. Әгъзамов[2]. Әмма дуслык-танышлыкның тамырлары бу вакытта инде шактый ныгыган була. Моны М. Максуд язмасы раслый. Г. Кашшаф белән М. Җәлилне «күптәнге дуслык, ...бер-берсенә ахирәт булулары» бәйләп тора. М. Максуд «Сагынган минутларда» дип исемләнгән китабында М. Җәлилнең «Иптәшкә» китабына бәйле әлеге фактны мондый фикерләр белән раслый: «Иптәшкә»нең зур тарихи әһәмияте бар.

Китапның титул битендә «Иптәшкә» исеме астында җәя эчендә «Теләктәшкә» дип өстәлгән. Менә хәзер минем кулымда шул китапның Муса үзе Гази Кашшафка бүләк итеп биргән экземпляры. Титул битендә, сул кырыйда Муса үзенең аермачык укыла торган вак хәрефләре белән (гарәп алфавитында) түбәндәгеләрне язган:

«Кәшшәфи дус! Синең йөзеңдә революция юлындагы чын иптәшем-теләктәшемне күрдем. Йөрәктән ачыклык – искренныйлык, простойлык, салкын канлылык, тирән уйлаучылык, керсезберкатлы дуслык – менә минемчә нинди сыйфатлар теләктәшләрне җәһәт якынайта һәм бергәләп һәр уйны ачык уртаклашырга, тәнкыйтьләшергә, тикшерергә, киңәшергә, төзәтешергә, булышырга нигез сала. Без дә шулай бергәләп үсик, бергәләп көрәшик. М. Җәлил, Мәскәү. 1929 – февраль 16»[3]. Ягъни Г. Кашшаф әдәбият

[1] Агзамов Ф.И. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / сост. и ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 39–40.

[2] Там же. С. 33–34.

[3] Максуд М. Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 119.

дөньясында эшчәнлеген актив җәелдереп җибәргәнгә кадәр үк, шагыйрь белән якын дуслыкта була.

М. Җәлилнең публицистикасын тикшергән Ш. Хамматов аларның дуслашу сәбәпләрен дә ачыкларга тырышкан: «Аларны күп нәрсә: идея инанганлыгы, тормышка, әдәбиятка мөнәсәбәт берләштерә иде»[1].

Ф. Әгъзамов игътибарга лаек бер фактны искәртә: «М. Җәлил Г. Кашшафка партиягә кергәндә рекомендация бирә, аның идеяләргә бирелгән, объектив, кыю, партиячел тотрыклы, җәмәгать эшләрендә актив булуын ассызыклый. Бу – М. Җәлил белән Г. Кашшафның дөньяга караш җәһәтеннән кардәшләр, рухи туганнар булуын раслый»[2].

Тәнкыйтьче, үз чиратында М. Җәлилнең иҗатына югары бәя биреп бара. Мәсәлән, 1943 елда Г. Кашшаф белән композитор Җ. Фәйзи М. Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосына уңай бәяләмә язалар[3]. Әсәрне музыкага салган композитор Н. Җиһанов һәм мәкалә авторлары шагыйрнең ижат жимешенә сокланып карыйлар, аны чын мәгънәсендә горурланырдай мирас, дип билгелиләр.

М. Җәлилнең Г. Кашшафка язган хатларына аерым тукталу урынлы булыр. Бу хатларда ышаныч, җылылык сүзләре яңгырый. М. Җәлилнең иң якын дустына эндәшкән сәламләү яки саубуллашу сүзләре башкаларныкыннан күзгә күренеп аерылып тора: Кашшаф дускай; Кашшаф, кадерле дус; Кашшаф дус; Кадерле Кашшаф дус; Кадерле Кашшаф... Кайнар үбәм – Муса; Мусаң; Каты кочып Муса; Кулыңны кысып, Мусаң; Хәзергә сине кочып, Муса. Эчтәлекләренә дә игътибар итми мөмкин түгел. Менә М. Җәлилнең Курск өлкәсендәге Щигры шәһәреннән язылган хатыннан берничә юл: «Синең хатың беренче булып килде һәм мин

---

[1] Хамматов Ш. Ему завещал Джалиль: к 80-летию со дня рождения Гази Кашшафа // Вечерняя Казань. 1987. 15 апреля.

[2] Агзамов Ф.И. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: срок лет на Кремлевской: сорник / сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 34.

[3] Кашшаф Г., Фәйзи Җ. Татар операсының үсүе // Совет әдәбияты. 1943. № 8. Б. 72–78.

бөтен йөрәгемнән игътибарың өчен һәм чын дуслыгың өчен сиңа рәхмәт белдерәм. Мин һәрвакытта да онытмавыңа тирәннән ышана идем. Синең хатың бик җылы язылган һәм мин анда үземнең сагынган йөрәгемә кирәкле нәрсәләрнең барысын да таптым. Рәхмәт, кадерле дус!»[1]. Әмма бу бер генә хатта язылган сүзләр түгел. 1942 елның егерменче мартында язып җибәргән хатында да шагыйрь дустына карата ихтирам сүзләрен кызганмый: «Кадерлем минем, Кашшаф! Син минем иң якын һәм кайгыртучан дустым идең һәм шулай булып калдың. Минем шундый авыр көннәремдә син үзеңнең дусларча саф күңелдән язылган хатларың белән миңа ярдәм иттең, минем иҗатым, китабым, һәм гаиләм турында кайгырттың. Мин чын күңелдән сиңа рәхмәт әйтәм...»[2]. Соңрак Г. Кашшафка васыять хаты языла: «Мин – татар язучысы, Совет язучылары союзының члены Джалиль (Залилов) Муса Мустафович – Муса Җәлил – хәзерге вакытта хәрәкәттәге удар армиядә Ватан сугышы фронтында булып, үзем фронтта һәлак булган очракта, әдәби мирасым турында түбәндәгеләрне васыять итәм:

Мин әдәби иҗат эшләре белән 1916 елда шөгыльләнә башладым. Беренче шигырьләрем 1919 елда Оренбургта (хәзерге Чкалов) фронт армия газетасы «Кызыл йолдыз»да басылдылар, һәм шул вакыттан бирле мин һаман да татар матбугатында, шулай ук өлешчә рус матбугатында әсәрләремне бастыра килдем. Ләкин минем әсәрләремнең тик 30 – 35% чамасы гына дөньяга чыгарылган. Кулъязмаларымның бер өлешен мин тормышымның төрле шартларында Мостафа авылында, Оренбургта, Казанда, Мәскәүдә һ.б. югалттым. Сугышка хәтле мин аларны бергә җыеп, тәртипкә китерә алмадым.

Үзем үлеп калган очракта каралама хәлендәге, шулай ук акка күчерелгән барлык кулъязмаларымны, шигырьләр, җырлар, хикәяләр, пьесалар, эпиграммалар, тәнкыйть мәкаләләре, көндәлекләр һәм хат-

[1] Муса Җәлил: Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т.3. Б. 404.

[2] Шунда ук. Б. 423.

ларымны җыю эшен иң якын дустым, язучы һәм тәнкыйтьче, Совет язучылары союзы члены Гази Кашшаф иптәшкә васыять итәм.

Минем барлык кулъязмаларым, хатларым һәм көндәлекләремнең аңарда туплануын, барлык язмаларымның аңа бирелүен һәм үз библиотекамдагы кулъязмаларымны җыеп тәртипкә салырга аңа рөхсәт ителүен васыять итәм.

Гази Кашшаф иптәшкә үзем үлгәннән соң әсәрләремнең җыентыкларын һәм аерым китапларын төзергә, аларны редакцияләргә васыять итәм. Аңар үземнең барлык иҗатымны васыять итәм һәм барлык әдәби мирасымны тәртипкә салып, үз комментарийлары белән, үз каравы буенча матбугатта чыгаруны васыять итәм.

Шуңа күрә дә тиешле оешмаларның һәм аерым кешеләрнең бу эштә Г. Кашшаф иптәшкә тулысынча булышлык итүләрен һәм үзләрендә булган кулъязмаларның, көндәлекләремнең һәм хатларымның барысын да аңа тапшыруларын үтенәм. Муса Җәлил. 27.5.42»[1].

Васыять булып, рус телендә рәсми рәвештә җибәрелә. Нәкъ менә васыять килгән елдан, «1942 елның июненнән Мусадан хатлар килми башлады. Мин бик озак көттем. Ниһаять, кайгылы хәбәр килде: Җәлил хәбәрсез югалган», – дип яза үзенең истәлегендә Әминә Җәлилова[2]. Шушы вакыйгалар Г. Кашшафны М. Җәлилнең тормышын, көрәшен, иҗатын тулы итеп өйрәнергә этәрә дә. «Сугыш елларында Г. Кашшаф Казан әдәби хәрәкәтендә иң үзәк фигураларның берсе була. М. Җәлил васыять рәвешендә язган язмасында аның исеме беренчеләрдән булып аталуы тиккә түгел!» – дип белдерә Р. Фәйзуллин[3].

Билгеле, сугышта хәбәрсез югалган солдат турында төрле имеш-мимешләр йөри башлый. Шуңа да карамастан, 1942 елда Г. Кашшаф аның «Тупчы анты» исемле шигырьләр җыентыгын

---

[1] Максуд М. Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 8.

[2] Мостафин Р. Өзелгән җыр эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. Б. 9

[3] Фәйзуллин Р. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл: фәнни-публицистик язма. Казан: Идел-Пресс. 2004. Б. 33

әзерли һәм бастырып чыгара. Дустының яман юлга басуын Г. Кашшаф бер мизгелгә дә уена кертергә тырышмый.

1943 елның октябрь аенда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы идарәсенең президиум утырышы үткәрелә. Ул утырышта Г. Кашшаф «Бөек Ватан сугышы көннәрендә татар язучыларының эше» турында доклад ясый. Аның докладын президиум әгъзалары зур игътибар белән тыңлый. Шул ук утырышта А. Фадеев М. Җәлил хакында да сораша. Г. Кашшаф аңа Җәлилнең Волхов фронтында хәбәрсез югалуын әйтә. «Мәскәүдә резервта торган чагында Җәлилнең рус телендә бастырырга дип үзе әзерләп калдырган китабы ни хәлдә, басылып чыктымы?», – дип сорый А. Фадеев[1]. Президиум утырышында катнашкан Гослитиздат вәкиле шагыйрьнең язмышы ачык булмау сәбәпле, китапның әлегә кадәр басылмавын әйтә. А. Фадеев шигырьләр җыентыгын бастыру турында махсус карар чыгарырга тәкъдим итә.

Ләкин нәшриятта Җәлилнең кульязмасы югалган була. Китапны дөньяга чыгару өчен Г. Кашшафка эшне яңадан башларга, М. Җәлил шигырьләрен русчага сүзгә-сүз тәрҗемәләрен эзләп табарга, рус шагыйрьләре белән сөйләшеп, аларны яңадан тәрҗемә иттерергә һәм китапны Казанда чыгарырга рөхсәт алу артыннан йөрергә туры килә.

1947 елда басылган «Татар совет әдәбиятының 30 еллыгы» дип аталган күзәтү мәкаләсендә тәнкыйтьче шушы елларда иҗат иткән әдипләрне, язылган әсәрләрне барлый, аларның чор өчен кыйммәтле һәм кимчелекле якларын ачырга тырыша һәм М. Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасына да туктала. Бу факт хакында Ф. Галимуллин болай яза: «Г. Кашшаф М. Җәлил исемен уңай яктан телгә алырга җөрьәт итә. Аның ни рәвешле цензура аша узганлыгы гаҗәпләнү тудыра. Дөрес, ул М. Җәлилне коммунистлар идеологиясе тегерменәнә су коючы сыйфатында телгә ала. Батыр халыкның үз мәнфәгатьләрен кайгыртуы, ул чор өчен куркыныч булган милләтчелек дигән сүз белән бәяләнгән бервакытта, татар язучыларын әнә шулай нигилист итеп күрсәтү ул елларда идеологларга файдалы иде. Моны әле рәсми

[1] Мостафин Р. Өзелгән җыр эзеннән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. Б. 38.

рәвештә илгә «хыянәт иткән» дип исәпләнүче М. Җәлил исеменнән башка да эшләргә мөмкин булгандыр. Г. Кашшаф, шушындый юл белән генә булса да, дустының исемен матбугатта күрсәтергә теләгән күрәсең»[1].

1944 елда Җәлил үлемгә хөкем ителә һәм үтерелә. Шушы ук елны Казанда шагыйрьнең «Письмо из окопа» исемле яңа җыентыгы басылып чыга. Китап турында беренче булып кайгыртып йөргән кеше – Г. Кашшаф. Ул аны төзеп бирә, күзәтеп бастыра. Әмма шагыйрь язмышы турында әлегә берни белми.

Сугыштан соңгы беренче елларда Моабит дәфтәрләре кайтып җитә һәм төрле шикләр куера. Инде искәртеп үтелгәнчә, шушы «ярамаганлык» шартларында да тәнкыйтьче дустының әсәрләре хакында үз мәкаләләрендә язып тора. М. Җәлил язмышы өчен иң беренчеләрдән булып Г. Кашшаф борчыла. Ул шушы мәсьәлә белән Татарстан Өлкә Комитеты секретаренда була, аның тәкъдиме белән 1948 елны Мәскәүгә – СССР Язучылар союзының секретаре А. Фадеевка бара, мәсьәләнең торышы белән таныштыра, шагыйрьгә булган ышаныч турында сөйли.

Әлбәттә, шагыйрь исемен һәм иҗатын кабат халыкка кайтару эше Г. Кашшафны күп юллар таптата. Аны яклап чыгучылар булган кебек, каршы якта торучылар да аз булмый. Шуңа да карамастан, тәнкыйтьче бирешми.

«Совет әдәбияты» журналында шактый озак – биш ел буе аның белән янәшә, аның кул астында эшләгәнлектән, остазы һәм редакторы Г. Кашшафны Г. Ахунов чыннан да яхшы белә. Заманында ул аның иң яраткан шәкерте булган. Бергә эшләгән елларны искә төшереп, Г. Ахунов үзенең остазына чынлап торып соклана, аның эшчәнлеген үзенчә кадерләп кенә искә төшерә. Г. Ахуновның «Мәдәни җомга» газетасында басылып чыккан «Беренче остазым» мәкаләсендә без күп кенә кызыклы мәгълүматлар белән очрашабыз[2]. Мәсәлән, редакциядә булган бер вакыйга Г. Кашшафның М. Җәлилгә

---

[1] Галимуллин Ф. Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 72.

[2] Ахунов Г. Беренче остазым // Мәдәни җомга. 1997. 1 май.

багышланган эшчәнлеген яктырта. Биредә әлеге вакыйгага кагылышлы төп репликалар гына китерелде.

«Ул беркайчан да кул астындагыларга тавышын күтәрми, беркайчан да ачулана белми, аның, әйтик, сиңа хәтере калганын артыгы белән басынкыланып киткән булуыннан гына белергә була иде.

Мин аның бер генә нәрсәгә көенгәнен, вакыт-вакыт кына түгел, берничә ел рәттән көенгәнен беләм. Ул да булса – М. Җәлил язмышы. Мин илленче елларда гел дә авыл малае кебек кенә идем әле. Шулай да, мине үзе белән тиң күреп, Җәлил язмышы өчен борчылганын әйтә, журналга җыелган материалны үземчә редакцияләп бетереп, машинкада, кабат бастырып алып кергәч, бер читкә иплəп кенә алып куя да:

– Ярар, мин аны дачага алып кайтып укып килермен, – ди, – монда аны укырга барыбер ирек бирмәсләр...

Мин аның, дымланып киткән күзлеген салып, күзлек пыялаларын озаклап сөрткәнен карап утырам. Ул хәзер күптәнге дусты, бала чактан ук белгән ахирәте Муса турында сүз башлаячак.

Минем көткәнем аклана.

– Мусаның язмышы хәл ителми бит әле, Гарифҗан, – ди ул һәм авыр гына көрсенеп куя.

...1953 ел башларында редакциягә ифрат сөенечле хәбәр алынды. Аны Гази ага үзе алып килде. Ул бүген гадәтенчә төштән соң килмәде, иртәнге унда ук килеп җитте. Йөрүе дә үзгәргән, протезлы аягын ул озаклап яннан китереп салмый, селтәп-селтәп кенә килә, аның көйрәп кабынган коңгырт күзләреннән үк дөньяда бик тә мөһим бер хәл булганын аңлавы кыен түгел иде.

– Гарифҗан, балакаем... булды бу! – диде ул һәм аһылдап урындыкка килеп утырды. Өстен салырга да онытты.

– Менә, кара, кара, балакаем, – диде.

Ул биргән «Литературная газета»ны ачып җибәрсәм, «Моабит зинданында язылган шигырьләр» ярылып ята.

– Котлыйм, Гази ага!

– Котла, балакаем, котла, татар әдәбияты өстенә ыргытылган кара тап алып ташланды, батырның исеме илгә кайтты. И матур

көннәр булыр инде. Булыр, балакаем, шөкер, мин ул көннәргә тикле килеп җиттем... – диде. Аның тавышы киселде, күзләрен яшь пәрдәсе каплады»[1].

Озак та үтми, Г. Кашшаф М. Җәлилнең көрәштәшләрен эзләргә, аның мирасын халыкка кайтару өчен илне гизәргә чыгып китә.

1953 елда «Литературная газета» битләрендә М. Җәлилнең Моабит шигырьләренең бер өлеше басылып чыга, шагыйрьнең исеме аклана, язмышы ачыклана. Аның иҗатын бу елларда халыкка җиткерүдә янәдән Г. Кашшаф тырыша. Егерме бишенче апрель исә, чын-чынлап, герой-шагыйрьнең икенче туган көне дип йөртелә башлый.

М. Җәлилнең исеме ни өчен озак еллар реабилитацияләнә алмавы хакында, төрле документларга таянып, Р. Мостафин язып чыга. Карарның тоткарлану сәбәбе – элекке әсирләрнең күрсәтмәләренә кайтып кала. Аларның кайберләре исемнәрен аклау максатыннан төрле гайбәтләргә таянса, икенчеләре капма-каршы җавап тота. Нәтиҗә буларак, «1947 елның 5 нче апрелендә татар язучылары Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш исемнәре МГБ СССР дүртенче управлениесе тарафыннан берничә рәт сәяси маддәләр буенча шик тудырган аеруча куркыныч җинаятьчеләр исемлегенә кертеләләр. Әлеге исемлек агентураның бөтен челтәре буенча, шул исәптән чит илләргә дә җибәрелә»[2].

1953 елда ук Г. Кашшаф беренче тапкыр Моабит шигырьләре җыентыгын әзерли, фәнни комментарийлар бирә һәм бастырып чыгара. Җыентыкның кереш мәкаләсе дә М. Җәлилнең исеме аклануын дәлилләп, «Үлемсезлек» дип атала.

М. Җәлилнең тууына илле ел тулуны билгеләп үтү елларында (1955 – 1956), аның өч томда «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрә. Төзүче итеп шагыйрьнең хатыны – Әминә Җәлилова күрсәтелсә дә, З. Рәмиев хаклы рәвештә әлеге җыентыкны Г. Кашшафның зур күләмле текстологик хезмәте буларак исәпли. Тәнкыйтьче томнарга

[1] Ахунов Г. Беренче остазым // Мәдәни җомга. 1997. 1 май.
[2] Мустафин Р. Засекреченные страницы // Литературная газета. 2006. № 9.

кереш сүз яза, комментарийлар әзерли һәм китапларны редакцияли[1]. Рус укучысына сайланма әсәрләр бер томда тәкъдим ителә.

М. Җәлилнең исемен, иҗатын халыкка җиткерүдә тәнкыйтьче күп кенә эшләр башкарса да, моның белән генә канәгать калмый, башкаларны да әлеге эшкә тартырга тели: «Муса турында истәлек кирәк! Шушы сүзләр белән мин кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем! Язучыларга, артистларга, композиторларга, белеш-танышларга, дусларына, көрәштәшләренә... Берсе дә тәкъдимемне кире какмады, бик яхшы эш, изге эш, диделәр, шундый истәлекләрнең киләчәк буыннар өчен аеруча кыйммәтле булачагын искә төшерделәр һәм... истәлекләр ява башларга тиеш иде, билгеле. Тик алай булмады...»[2]. Г. Кашшаф эшенең янә бер юнәлеше туа – эзләү. «Миңа дистәләрчә кешеләр белән хат язышырга, дистәләрчә иптәшләр янына барып кайтырга, бик күпләрне күреп сөйләшергә һәм хәтерләрендә сакланган энҗе бөртекләрен инә белән казып алырга туры килде», – дип яза ул үзенең «Соңгы сүз» дип аталган мәкаләсендә[3]. Әлеге мәкалә «Муса турында истәлекләр» китабының ахырына урнаштырылган

Истәлекләрне туплау өчен Г. Кашшафка әле Магаданга, әле Заполярьега, әле Әфган чигенә, әле төньякка, әле көнбатышка... Урта Азиягә, Кавказга барырга туры килә. Бертуктаусыз хат алышулар, очрашулар. Күп кенә фактлар билгеле түгел, күп кенә шаһитлар вакыйгаларны төгәл хәтерләми. Берсе бер фикер әйтә, икенчесе – икенчесен. Ниһаять, тәнкыйтьче-галимнең сабырлыгы, тырышлыгы белән дәлилләнгән фактлар бергә тупланып, 1964 елда истәлекләр дөнья күрә.

Г. Кашшаф 1957 һәм 1960 елларда М. Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын яктырткан очерклар яза. Шагыйрьнең балачагын, үсмер чагын һәм яшьлеген, иҗатын күзәтеп чыгу да җиңел эшләрдән түгел. Моның өчен М. Җәлилнең туган якларын, туганнарын күрергә, һәрбер детальне күздән ычкындырмый теркәп ба-

[1] Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века. Казань: «Алма-Лит», 2008. С. 130.

[2] Кашшаф Г. Муса турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. Б. 306.

[3] Шунда ук, Б. 308.

рырга туры килә. Г. Кашшаф әлеге эшне дә намус кушканча башкарырга тырыша. Моннан тыш ул һәрвакыт төрле очрашулар, кичәләр уздырып тора, яшь буынга шагыйрь турында истәлекләрен сөйләп калырга ашыга.

М. Җәлилнең тууына 70 ел тулу уңаеннан, 1974 елның башында, герой-шагыйрьнең 4 томлык фәнни басмасын, фотоальбомын һәм сайланма әсәрләрнең русча вариантын бастырып чыгару мәсьәләсе күтәрелә, һәм бу эш СССР ФА КФ Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторына йөкләнә. Н. Юзиев җитәкчелегендә төзелгән редакцион коллегиягә Ш. Галиев, Ә. Исхак, Г. Кашшаф кертелә. Соңгысы томнарның төзүчесе һәм комментарийлар авторы итеп билгеләнә[1]. Әмма Г. Кашшафның сәламәтлеге какшау сәбәпле, Н. Юзиев әлеге эшкә ярдәмчеләрне – институтның фәнни хезмәткәрләре, текстологлар Ф. Ибраһимова һәм Н. Ханзафаровны билгели.

Соңгы көннәренә кадәр Г. Кашшаф М. Җәлилне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеген дәвам итә, соңгы сүзендә дә аның гаиләсе турында кайгыртуын яңгырата. Шагыйрьнең тууына җитмеш ел тулуга берничә ай кала Г. Кашшаф соңгы юлга озатыла.

Г. Кашшафның гомере өзелү белән, М. Җәлилне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлек туктамый. Аның шәкертләре әлеге хезмәтне үз җилкәләренә йөкли. «Үзенең каләмдәше һәм якын дусты Муса Җәлилнең бу васыятен намус белән үтәп, Гази Кашшаф язучы Рафаэль Мостафинны да герой-шагыйрь иҗатын өйрәнүгә юнәлтте», – дип яза И.А. Ахунҗанов[2]. «Бервакыт шулай, ничектер, Гази Кашшаф янына керәсе иттем. М. Җәлилнең әсирлеккә кайчан эләгүе турында ни өчен шундый төрле караш булуы турында сорадым», – дип искә төшерә Р. Мостафин[3]. Шушы керүдән соң ул да М. Җәлилне өйрәнү дәрьясына кереп чума. Ә. Гаффар, эшнең дәвамлылыгын ассызыклап, болай яза: «Муса Җәлил Гази

[1] Рамеев З.З. Текстология татарской литературы начала XX века. Казань: Алма-Лит, 2008. С. 131.

[2] Ахунҗанов И.А. Остаз // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 8.

[3] Шунда ук. Б. 7.

Кашшафның игелекле, иманлы бер кеше – тәнкыйтьче галим, тугры иптәш икәнлеген алдан күрә белеп, үз әсәрләре язмышын кайгыртуны аңа васыять иткән. Һәр останың, әгәр ул чын оста икән, билгеле, үз шөгылен тапшырыр шәкерте була. Гази ага Җәлил фәне сукмагына Рафаэль Мостафинны да бастырды. Ә шәкерт – әгәр ул ихлас шәкерт икән – бик тиз мөстәкыйльлек ала, остазы юлыннан аягын ныклап басып китә»[1]. Бу бердәмлекнең нәтиҗәсе булып, 1965 елда «Эзләнүләр дәвам итә» дигән китап дөньяга килде. Шулай итеп Г. Кашшаф талантлы яшь тәнкыйтьчегә игътибарын юнәлтте, аны канат астына алды, ә аннары, аның үз канатлары ныгыгач, иҗат юлына фатиха бирде. Фидакарь эшчәнлекләре өчен, Г. Кашшаф һәм Р. Мостафин Республиканың М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булалар.

И. Ахунҗанов: «Һәм шулай ук мин дә үземне Гази аганың шәкерте дип исәплим. Минем дөнья күргән әзме-күпме хезмәтләремдә Г. Кашшафның йогынтысы, аның ярдәме гаять зур», – дип яза[2]. Димәк, тәнкыйтьче үз эшенең белгече, аның асылына төшенеп һәм эшкә кызыксынуны, мәхәббәтне укучыларына җиткереп торган чын педагог була.

Нәтиҗәдә бүген язылган күп кенә хезмәтләр – Г. Кашшаф башлаган эшнең дәвамы. Р. Мостафин, В. Воздвиженский, Ә. Мәхмүдев, Ю. Корольков, Р. Бикмөхәммәтов, И. Зәбиров һ.б. ның документларга нигезләнеп язылган хезмәтләре, шагыйрьнең образын сурәтләгән күпсанлы әдәби әсәрләр дә моны раслап тора: «Муса» (Ш. Маннур), «Муса Җәлил» (Н. Исәнбәт), «Үлмәс җыр» (Р. Ишморат), «Моңлы бер җыр» (Т. Миңнуллин) һ.б. Әлбәттә, яңа фактлар табыла тора, һәм алар Г. Кашшафның эшен тулыландыра, баета бара. Бүгенге әдәбият галимнәре арасында М. Жәлил ижатына Х. Миңнегулов, Т. Галиуллин, Ф. Галимуллин, Д. Заһидуллина, М. Йосыпова һ.б. игътибар бирәләр.

---

[1] Гаффар Ә. Гасырлар улы // Ватаным Татарстан. 2006. 10 февраль.

[2] Ахунҗанов И.А. Остаз // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 6.

Бүген шагыйрьнең шәхси тормышын яктырткан мәкаләләр аз түгел. Аларда без М. Җәлилнең балалары, сөйгән ярлары турында тулырак мәгълүмат белә алабыз. Г. Кашшаф та алар турында хәбәрдар булган. Замана таләбе беләнме, әллә әлеге мәгълүматларны халыкка җиткерүне үзмаксат итеп күрмәгәнгәме, ул аларны телгә алмый. Күпчелек укучылар өчен ул кирәкми дә. Шәхси тормыш һәр шәхеснең үз эше. Татар халкына М. Җәлил батыр, патриот шагыйрь буларак кадерле. Г. Кашшафның эшчәнлеге бәясез. Соңгы елларда М. Җәлилнең исеменә төшкән кара тап әледән-әле төрле «хакыйкать эзләүчеләр» тарафыннан яңартыла. Бу аеруча 2008 – 2009 елларда вакытлы матбугат битләрендә ачык чагылыш тапты. Ф. Бәйрәмова Алманиядә яшәүче хокук фәннәре докторы, «Азатлык» татар-башкорт радиосына нигез салучы, ярты гасыр буе татар халкын яклап, халыкара мөнбәрләрдән чыгышлар ясаучы Гариф Солтановка уңай бәясен матбугат битләрендә белдерә. Әлеге язмаларга җавап рәвешендә Р. Мостафинның «Хаиннан батыр ясап буламы» дигән язмасы дөнья күрә[1]. Әлбәттә, сүз турыдан-туры Г. Солтан шәхесенә караса да, мәкаләләрнең нигезендә М. Җәлилнең әсирлектәге язмышын ачыклауга кайтып кала. Мәкаләләр белән танышып чыкканнан соң, чыннан да уйга каласың. Һәр автор да үз фикеренә ышандырырлык, дәлилле яза. Ләкин фактлар Җәлилнең героик исеменә тап төшерергә тиеш түгел. Яшерен оешманың булуы, димәк, төрледән-төрле сүзләр куертылуга, ялган, алдашу сүзләре йөртергә дә урын калдырган. Әлеге үткән вакыйгаларга дөрес бәя-аңлатмалар биреп, тарихи факт буларак өйрәнергә вакыт. Шушы уңайдан Ф. Бәйрәмова һәм Р. Мостафиннарның язмаларына җавап рәвешендә басылып чыккан Г. Солтан белән унбиш елдан артык таныш булган һәм «Идел-Урал» легионы тарихын өйрәнгән И. Гыйләҗев мәкаләсе урынлы яңгырый: «Каһарманмы, хаинмы?»[2]. Тарихчы буларак, мәкалә авторы Ф. Бәйрәмованы һәм Р. Мостафинны үз шәхси мән-

[1] Мостафин Р. Хаиннан батыр ясап буламы? // Ватаным Татарстан. 2008. 12 декабрь.

[2] Гыйләҗев И. Каһарманмы, хаинмы? // Ватаным Татарстан. 2009. 16 гыйнвар.

фәгатьләрен онытып, объектив булырга чакыра һәм әлеге тарихи фактларга мөрәҗәгать иткәндә сак эш йөртергә тәкъдим итә.

2009 елда «Мирас» журналында М. Сәхапов һәм Э. Яһүдин тарафыннан иҗат ителеп басылган «Барбаросс инкыйразы»[1] исемле драмасы күпләрне шаккатырды. Әйе, бу әдәби әсәр, димәк монда уйдырманың булуы да ихтимал. Әмма әсәр эчтәлегеннән М. Җәлилгә карата яңгыраган фикерләр белән килешеп булмый. Дәлилсез, тарихи фактларга таянмау, инде әсәр басылгач та, язган сүзләр өчен анык җавап бирмәү бары тик уйдырма турында сүз йөртергә урын калдыра. Шулай да журнал чыккан, әсәр басылган, укучыга җиткерелгән. Һәрбер укучы да матбугат битләрендә драма уяткан полемика белән таныша да алмый. Кызганычка каршы, бу безнең бүгенге әдәбият тарихына кереп калачак аяныч вакыйгалар. Шул ук вакытта, «Мирас» битләрендә пьесага карата басылган бәяләмәләр дә дөнья күрде. Алар арасында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Б. Урманче премиясе лауреаты, Татарстанның Рәссамнар союзы әгъзасы К. Нәфыйковның сүзләре Г. Кашшафның эшчәнлеген дә шик астына алу булып яңгырый: «Муса Җәлил төрмәдә язган шигырьләре өчен Герой исеменә лаек булды. Ә сугыш елларында, төрмәгә чаклы ниләр булган, аның эшчәнлеге безгә билгесез, караңгы. Шәхеснең тормышын күбрәк белсәк, шәхеснең формалашуын аңларга әйбәтрәк булыр иде»[2]. Мәкалә исеменә чыгарылган сүзләр эчтәлектә ачылмый. Драманың әсәр буларак яңалыгы нидә? – дигән сорау ачык кала.

Р. Зарипов: «Җәлилне аклауда иң зур фидакарьлек күрсәтүче зат Гази Кашшаф иде бугай»[3], – дип язса да, бу сүзләр Р. Мостафинның эшчәнлеген кимсетү, М. Җәлилне аклау юлында түгел. Журналист Р. Җәмдихан фикеренчә, Совет хакимияте татар халкының аңа буйсынуын күрсәтү өчен «ясалма герой» – Муса Җәлилне тудырган[4]. Руста үзендә шундый герой булмый торып, шагыйрь вафатыннан соң

[1] Сәхапов М., Яһүдин Э. «Барбаросс» инкыйразы // Мирас. 2009. № 6, 7.

[2] Нәфыйков К. «Барбаросс инкыйразы» татар драматургиясенә яңалык алып килүче // Мирас. 2009. № 11. Б. 139.

[3] Зарипов Р. Кемгә тәүбә итәсе? // Мирас. 2009. № 11. Б. 27.

[4] Җәмдихан Р. Чын тарихны өйрәнергә кирәк // Мирас. 2009. № 11. Б. 55–63.

9 ел үткәч мондый геройның барлыкка килүе кемне ышандырыр икән. Үткен телле язучы Ф. Баттал да, бу хәлгә битараф кала алмыйча, дөреслекне табырга тырыша[1]. Әсирлек язмышын татыган тоткыннарның серләре бүген дә ачылып бетми.

Әлбәттә, М. Җәлилнең исемен түбәнсетүгә каршы бүгенге көн язучылары, зыялылары күтәрелеп чыкты. «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Мәгърифәт» һ.б. газета-журналларда күпсанлы җаваплар моны ачык күрсәтә. 2009 елның май аенда бер төркем татар әдипләре тарафыннан Язучылар берлегендә «Эшлекле мәҗлес» уздырыла. Анда Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь И. Ибраһимов, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык язучысы Т. Миңнуллин, «Татарстан» журналының бүлек мөдире, язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин, Татарстанның халык язучысы Р. Батулла, Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р. Вәлиев, КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультеты деканы, тарих фәннәре докторы, ТР Фәннәр академиясенең мөхбирәгъзасы И. Гыйләҗев, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь З. Мансуров, «Идел» журналының бүлек мөхәррире Р. Зәйдулла һ.б. катнашалар. Бу хакта «Тик антыма таплар кунмасын» дип исемләнгән мәкаләдә бәян ителә. Язма төрле ялганнарга бер мөнәсәбәт белдерү генә түгел, күп кенә сорауларга җавап бирү буларак та яңгырый. «Мирас» журналында пьесаны яклап чыккан язмалар да фактларга таянып эш итмәве белән бик йомшак яңгыраш алганнар. М. Җәлилнең исеме совет заманында да, хәзер дә татар гына түгел, рус галимнәренең хезмәтләрендә дә үрнәк итеп куела[2]. Язучы, шагыйрь, драматург Р. Зәйдулланың сүзләренә кушыласы килә: «Иң мөһиме – аның татар милләте өчен

---

[1] Баттал Ф. Хакыйкать кадерлерәк // Мирас. 2009. № 9. Б. 29–41.

[2] Советская многонациональная литература (Очерк развития): учеб. пособие для филол. спец. вузов / О.А. Баканидзе, Г.А. Белая, Р.Г. Бикмухаметов и др.; Под ред. Г.И. Ломидзе; отв. ред. Н.С. Надъярных, С.М. Хитарова. М.: Высш.шк., 1986. С. 9; Введение в литературоведение: учеб. пособие / Л.В. Чернец, В.Е. Хализев, А.Я. Эсалнек и др.; Под ред. Л.В. Чернец. М.: Высш.шк., 2004. С. 85.

рухият каһарманы булуында. Ул тоткынлыкта үлемсез әсәрләр иҗат итеп, безгә моны тулысынча раслады. Шундый авыр шартларда шигырьләр язган кеше буларак, ул, әлбәттә, безнең горурлыгыбыз саналырга хаклы. Бу шулай булып калачак та»[1]. Әлеге «Эшлекле мәҗлес»тә катнашучыларның фикерен яклап, пьеса басылганнан соң да күп кенә мәкаләләр дөнья күрә: Р. Кашаповның «Дәлилсез, нигезсез уйдырма», М. Черепановның «Сер булып калган батырлык», Р. Мостафинның «Яла», «Мәгърифәт»тә басылып килгән кайтавазлары һ.б.

Беренче Президентыбыз М.Шәймиевнең татарның батыр улы турында китерелгән сүзләренә тукталып китик: «Муса Җәлил иҗаты – бай күпмилләтле Россия сәнгатенең, аның уникаль әдәби мирасының аерылгысыз бер өлеше. Ә аның тормышы – югары әхлак идеалларына тугры калу үрнәге, ватанпәрвәрлек, батырлык, героизмның чын символы»[2]. Татар халкы өчен төгәлләштерелгән М. Шәймиев сүзләре дә урынлы яңгырый: «Муса Җәлил – татар халкының аерым бер горурлыгы, какшамас милли рух символы ул»[3].

М. Җәлил һәм Г. Кашшафны тормышта дуслык бәйләп торган кебек, әдәбият тарихы да берләштерә. Җәлил фәненә нигез салган тәнкыйтьченең эшчәнлеге ихтирамга ия, ул – лаеклы хезмәт. Әлеге фактны аның замандашлары гына түгел, бүгенге укучы да белеп бәяләргә тиеш. Г. Кашшафның бу өлкәдәге эшчәнлеген алга таба да өйрәнергә, башка хезмәтләрдә китерелгән мәгълүматлар белән чагыштырырга мөмкин.

---

[1] Муса Җәлил: Тик антыма таплар кунмасын. Эшлекле мәҗлес // Мәдәни җомга. 2009. 22 май.

[2] Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века / сост. Х.Ю. Миннегулов, Н. М. Юсупова. Казань: Казан. ун-т, 2006. С. 4.

[3] Үлемсез җыр. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевның Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган тантаналы җыелыштагы чыгышы // Ватаным Татарстан. 2006. 27 февраль.

### 4.2. Г. Кашшафның М. Җәлил турындагы төп хезмәтләре

Әйтеп үтелгәнчә, Г. Кашшаф беренчеләрдән булып М. Җәлилнең иҗатын һәм тормыш юлын халыкка җиткерүче тәнкыйтьче-галим.

Г. Кашшафның М. Җәлил турындагы беренче язмалары 1941 елда дөнья күрә. Кыска гына мәкаләдә автор «Алтынчәч»не искә ала, «Хат ташучы» поэмасына туктала. Әсәрнең бер уңышы – аның халык җыры рәвешендә язылуында, дип билгели тәнкыйтьче һәм поэманың русчага тәрҗемә ителүен көтә[1].

Сугышка кадәр Г. Кашшаф, нигездә, шагыйрьнең иҗатына караган махсус мәкаләләр белән чыгыш ясамый. Белгәнебезчә, 1942 елда ул аның «Тупчы анты» шигырьләр җыентыгын бастырып чыгара. 1943 елда композитор Ж. Фәйзи белән берлектә «Татар операсының үсүе»н күзәтеп, тәнкыйтьче «Алтынчәч»кә бәяләмәсен тәкъдим итә[2].

Сугышның соңгы елларында М. Җәлилнең исеме телгә алынмый. 1947 елда Г.Кашшаф дустының исемен һәм кайбер әсәрләрен үзенең мәкаләләренә кертергә җөрьәт итсә дә, шагыйрь укучылар игътибарын җәлеп итми. 1953 елда М. Җәлилнең исеме һәм батырлыгы рәсми рәвештә танылгач, Г. Кашшаф озак еллар тупланган сүзләрен, мәкаләләрен укучыга җиткерергә тырыша, 1953 елда ук ул «Совет Татарстаны», «Советская Татария», «Комсомолец Татарии», «Совет әдәбияты», «Известия», «Кызыл таң» һ.б. басмаларда, герой-шагыйрьнең үлемсезлеген расларга ашыгып, язмаларын бастыра. М. Җәлилнең «Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр» җыентыгын да Г. Кашшафның «Үлемсезлек» дигән кереш мәкаләсе ачып җибәрә.

Г. Кашшафка калдырылган васыятендә әйткәнчә, М. Җәлил үзе исән чагында язган әсәрләренең 30 – 35% гына бастырып чыгарган, калганнары исә кульязма хәлендә калган була. Басылган әсәрләре дә

---

[1] Кашшаф Г. Творческий успех поэта Мусы Джалиля // Красная Татария. 1947. 30 апреля.

[2] Кашшаф Г., Фәйзи Җ. Татар операсының үсүе // Совет әдәбияты. 1943. № 8. Б. 72–78.

төрлесе төрле газета-журналларда һәм төрле елларда чыккан булып, аларны бергәмләп җыйнарга туры килә. Заманында шагыйрь үзе редакцияләргә тапшырып та, басылып чыкмыйча калган әсәрләрне редакция архивыннан эзләп табу шулай ук аның өстенә төшә. Ләкин Г. Кашшаф иренми, материалларның барысын да туплый, Җәлилнең васыятен үтәп, аларны үзе әзерләп һәм редакциялап, китап итеп бастыра. Шул ук вакытта, шагыйрь турында үзе дә китап яза һәм 1957 елда ул «Муса Җәлил. Тормышы һәм иҗаты турында очерк» дигән исем астында дөнья күрә. Яңа материаллар белән тулыландырылган вариант 1961 чыгарыла.

Әлеге китапларга карата Н. Юзиевнең бик урынлы әйтелгән сүзләре бар: «Һәр язучының «төп китабы», «алтын китабы» булган кебек, тәнкыйтьче-әдәбиятчының да иҗатында әнә шундый иң әһәмиятле хезмәтләре була. Гази Кашшафның да «төп китабы», «алтын китабы» бар. Бу – аның Җәлил турындагы хезмәтләре, «Муса Җәлил» исемле монографиясе (1957 һәм 1961 еллардагы басмалары)[1].

Чыннан да, Г. Кашшафның күп еллар дәвамында башкарылган киңкырлы эшчәнлеге тулысы белән бу монографияне тудыруга хезмәт иткәндер дип әйтү хата булмас. Г. Кашшаф – тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, публицист. Монографиядә авторның бу сыйфатлары ачык чагылалар, бер-берсен тулыландырып киләләр. Тәнкыйтьче осталыгы М. Җәлилне шагыйрь һәм язучы буларак танытырга ярдәм иткән. Әдәбият тарихчысы булу – Җәлилнең иҗатын әдәби процесс агымында, тарихи планда, мохиттә күрсәтергә, тормыш һәм иҗат юлының тулы күренешен тудырырга ярдәм иткән. Язучы, публицист-журналист булу аны шагыйрь турында хикәяләүне киң катлам укучыга аңлаешлы итеп, әдәби телдә язарга этәргән.

Биредә шулай ук шагыйрь белән тәнкыйтьченең дуслыгын истән чыгармаска кирәк. Турыдан-туры әдип белән аралашкан кеше генә үз сүзен үлчәп, кирәкле урында чикләп, дөреслеккә сый-

[1] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 137.

дырышлы итеп яза алган. Г. Кашшафның фидакарьлек, тугрылык, сабырлык, тыйнаклык, гаделлек, кешелеклелек һәм башка сыйфатлары, һичшиксез, хезмәтнең ни дәрәҗәдә чынбарлыкка туры килүен раслап торалар.

Г. Кашшафның 1957 елда чыккан хезмәтен, алдан ук искәртеп узыйк, Җәлил исеме илгә кайтарылганнан соң дүрт ел узгач дөнья күргән һәм аны шул елларда үткәрелгән эшчәнлек-эзләнүләрнең бер нәтиҗәсе дип кабул итәргә тиешбез. Монографиянең башында ук Г. Кашшаф М. Җәлилне Ю. Фучик белән янәшә куеп карый: «... бу тиңдәшсез батырлыкка хәзер бөтен дөнья сокланып баш ия. Аның берсе – Чехословакия халкының турылыклы улы, шагыйрь-журналист, подпольеда чыныккан коммунист Юлиус Фучик, икенчесе – совет халкының кайнар йөрәкле улы һәм офицеры, татар шагыйре, коммунист Муса Җәлил»[1]. Очеркны тәнкыйтьче шагыйрьнең туган ягына, гаиләсенә мөнәсәбәттә башлый. Г. Кашшаф фикеренчә: «Телнең матурлыгын, музыкасын Муса беренче кат әбисе әкиятләреннән ишеткән. Шуның белән бергә ул рәхимсезлеккә, вәхшилеккә каршы нәфрәтләнергә дә өлгергән»[2]. Тәнкыйтьче, күрәсең, истәлекләргә таянып, М. Җәлилнең башка балалардан аерылып торуын билгеләп уза. Шагыйрь бала чакта ялгызлыкны сөя төшә, рәсем ясарга, укырга ярата, аны музыка дулкынландыра. Укырга мөмкинчелеге булса да, кечкенә Мусага төрле кыенлыклар кичерергә дә туры килә. Илдә барган вакыйгалар, әтисенең эшсезлеге, гаиләдә балаларның күп булуы матди житмәүчелек тудыра. Әмма шул шартларда да Муса югалып калмаган, үз шөгелен тапкан.

Мостафа авылыннан Оренбургка күчү, Хөсәения мәдрәсәсендә уку, «Белек» китапханәсе, шигырь язуда беренче тәҗрибәләр – тәнкыйтьче Муса язмышындагы әнә шундый бер генә детальне дә күз уңыннан төшерми. Шагыйрьнең мәдрәсәдә Ш. Камал, Ш. Бабич кебек шәхесләр белән очрашуы, Тукай, Гафури кебек әдипләрнең иҗат традицияләре аның бу чор әсәрләрендә

[1] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Тормышы һәм иҗаты турында очерк. Казан: Таткнигоиздат, 1957. Б. 14.

[2] Шунда ук. Б. 10.

урын ала, дип белдерә Г. Кашшаф. Хезмәттә шулай ук, параллель рәвештә, М. Җәлилнең иҗтимагый тормыштагы активлыгы да билгеләнә. Яшь шагыйрь балалар өчен оешма төзи, аларда үзе башлап йөри.

Г. Кашшаф әлеге китапта М. Җәлилгә кагылышлы фактларны теркәп баруны гына күздә тотмый. Шагыйрьнең иҗаты һәм тормышы илдә барган иҗтимагый-сәяси вакыйгалар белән үрелеп бирелә. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче, вакыт-вакыт, бу чорда иҗат иткән язучы-шагыйрьләрнең әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, аларга да кыскача күзәтү ясап уза. Мәсәлән, Г. Ибраһимов, М. Гафури, К. Нәҗми, Ш. Камал һ.б.ның әсәрләренә туктала.

1922 елда Һ. Такташ, Г. Кутуй, Ф. Әсгать, М. Җәлил Казанга киләләр һәм биредә яшәүче К. Нәҗми, А. Шамов, Ярлы Кәрим кебек. талантлы яшьләргә кушылалар, әдәбиятны яңа эчтәлек белән баетырга омтылалар. «Ләкин яшьләрнең шушы кайнар омтылышларын җитәкләүче, аларга тиешле юнәлеш бирүче большевистик әдәби тәнкыйть булмый. Яшьләр үз-үзләренә биреләләр һәм, үзләре дә сизмәстән, аларны вак буржуаз стихиячелек чолгап ала»[1]. Шулай итеп Г. Кашшаф чор тәнкыйтенә дә бәясен биреп уза.

Очеркта М. Җәлилнең үзенең дә иҗатына булган бәяләмәләрен бирү уңышлы килеп чыккан. Шул рәвешле, тәнкыйтьче шагыйрьнең үз бәясен һәм тәнкыйтьчеләрнең фикерен кисештерә алган. Мәсәлән, моның ачык мисалы – М. Җәлилнең Гомәр Хәйям, Сәгъди, Хафизларны яратып укуында чагылыш таба[2].

М. Җәлилгә МГУның әдәбият һәм сәнгать факультетының тәнкыйть циклы буенча редакцион-публицистик бүлеген тәмамлавы турында 1931 елның 19 июнендә таныклык бирәләр һәм шул уңайдан Г. Кашшаф аның әдәби тәнкыйть өлкәсендә хезмәте киң җәелгәнен ассызыклый[3]. Шул ук вакытта, шагыйрьнең архивын өйрәнгәннән

---

[1] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Тормышы һәм иҗаты турында очерк. Казан: таткнигоиздат, 1957. Б. 99.

[2] Шунда ук. Б. 119.

[3] Шунда ук. Б. 179.

соң, тәнкыйтьче М. Җәлилнең татар совет опера культурасын үстерүгә зур өлеш керткәнен билгели.

Сугыш елларында М. Җәлилнең фронтка китүе, аянычлы язмышы турында Г. Кашшаф аның көрәштәшләре, исән кайткан сугышчыларның истәлекләренә таянып яза. Моабит дәфтәрләренең туган илгә кайтуына, төрле шикләрнең таралуына ирешеп, ниһаять, тәнкыйтьче васыятен үтәү юлында беренче адымнарын да ясый. Әйтергә кирәк, хезмәт шактый кызыклы, җиңел тел белән язылган булса да, аны тоташтан укып чыгу авырлык тудыра. М. Җәлил турында бүгенге көндә киң катлам укучыга таныш булган фактларның барысы да әлегә китапка кермәгән. Хезмәтнең өчтән бер өлеше генә Җәлилнең сугыштагы һәм әсирлектәге язмышын яктырта. Әмма бу китап чорның иң кыйммәтле ядкярләренең берсенә әверелә.

Дүрт елдан соң Г. Кашшаф бу хезмәтен түбәндәге юллар белән сыйфатлый: «1957 елда безнең «Муса Җәлил» исемле әсәребез басылып чыкты. Ул роман да, поэма да түгел, бәлки шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү тәҗрибәсеннән чыгып язылган бер очерк иде. Әсәр китап кибете шүрлекләрендә ятып калмады, ул бик кыска вакыт эчендә сатылып бетте. Бу факт үзе үк Мусаның тормышы һәм иҗаты белән җәмәгатьчелекнең бик нык кызыксынганлыгын күрсәтә. Ләкин әле ул чакта безгә байтак нәрсәләр билгеле түгел иде»[1].

Хезмәтне бәяләп берничә рецензия дөнья күрә. Шуларның беренчесен С. Кудаш «Кызыл таң» газетасында бастырып чыгара[2]. «Ике китапны укып чыккач...» дип исемләнгән язмада Гали Халитның рус телендә язылган «Габдулла Тукай» һәм Г. Кашшафның «Муса Җәлил» хезмәтләре тикшерелә. Биредә рецензиянең бары икенче өлеше турында гына сүз бара.

С. Кудаш баштан ук хезмәт авторының киң планда эш итүенә басым ясый. Аның фикеренчә, текстны нәкъ менә очерк жанры

---

[1] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. Б. 4.

[2] Кудаш С. Ике китапны укып чыккач... // Кызыл таң. 1957. 11 апрель.

кысаларында бирү аклана. Әмма, шул ук вакытта, С. Кудаш авторның чама хисен югалтмавын да ассызыклый. «Гази Кашшаф үзенең язганнарына көчләп ышандырырга теләми. Бәлки Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын очерк теле белән сөйләп бирә. Үзенең положениеләрен, дәлилләр һәм тормыштагы фактлар белән беркетеп, алдыңа китереп бастыра. Шунлыктан син, китапны укыган чакта, аланнан калын урман эченә кереп киткән бер юлчы кебек, гомер юлы кечкенә Саелмыш елгасы буеннан башланып киткән Муса Җәлил белән 38 ел буена бергәләп йөрисең, бергә яшисең, бергә шатланасың, бергә кайгырасың»[1]. Китапның төп кыйммәтен М. Максуд та нәкъ менә шул формада язылуында күрә.

Шул ук елның май аенда әлеге хезмәткә рус телендәге бәяләмә «Советская Татария» газетасында басыла. Мәкаләнең авторы – Г. Кашшаф кебек үк Муса Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын тикшергән галим Р. Бикмөхәмәтов. Тәнкыйтьче фикере буенча, Г. Кашшаф шактый зур эш башкарып чыккан һәм бу китап аркылы укучылар өчен шагыйрь турында бик күп яңа фактлар ачыклана. Мисал өчен, Муса Җәлил кайсы төрмәләрдә утырган, кайсы лагерьларда булган, гитлерчыларга каршы нинди характердагы көрәш алып барган? һ.б. «Г. Кашшаф шагыйрь иҗатында билгеле бер дәрәҗәдә күләгәдә кала биргән тәрҗемә һәм әдәбият белеме өлкәсенә керткән өлешне шактый тулы яктырткан», – дип саный. Р. Бикмөхәмәтов[2]. Бер үк вакытта мактау сүзләре белән янәшә аерым кимчелекләр дә барлана. Шулар арасында рецензия авторы шигъри мисалларның кайбер очракларда уңышлы сайланмавына, вакыт-вакыт китапның бердәм стиле сакланмавына басым ясый. «Икенче яктан, бу –шагыйрьнең идея-эстетик үсеш, осталык, классиклардан өйрәнү мәсьәләләрен күтәреп чыккан чын мәгънәсендә җаваплы рәвештә эшләнгән фәнни тикшерену»[3].

Н. Юзиевнең тәнкыйди язмасы «Совет Татарстаны»нда басыла: «Бу китапта тәнкыйтьченең үсешен дә – аның эстетик караш-

---

[1] Кудаш С. Ике китапны укып чыккач... // Кызыл таң. 1957. 11 апрель.
[2] Бикмухаметов Р. Волнующая книга // Советская Татария. 1957. 23 мая.
[3] Там же.

лары тирәнәюен, язучы иҗатын әдәби процесс белән бәйләп бирүдә тагын да ныграк уңышка ирешүен, әдәби анализда социологиядән, турысызыклылыктан нык арынуын күрергә мөмкин. «Муса Җәлил» китабы – Гази Кашшаф иҗатындагы иң уңышлы, иң өлгергән әсәр. Тәнкыйтьченең үсеше, аның 1940 елны чыккан «Шәриф Камал» исемле монографик очеркы белән чагыштырганда, аеруча ачык күзгә бәрелә»[1]. Мәкаләдә хезмәтнең тел-стиль үзенчәлекләренә дә игътибар бирелә: «Авторның үз стиле турында да берничә сүз әйтеп үтик. Китап җиңел, аңлаешлы телдә, иркен язылган. Анда ясалма академизм, сөйләүне катлаулы төзү юк. Төрле язу стиленең кулланылуы китапны җанландыра, укучының кызыксынуын арттыра»[2].

«Совет әдәбияты» битләрендә «Беренче тәҗрибә» исемле тәнкыйди язмасын М. Максуд тәкъдим итә[3]. Автор Г. Кашшафның хезмәтен югары бәяли, хезмәтнең телен художество әсәренең теленә тиңли. Принципиаль әһәмияткә ия нәтиҗәләр арасында М. Максуд унөч яшьлек Мусаның шигырьләрен дөрес бәяләүне, «Тукай шигъри традициясеннән килә торган ритмик яңгыраш көчле булуын» күрсәтүне атый. «Алтынчәч», «Хат ташучы» кебек әсәрләргә төпле анализ бирелгәнен ассызыклый. Хезмәтнең югары бәягә лаек булуын кире какмый, рецензия авторы аерым бәхәсле моментларны да читләтеп үтми. Мисал өчен, М. Максуд әдәби хәрәкәт тарихына багышланган урыннарга туктала: хезмәттә формализм, гыйсъянчылык, футуризм, имажинизм кебек төшенчәләрне куллануга игътибар итә; Һ. Такташ үлгәннән соң поэтик эстафетаның кем кулына күчүе белән бәхәсләшә; китап авторы белән берлектә, Муса Җәлилнең иҗади эзләнүләре турында уйлана. Теләк рәвешендә түбәндәгеләр җиткерелә: «Мусаның Мәскәүдәге ун еллык тормышын тулырак яктырту, аның студиядәге һәм язучылар оешмаларындагы хезмәтләренә иркенрәк тукталу кирәк. Мусаның таланты ачылуда Мәскәү хәлиткеч роль уйнады. Шул ук елларда Мәскәү Нәҗип Җиһанов кебек зур

[1] Юзеев Н. Муса Җәлил турында фәнни китап // Совет Татарстаны. 1957. 4 окт.

[2] Шунда ук.

[3] Максуд М. Беренче тәҗрибә // Совет әдәбияты. 1957. № 12. Б. 98–102.

композиторны тәрбияләде. Муса белән бергә һәм Муса ярдәмендә эшләгән Ә. Фәйзи һәм Ә. Ерикәйләр операны әзерләүгә актив катнаштылар. Шулай ук ул елларда Язучылар союзы янында Мәскәүдәге татар язучыларының иҗат коллективы бик җанлы яши иде. Муса тормышына бәйләнешле булган бу моментларны тиешенчә яктыртуның әһәмияте бик зур»[1]. Әйтергә кирәк, тәнкыйтьченең сүзләренә колак салгандай, монографиянең 1961 елгы басмасында шагыйрьнең Мәскәү чорына Г. Кашшаф шактый киң туктала.

1961 елда чыккан хезмәткә килгәндә, ул шактый күләмле, 454 биттән тора. «Әкият ничек туа» дип исемләнгән кереш өлештә автор: «Шул рәвешчә, бу китап икенче тапкыр, төзәтелеп, арттырылып басылуына карамастан, тулылыкны вәгъдә итә алмый. Ләкин автор булган кадәресен әкият итеп түгел, бәлки чынны, бик күп истәлекләр белән тикшерелеп расланганны гына теркәде; ә чынлык үзе әкият итеп сөйләрлек... – дип »яза[2]. Тәнкыйтьченең үз эшчәнлегенә шундый бәя бирүен тыйнаклык дип әйтергә кирәк, чөнки ул М. Җәлилне өйрәнүгә нигез салучы, эшчәнлеге исә үз заманында да, хәзер дә кыйммәтен югалта алмаган һәм югалтмаячак та.

Монография, М. Җәлилне өйрәнүгә багышланган өлешендә, өч бүлектән тора:

1) шагыйрьнең яшьлек чоры;

2) зур адымнар белән;

3) шагыйрьнең Бөек Ватан сугышы елларындагы иҗаты.

Г. Кашшаф шул ук кереш мәкаләсендә әлеге китапны язу процессында башкарылган эшләрне дә яктыртып үтә. Билгеле, аңа барлык сорауларга да дөрес җавапны табуы җиңел булмаган. Бу юлда ул М. Җәлилнең дуслары, көрәштәшләре, туганнары, танышлары белән очраша. Төрле кешедән төрле хәбәр җыеп, дөресен табарга тырыша. Дөреслек исә күп очракта юлда гына ятмый. Аны эзләп әле чит илгә, әле Ватаныбызның билгесез бер почмагына барып чыгарга кирәк була. Г. Кашшаф үзен аямыйча гел тырыша, эзли, туплый.

---

[1] Максуд М. Беренче тәҗрибә // Совет әдәбияты. 1957. № 12. Б. 101-102.

[2] Кашшаф Г. Муса Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. Б. 8.

Монографияне башкарып чыгу юлында, Г. Кашшаф үз алдына берничә максат куеп эш итә. Шуларның иң мөһиме – М. Җәлилнең гомуми тормыш юлын, кече яшьтән башланган иҗатын мөмкин кадәр тулы күрсәтү. Шулай ук хезмәттә укучыны М. Җәлилнең тоткынлыкта үткәрелгән еллары, иҗат ителгән әсәрләре, көрәштәшләре белән таныштыру да үзәктә тора.

Очеркта хикәяләү автор тарафыннан алып барыла. Әмма һәр вакыйгага, һәр деталь-күренешкә тәнкыйтьченең битараф булмавы, аларга мөмкин булганча тирәнрәк үтеп кереп, үзе күргәннәрне укучыга тулаем җиткерергә теләве сизелеп тора. «Муса Җәлил» очеркы шагыйрьнең балалык, яшьлек елларын язып китү белән башлана. Әйтергә кирәк, әлеге бүлектә Г. Кашшаф безне М. Җәлилнең туганнары, якыннары, дуслары белән генә таныштырып калмый, ә нәни Мусаны чолгап алган табигатькә, мохиткә, әйләнә-тирәгә дә игътибар итә. Беренче басмага караганда, биредә табигать күренешләренә, Мостафа авылының тарихына игътибар күбрәк бирелә. Шагыйрь туган авылның пейзажын сурәтләп, тәнкыйтьче укучы алдында тулы бер картина бастыра. Казаннан Уральскига киткән Тукайның да юлы Мостафа авылы аша узуы турында мәгълүмат бирү, әдәби шәхесләрнең язмышын бәйләп карау уңышлы яңгырый. Тәнкыйтьче-галим М. Җәлилнең нәсел-шәҗәрәсенә мөрәҗәгать итеп, шагыйрьлек сәләтенең нигез-ялгыларын табарга тырышкан. Моңа дәлил итеп шагыйрьнең атасының абыйсы Хәсән язган дини парчалар, үзе шигырьләр, мөнәҗәтләр чыгарган әнисе Рәхимә түти иҗатлары китерелә. Шул ук вакытта, тәнкыйтьче М. Җәлилнең язу таланты инде кечкенәдән үк сизелүен дә ассызыклый. Мәсәлән, Мусаның беренче шигырьләре 1915 елда ук языла. Кызганычка каршы, абыйсы Ибраһим, сеңелләре Зәйнәп һәм Хәдичәләрнең истәлекләренә караганда, Мусаның беренче язганнары югала. Югалуның сәбәпләрен дә Г. Кашшаф ачыклап китә. Шунда ук автор шагыйрьнең тырышып укуына, китаплар җыярга омтылуына да укучының игътибарын юнәлтә. Шул рәвешле, Мусаны укучы күңелендә билгеле бер образ тудырырлык дәрәҗәгә күтәрә.

«Зур адымнар белән» дип аталган икенче бүлектә Г. Кашшаф М. Җәлилнең 1927 елдан алып Бөек Ватан сугышы башланган еллар-

га кадәр иҗатын һәм тормышын үреп бара. Шушы елларда шагыйрь энергиясенең һәрнәрсәгә җитүен, һәрнәрсәнең аның күңелен җәлеп итүен әйтергә тырыша. Мәгълүм булганча, М. Җәлил әлеге елларда совет оешмаларында төрле вазифалар башкара. Замандашы буларак Г. Кашшаф аның әлеге эшчәнлеген югары бәяли. Шагыйрь белән тәнкыйтьче дуслыгы да нәкъ әнә шул елларда ныгый.

Без карап үткән алдагы очеркта Җәлил белән бер сафта баручы язучы-шагыйрьләр рәтенә бу китапта тагын Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ш. Усманов, Ш. Фидаи исемнәре өстәлә. Ягъни Г. Кашшаф монографияне янәдән карап чыккан, кайбер урыннарда, өстәп, хаталарын төзәтергә тырышкан. Мисал өчен, 1918 елның көзендә М. Җәлил Төхфәт Ченәкәй белән таныша һәм бу танышу озак елларга сузылган дуслыкка әверелә. Үзенең М. Җәлилгә булган йогынтысы турында Ченәкәй түбәндәгечә яза: «Муса барлык газет-журналларны укып барды. Журналларны миңа Казаннан җибәрәләр иде, ә Оренбургта ул чакта Казанның газеталарын гына яздыралар иде. Минем үземдә Әбелмәних Каргалиның «Өммикамал» исемле шигырь китабы, «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Йосыф» китабы, «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет» бар. Гомәр Хәйям, Хафизлар иҗаты белән «Шура» журналы аша таныша идек. Мин гарәпчә яхшы белә идем һәм борынгы китапларны Мусага аңлатып бирә идем. Гали Рәхимнең «Шәрык шагыйрьләре» исемле китабы басылып чыккач, без аны бергә укып чыктык... Бу укулар Мусаның үз иҗатына тәэсире булгандыр. Ул үз шигырьләрен тикшерүне ярата, тәнкыйтьне яхшы күрә иде...»[1]. Әлеге юллар икенче очеркта гына китерелә. Г. Кашшаф, шул рәвешле, аерым факт-детальләрне еллар узгач та барлый, аларга укучының игътибарын юнәлтә.

Тәнкыйтьче үз хезмәтенә җаваплы карый. Икенче китап язучының шигырьләренә, аларга бирелгән анализларга бай. Чор, заман таләпләрен күрсәтергә тырышып, Г. Кашшаф төрле рәсми документларны да кертеп җибәрә, һәр фикерен дәлилләп бара. Шагыйрьнең 1924 – 1925 елларга кадәр иҗатына әдәбиятчылар ае-

[1] Кашшаф Г. Муса Җәлил: герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. Б. 32.

рым игътибар бирмиләр. Г. Кашшаф моның белән килешмәвен язып чыга: «Без мондый карашларны уртаклаша алмыйбыз. Тема охшашлыгы, аерым мотивларның кабатлануы, шигъри формалардан өлге алып язу – болар язучының үз башына мөстәкыйль эшли алуын шик астына куймаска тиешләр. М. Җәлилнең югарыда искә алынган әсәрләре каршылыклы булуларына, авторның эзләнүен раслауларына карамастан, алар зур шагыйрьдән хәбәр бирәләр, аларда сәнгать орлыклары бар. Шигырь төзелеше ягыннан да алар игътибарга лаеклы. Рифма, ритм, цензура, пауза, музыкальлек мәсьәләләренә яшь шагыйрь үзенә карата таләпчәнлек күрсәтә, шигырь культурасының нечкәлекләренә таба омтыла»[1]. Күрәбез, бу анализ, әдәбият белеменә караган төшенчәләр белән эш итү тәнкыйтьченең эзләнүләренең дәрәҗәсен тагын бер кат исбатлыйлар. Башка әдәбиятчыларның карашларына да Г. Кашшаф битараф кала алмаган. Әлеге тәнкыйди юлларга М. Максуд та үз мөнәсәбәтен белдерә: «Чыннан да бик сәер караш. Бу бит Муса Җәлил иҗатыннан аның 6 – 7 еллык гүзәл башлангыч чорын бер селтәнүдә сызып ташлау дигән сүз. Мондый караштa торасың икән, Шамун Фидаи һәм Ибраһим Йосфи шигырьләрен дә сызып ташларга һәм, гомумән, гражданнар сугышы чорында газеталарда басылган шигырьләргә «игътибар бирү кирәк түгел» дип расларга туры киләчәк»[2].

Г. Кашшафның хезмәтендә шагыйрьнең башлангыч чор иҗатына мондый бәя биргән тәнкыйтьчеләрнең исемнәре аталмый. М. Максуд исә үз китабында бу моментка тулырак туктала. Әмма уңай якларны барлау белән бергә, ул монографиянең җитешсезлекләрен дә билгели. Мәсәлән, М. Җәлилнең «Бибкәй кыз» музыкаль драмасына бәйле: «Бик яшьтән үк инде Муса әсәрнең идея эчтәлегенә, аның укучыга тәрбия бирү көченә игътибар итеп өйрәнгән. «Муса Җәлил» исемле әсәрендә Гази Кашшаф гаять кызыклы бер факт турында яза (99 – 100 битләр). 1925 елның 13 гыйнварында «Кызыл Татарстан» газетасында Муса Җәлилнең Казанда Татар дәүләт театры сәхнәсендә куелган

[1] Кашшаф Г. Муса Җәлил: герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. Б. 93.

[2] Максуд М. Сагынган минутларда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 106.

«Бибкәй кыз» исемле әсәрен идеология ягыннан каты тәнкыйть иткән рецензия басылып чыга. Ә 15 январьда инде Муса Җәлилнең редакциягә хаты басыла. Яшь шагыйрь мәсьәләне кабыргасы белән куя. «Бибкәй кыз» музыкаль драмасы 1922 – 1923 елларда язылган иде. Ул һәм аның кебек күп нәрсәләрем надан хәлемдә, эшләнмәгән талантка таянып язылдылар да, шунда ук югалдылар да», – ди Муса.

Мусаның дәһшәтле кисәтүенә карамастан, «Бибкәй кыз» пьесасы соңыннан да Уфада, Ташкентта күп тапкырлар куелган һәм уңышлы барган...

«Бибкәй кыз»ның бердәнбер текстын Латыйповлар Кашшафка биргәннәр. ... «Бибкәй кыз» хәзерге көн өчен һич тә актуаль түгелдер, аны сәхнәгә кую турында хыяллану урынсыздыр. Шулай булса да, әсәрне эзләп тапкан Кашшаф аның турында үз фикерен әйтеп китәргә тиеш иде»[1]. Ягъни биредә М. Максуд тәнкыйтьчене фактлар, күренешләр белән эш иткәндә билгеле бер дәрәҗәдә сак, игътибарлы булырга өнди.

Монографиянең шактый өлешен (китапның яртысын диярлек) өченче бүлек тәшкил итә. Бу аңлашыла да, чөнки М. Җәлилнең исемен аклау юлында Г. Кашшаф бик зур тырышлык куя. Халыкка дөреслекне раслау исә – җиңел эшләрдән түгел. Шуңа да автор мөмкин кадәр тулы, һәр детальне ассызыклап, күзәтеп бара. Ягъни бу монографиясе белән дә тәнкыйтьче үзенең дуслыгына тугры булып кала.

1961 елда басылган хезмәттә фотографияләр күбрәк бирелә, истәлекләр, хатлар да шактый. Бирегә шулай ук Г. Кашшаф шагыйрь васыятенең фотокүчермәсен дә керткән. Җәлил белән әсирлек тормышын татып, аның кебек җәзалап үтерелгән иптәшләренең шәхесләренә мөрәҗәгать итә тәнкыйтьче. Ләкин ул тиз генә ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ашыкмый, төгәллеккә омтыла, һәр ясалган нәтиҗәсен документлар белән расларга тырыша. Г. Халит Г. Кашшафның монографиясенә карата: «әдәби метод һәм стильләр формалашу яктылыгында тикшерү нияте аеруча

[1] Максуд М. Сагынган минутларда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 117.

сизелә», – дип язып чыга[1]. Әмма хезмәтне чор идеологиясе кысаларында язылган хезмәт дип бәяләү дөрес түгел.

Г. Кашшаф М. Җәлилгә багышланган хезмәтен очерк дип билгели. Чыннан да, документальлек һәм сәнгати эшләнешенә карaганда, китап шулай да аталырга мөмкин. Әмма герой-шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын беренче тапкыр фәнни әйләнешкә керткән бу очеркны тулы хокуклы монография дип санарга кирәк. Жанр буларак нәкъ менә монография аерым бер күренекле кешенең тормыш юлын һәм эшчәнлеген яктыртуга багышланган күләмле фәнни хезмәт (гадәттә, басма китап) булып тора[2]. Г. Кашшаф исә, М. Җәлилнең тәрҗемәи хәлен һәм иҗатын барлаган галим, биограф, текстолог. Соңгы елларда әдәбият галимнәре биографияне язганда мөмкин кадәр тормыш фактларына мөрәҗәгать итәргә, мохитне тулаем сурәтләргә кирәк дигән карашта торалар. Әлеге юл белән әдипнең тормыш юлы гына түгел, ә бәлки шәхси үзенчәлекләрен дә күрсәтергә мөмкинчелек туа[3]. «...Шәхес изоляциядә үсеш ала алмый. Яхшы биограф, билгеле бер дәрәҗәдә рәссам булып, бер яктан, үз героеның образын ачып бирү өчен, предметлар һәм атрибутлар белән чолгап алынган «репрезентатив портрет» алымын куллана белергә тиеш»[4]. Ягъни, нәтиҗә чыгарып әйткәндә, бүгенге көн әдәбият галимнәре тарафыннан биографик монографияне язу өчен билгеләнгән таләпләрне Г. Кашшафның хезмәтендә тулаем таба алабыз. Шулай итеп тәнкыйтьче-галимнең үз чоры һәм хәзерге буын укучысы өчен дә әһәмиятле эш башкарып чыгуы турында тагын бер дәлил туа.

Үз вакытында китапның кайсы жанрда язылуы хакында тәнкыйди фикерен Р. Бикмөхәмәтов та җиткергән: «Бездә фәнни био-

---

[1] Халитов Г. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. Б. 328.

[2] Әдәбият белеме сүзлеге [Төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. Б. 106.

[3] Петровская И.Ф. Еще раз об источниках биографических сведений о русских писателях и их окружении / И.Ф. Петровская // Рус. лит. Л., 1984. № 2. С. 192.

[4] Холиков А.А. Писательская биография: жанр без правил // Вопросы литературы. 2008. № 6. С. 54.

графия жанры йомшак эшләнгән. Бу факт әлеге хезмәттә дә, аның жанрының төгәлсезлегендә дә ачык чагыла. Безнең алда әле биография, әле истәлек-хатирәләр, әле шигырь төзелеше тарихына экскурс пәйда була»[1]. Билгеле, төрле жанрдагы материалны берләштерү (документлар, хатлар, истәлекләр, шигъри әсәрләр һ.б.) җиңел эш түгел. Шулай ук шагыйрь иҗатын бары тик академик стиль-тел аша күзаллау да дөрес түгелдер, чөнки Г. Кашшаф беренче чиратта М. Җәлилнең шәхесен ачарга омтыла. Шуңа да китапның жанрын, безнеңчә, киң планда карау урынлы булыр.

Г.Кашшафның Муса Җәлил турындагы беренче хезмәте кебек үк, 1961 елда басылып чыккан монографиясе дә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителә. «Социалистик Татарстан», «Совет әдәбияты», «Вопросы литературы» басмаларында аңа карата берничә рецензия басыла. Китап басылган елны ук Салих Хәкимнең кыска язмасы дөнья күрә. Биредә төп игътибар шагыйрьнең батырлыгына юнәлтелә, шулай ук китапның образлы телдә язылуы, җиңел укылуы хакында да әйтелә. Ягъни тәнкыйтьченең үзенең дә язучы-художник булуы танылa[2].

1962 елда китапка карата ике рецензия басылып чыга. Шуларның берсен Мәскәү университеты аспиранты Ю. Әминов язган[3]. Монографиянең гомуми кыйммәтен билгеләгән хәлдә, тәнкыйтьче, кайбер кимчелекле якларны да барлый. Мисал өчен, хезмәт авторының кайбер өлешләрдә әдәби мохитне артык мавыгып сурәтләве, шуңа бәйле рәвештә Муса Җәлил иҗатының икенче планга күчүе; Җәлил иҗатына хас эзлеклелекне, бөтенлекне тулаем күрсәтмәве; «Зәйнәп» поэмасын гел уңай яктан бәяләве; М. Җәлилнең драма әсәрләре анализдан читтә калуы; журналист һәм тәнкыйтьче буларак эшчәнлеге аз өйрәнелүе һ.б. Ю. Әминов: «Муса Җәлил» монографиясе герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүдә тагын бер кыйммәтле хезмәт ул. Бу китаптан укучылар үзләрен кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап таба алалар.

[1] Бикмухаметов Р. Биограф поэта // Вопросы литературы. 1962. № 5. С. 236.

[2] Хәким С. Герой шагыйрь турында китап // Социалистик Татарстан. 1961. 19 сентябрь.

[3] Әминов Ю. Заман белән бергә // Совет әдәбияты. 1962. № 1. Б. 136–142.

Ләкин биредә Җәлил турында әйтеләсе инде әйтелеп беткән, әдәбият белгечләребезгә тынычлап, кул кушырып утырасы гына калган дигән фикерне аңларга ярамый. Бу өлкәдә чишеләсе, хәл ителәсе мәсьәләләр җитәрлек», – дип белдерә[1]. Димәк, Г. Кашшаф үзенең хезмәте белән үк аудитория алдында киләчәктә хәл ителәсе сорауларны да күтәрә алган, алга таба эзләнүчеләргә юл күрсәткән, дигән нәтиҗә чыгара алабыз.

Китапка өченче рецензияне Р. Бикмөхәмәтов язып чыга. Ул: «Г. Кашшаф хезмәтенең төп кыйммәте – яңа кызыклы материалга бай булуы, шагыйрьнең биографиясе һәм иҗаты органик бәйләнештә бирелүендә. Китапның бүгенге көнгә чаклы рус теленә тәрҗемә ителмәве шаккатыра: ул шагыйрьнең героик шигырьләренә, аларның төгәл комментарийларына алыштыргысыз кушымта булып тора», – дигән фикерне җиткерә[2]. Шуның белән бергә, тәнкыйтьче аерым җитешсезлекләрне дә санап чыга. Әйтик, Г. Кашшафның шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнгән башка галимнәргә мөрәҗәгать итмәве; аерым хатларга сылтамалар күрсәтмәве. Әмма, шуларга да карамастан, Р. Бикмөхәмәтов тәнкыйтьче-коллегасының хезмәтен зур казаныш дип саный.

Әлбәттә, ике монографияга карата да тәнкыйтьче һәм галимнәрнең бәяләмәләрендә хаклык бар. Бу – уңай һәм кимчелекле якларны барлауга да карый. Әмма хезмәтнең укылуы, алга таба аның нигезендә бик күп яңа эзләнүләрнең барлыкка килүе үк Г. Кашшаф башкарып чыккан эшнең күләмен һәм дәрәҗәсен күрсәтеп тора.

1960 елда Г. Кашшаф тарафыннан якланган кандидатлык диссертациясенең бер өлешен нәкъ менә Җәлилгә багышланган бүлек алып тора. Тәнкыйтче, заман әдәбият белеменә таянып, шагыйрьнең иҗатын татар совет әдәбиятының гомуми үсеше яссылыгында күзәтеп чыга. Шул рәвешле, монография тулы хокуклы фәнни хезмәт буларак карала да.

Тәнкыйтьче-галимнең М. Җәлил турындагы хезмәтләренең ике үзенчәлеге хакында Ф. Әгъзамов язып чыга: 1) «конкрет ми-

---

[1] Әминов Ю. Заман белән бергә // Совет әдәбияты. 1962. № 1. Б. 142.

[2] Бикмухаметов Р. Биограф поэта // Вопросы литературы. 1962. № 5. С. 236.

салларын анализлау юлы белән шагыйрьнең поэтик һәм гражданлык батырлыгының закончалыклы булуы турындагы идеяне раслый: ул бу батырлыкка бөтен тормышы, безнең чынбарлыгыбыз, тәрбия һәм үзтәрбия тарафыннан әзерләнде»; 2) «ул шагыйрь һәм гражданны формалаштырган мәдәният мохитын яхшы белә. Бу – халык авыз иҗаты, татар классик әдәбияты, көнчыгыш поэзиясе, бөек рус мәдәнияте, көнбатыш әдәбияты һәм тере тирәлеге – Ш. Камал, Һ. Такташ, К. Нәҗми, Ф. Бурнаш, А. Фадеев, П. Тычина, Я. Уксай һәм башка бик күпләр»[1].

«Муса Җәлил» хезмәтеннән тыш, Г. Кашшаф герой-шагыйрь исеме белән бәйле истәлекләрне дә туплый. Алар аерым китап булып басылып чыгалар. Истәлекләр дә әлеге монографиянең бер нәтиҗәсе. Г. Кашшаф төп хезмәтен язганда, Муса Җәлил белән таныш булган, бергә эшләгән, көрәшкән кешеләрнең язмаларын, сөйләп биргән истәлекләрен файдаланган. Боларга Г. Кашшафның М. Җәлил томлыкларына язылган кереш, йомгак сүзләрен, төрле газета-журналларда басылган мәкаләләрен, башка авторлар белән бергәлектә язылган хезмәтләрен дә өстәсәк – тәнкыйтьченең чын мәгънәсендә зур эш башкарганын сиземләве кыен түгел.

«Муса Җәлил» монографиясе – Г. Кашшафның төп китабы. Шагыйрьнең чын дусты гына әлеге йөкне үз өстенә алып, башкарып чыга ала. Автор исә аны намусы, вөҗданы кушканча үтәп чыга. Билгеле, аның хезмәтләренә күп кенә фактларны өстәп булыр иде. Әмма алар Г. Кашшаф хезмәте булмас иде инде. Монография болай да Җәлил фәне өлкәсендә чыганак була ала, барлык эзләнүләргә этәргеч ролен дә үтәп килә. Китап фактик материалга гаять бай, Җәлил тарихын өйрәнү, аның намуслы исемен торгызу, әсәрләрен җәмәгатьчелеккә җиткерү буенча бай мәгълүмат бирә, фәнни әйләнешкә беренче мәртәбә күп кенә әһәмиятле яңа фактлар кертә. Г. Кашшаф Җәлил фәненә нигез салучы тәнкыйтьче-галим

[1]Агзамов Ф.И. Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / сост. и ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 40–42.

буларак татар әдәбияты тарихында, гомумән, татар мәдәниятендә мөһим роль башкарган.

Исеме туган иленә әле генә кайтарылган шагыйрьнең иҗаты һәм язмышы югары пафоста сурәтләнә. Тәнкыйтьче өчен исем аклау факты аеруча мөһим. Г. Әпсәләмов тәнкыйтьченең М. Җәлилгә багышланган эшчәнлеген «бүгенге тәнкыйтьнең уңышлы адымы», дип карау белән беррәттән, Г. Кашшаф эшчәнлегенең әдәби тәнкыйтькә бәйле кимчелекле бер ягын күрсәтә: «Күп кенә тәнкыйтьчеләр, язучыларның теге яки бу әсәрен тикшергәндә, хаклы рәвештә, аларны тел кытыршылыклары өчен тиргиләр. Ләкин үзләренең аннан да кытыршырак зәгыйфь тел белән язуларын күрмиләр. Г. Халит, Г. Кашшаф, Х. Хәйри иптәшләрнең кайбер мәкаләләрен бик зур түземлелек белән генә укып чыгарга мөмкин. Аннары безнең тәнкыйтьчеләрнең аерата озын язу белән мавыгуларын да әйтергә кирәк. Мәсәлән, Г. Кашшафның М. Җәлил турындагы эчтәлекле мәкаләсе, «суы» күп булу аркасында, бик нык оттыра. Картлардан күреп яшь тәнкыйтьчеләр дә колачны киң җәергә тырышалар»[1]. Дөрестән дә, күп кенә язмаларында Г. Кашшаф темалардан читләшә, артык «сүз куерту» белән мавыга. Әмма бүгенге көндә ул чордагы хезмәтләрдә урын алган һәр сүз тулаем бер дәвер мохитен тоеп аңлар өчен зур кыйммәткә ия.

Җәлилне өйрәнү фәненең бүгенге торышы турында сүз йөрткәндә, түбәндәгеләрне билгели алабыз: герой-шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын, батырлыгын яктыркан 11 кандидатлык диссертациясе яклангaн, шуларның 7се әдәбият өлкәсенә карый:

1. Р.Г. Бикмухаметов «Творческий путь Мусы Джалиля» (1955);
2. Н.Г. Юзеев «Поэмы Мусы Джалиля» (1958);
3. М.С. Кашафутдинов «Основные этапы развития татарской советской литературы и творчество Мусы Джалиля» (1960);
4. В.Г. Воздвиженский «Моабитские тетради» и их место в советской литературе военных лет» (1968);

[1] Әпсәләмов Г. Сугышчан тәнкыйть өчен // Совет әдәбияты. 1954. № 6. Б. 87.

5. И.Х. Забиров «Муса Джалиль и моабитская группа татарских писателей» (1971);

6. Р.А. Мустафин «Моабитский период жизни и творчества Мусы Джалиля в свете новых материалов и изысканий последних лет» (1971);

7. А.Г. Махмудов «Идейно-эстетическое своеобразие творчества Мусы Джалиля: к вопросу об эстетическом идеале» (1980).

Ике хезмәт – татар телендә, берсе басылган язмалар нигезендә башкарылган. Диссертацияләрнең төп өлеше узган гасырның 80 нче елларына кадәр якланган, һәм, шулай ук, шагыйрь турындагы фәнни-популяр әдәби-тәнкыйди һәм публицистик язмаларның да күпчелеге шул чорга туры килә. Бүгенге көндә фәнни җәмәгатьчелек аерым авторларның эзләнүләре, юбилей уңаеннан үткәрелә торган чаралар, Җәлил укулары белән канәгатьләнә дигән сүз.

Алда күрсәтелеп үткән диссертацияләрне барлау шуны күрсәтә: шагыйрь иҗатын өйрәнү билгеле бер дәвамчанлык һәм хезмәттәшлек юлы белән алып барылган. Мисал өчен, Н.Г. Юзиев диссертациясенең рәсми оппоненты – Р.Г. Бикмөхәмәтов, И.Х. Зәбировның фәнни җитәкчесе – Г. Кашшаф, Ә.Г. Мәхмүдев фәнни эшенең оппоненты – Р.А. Мостафин. Р. Мостафинга исә Җәлил фәненә хәерфатихасын шулай ук Г. Кашшаф бирә. Аларның берничә хезмәте бергә башкарыла. Шул рәвешле, хәзерге әдәбиятта Г. Кашшаф эшен нәкъ менә шушы тикшеренүче алып барды.

Билгеле, вакыт узган саен һәрбер тикшеренү өлкәсе дә яңа мәгълүматлар белән баетыла, заман фәне таләпләреннән чыгып үсеш ала. Җәлил фәне дә бүген үз тикшеренүчеләрен көтә, чөнки бу өлкәдә тупланган бай материалны күзаллау өчен бер генә докторлык хезмәте аз. Ләкин бу өлкә тарихы белән кызыксына башлаган яисә эзләнергә теләүче һәрбер галим Җәлилне өйрәнү фәненә нигез ташларын салган Г. Кашшаф хезмәтләрен уратып узмаячак.

# ЙОМГАК

Татар әдәбиятында совет чоры дип исемләнгән елларны өйрәнү һәм аны хәзерге әдәбият белеме казанышларына таянып бәяләү дәвам итә. 70 елны үз эченә сыйдырган бу дәвергә билгеле бер катгый нәтиҗә чыгарып булмый. Аның һәр унъеллыгы үзенчәлекле. Гомуми планда чорны аңлау, дөрес фикер йөртү өчен күп кенә мәсьәләләрне чишәргә кирәк. Шуларның берсе – шул елларда иҗат иткән әдипләрнең, тәнкыйтьчеләрнең эшчәнлеген тикшерү, мирасларын бәяләү. Монографиядә тикшерелгән тәнкыйтьче-галим Г. Кашшаф эшчәнлеге совет чорында да, хәзерге көндә дә татар әдәбияты тарихында мөһим урын алып тора.

Хезмәтнең беренче бүлеге турыдан-туры Г. Кашшафның тормыш юлын һәм күпкырлы эшчәнлеген игътибарга алса, калганнары тәнкыйтьченең язма мирасына юнәлтелгән иде. Әдипнең биографиясен һәм эшчәнлеген аерым бүлек итеп алуыбыз акланды. Г. Кашшафның чын мәгънәсендә тәнкыйтьче, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе булып китүе тормыш вакыйгаларына да бәйләп карала. Ул бик иртә әдәбият белән кызыксына башлый, шагыйрьләр, язучылар белән аралаша. Совет чоры дип исемләнгән әдәбият тарихында төрле өлкәләрдә башкарган эшчәнлеге белән Г. Кашшаф башка тәнкыйтьче-галимнәрдән аерылып тора. Ул актив җәмәгать эшлеклесе, шул ук вакытта тәнкыйтьче, редактор, педагог, галим хезмәтләрен үреп бара, Язучылар союзында эшли. Үз чиратында бөек шәхесләребезнең аңа йогынтысы да булмый калмагандыр. Алар да тәнкыйтьченең тормыш юлына билгеле бер дәрәҗәдә тәэсир иткән.

Хезмәтнең калган бүлекләре тәнкыйтьченең әдәби-тәнкыйди мирасын мөмкин кадәр тулы ачып бирә. Аларны йомгаклап, түбәндәге төп нәтиҗәләрне чыгарырга мөмкин:

1. Г. Кашшафның иҗтимагый-сәяси, әхлакый-эстетик, гуманистик карашлары аеруча аның әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми язмаларында чагыла. Аларда ул татар әдәби тәнкыйтенең классик традицияләрен дәвам итүче буларак чыгыш ясый. Г. Кашшаф язучыларның тәрҗемәи хәлләренә, төп биографик фактларга, иҗатларының үсеш этапларына игътибарын юнәлтә. Аның

рецензияләрендә, мәкаләләрендә, әдәби портретларында, аннотацияләрендә, кереш сүзләрендә һ.б. язмаларында күпчелек татар совет әдипләренең иҗаты өйрәнү объекты итеп алына. Г. Кашшаф төрле жанрлар белән эш итә (рецензия, аннотация, күзәтү мәкаләсе, иҗат портреты һ.б.), әдәбиятның һәр төре аңа яхшы таныш. Мәкалә-язмалардан күренгәнчә, Г. Кашшаф әсәрләрне, иң беренче чиратта, укучының кабул итү-итмәвеннән, чынбарлыкны ни дәрәҗәдә дөрес чагылдыруыннан торып бәяли. Гуманистик аспектка, әсәрдәге кеше образларының бирелешенә ул аеруча басым ясый. Аңа иҗат җимешенең сәнгати, тел-стиль ягы да мөһим. Тәнкыйтьче татар совет классикларының иҗатларына мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта татар әдәбиятының гомуми барышын да күзәтә. Күп кенә язучы-шагыйрьләрне Г. Кашшаф әдәбият мәйданына чыгара, аларга хәер-фатихасын бирә. Чор шаукымына ияреп, ул вульгар социологизм идеологиясенә дә бирелеп ала, заманында актуаль яңгыраган «конфликтсызлык» теориясенә, уңай герой мәсьәләсенә, «кечкенә кеше» проблемаларына да кагыла. Әдипнең тәнкыйть өлкәсендәге мирасы бай, төрле тармакларны яктыртуы белән үзенчәлекле. Биредә язучының иҗатын, аерым бер әсәрдән башлап, әдәбиятның гомуми торышын анализлауга караган мәкалә-хезмәтләрен атап дәвам итә алабыз. Мәкаләләренең күптөрле газета һәм журнал битләрендә басылып чыгуы мәгълүм. Ягъни әдип киң катлам укучыларга үз карашларын җиткерергә тырышкан, димәк моңа ихтыяҗ булган. Бер үк вакытта, Г. Кашшаф төрле чыгышлар да ясаган, җыентыкларга кереш сүзләр язган. Әлеге эшчәнлеге аны тәнкыйть дөньясының күренекле вәкиле булып күтәрелүенә китергән. Үз чорында аның хезмәтләре, эшчәнлеге иҗатташлары, чордашлары тарафыннан уңай бәяләнә. Билгеле, Г. Кашшаф әдәбият теориясенең аерым мәсьәләләренә киң тукталмый. Ул гомуми планда эш итә, әхлакый-эстетик юнәлештә иҗат итәргә омтыла. Совет чорында шушы хезмәтләре өчен ул еш кына тәнкыйть сүзләре дә ишетә. Әмма Г. Кашшафның күп кенә язмалары бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмый. Г. Кашшаф исә, күпсанлы язучы-шагыйрьләрнең иҗатын өйрәнеп, тикшереп чыгу ягыннан караганда, тәнкыйтьче-галим, биограф, текстолог буларак танылган шәхес.

2. Г. Кашшафның Муса Җәлилне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлегенә килгәндә, берничә моментны аеруча ассызыклап үтәсе килә. М. Җәлил – каһарман, батыр, тиңсез шагыйрь. Шагыйрьнең дусты Г. Кашшаф та, үз чиратында, үз эшендә каһарман, максатчанлыгы, васыятькә тугры калуы белән батыр характерлы, тырыш зат. Әлеге ике шәхесне яшәгән чорлары, дуслыкларыннан тыш та үзара бәйләп торучы нигезләр аз түгел. Г. Кашшаф, кайчандыр М. Җәлил яшәгән фатирда гомер кичерә. Шул рәвешле, шагыйрьнең рухын саклаган диварлар Г. Кашшафны илһамландыра, каләменә көч өсти, башкалар иҗатына юнәлеш бирергә этәрә. Әлеге дәвамлы хәрәкәт бүген дә туктамый. Җәлил фәненә нигез салган тәнкыйтьченең эше, мирасы бүген дә актуаль.

Вакытлар узган саен, фидакарьлек белән башкарылган эшчәнлекнең бәясе, кадере күтәрелә генә бара. Аны әледән-әле хәтерләрдә яңартып, тузаннан саклап торачаклар. Шагыйрьнең үлмәс исеме яшәгәндә, аны халыкка кайтарган Г. Кашшаф исеме дә онытылмас. Аның эшчәнлегенә таянып, әле күп кенә фикерләр әйтелергә мөмкин.

Г. Кашшаф М. Җәлилнең героик характерын, фашистларга каршы алып барган яшерен көрәшен яктырта. Әлеге көрәшнең гаять киң колач җәюен мисаллар белән раслый. Шагыйрьнең көрәш юлында кичергән газаплары да тәнкыйтьче күңеленә тирән эз булып уелган. Шуңадыр, китапта шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлының соңгы чорына шактый киң урын бирелгән. Бу күренеш, әлбәттә, М. Җәлилнең соңгы көннәрен укучыга мөмкин кадәр тулы, дөрес итеп хикәяләп бирү максатыннан башкарылгандыр.

Г. Кашшафның М. Җәлилне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге нәтиҗәсендә, татар совет әдәбияты гына түгел, ә гомумән, дөнья әдәбияты герой-шагыйрьнең исемен, каһарманлыгын, үлемсез шигырьләрен үз тарихы битләренә кертә. Татар әдәбияты тарихында хаклы рәвештә Г. Кашшаф Җәлил фәненә нигез салучы буларак танылa. Шулай ук аны әлеге өлкәдә фундаменталь материал туплаган галим дип тә танырга кирәк.

3. Г. Кашшафның әсәрләре берничә хикәя, повесть белән чикләнсә дә, тәнкыйтьченең публицистик стиле бу иҗат

җимешләрендә үзен сиздереп тора. Әдәбият белгечләре тарафыннан алар югары бәяләнмәсә дә, әдипнең чынбарлыктагы вакыйгаларны сурәтли белүе, аларны укучысына кызыклы итеп җиткерә алуы күзгә ташлана. Димәк, Г. Кашшаф үз заманында укучысының ихтыяҗын тоеп яшәгән. Нигездә, илебез кичергән иң авыр сугыш һәм сугыштан соңгы елларда язылган бу әсәрләр чорның актуаль темаларын күтәрәләр. Шул ук вакытта, хикәяләр арасында тормыш ваклыкларын яктырткannнары да бар. Алар көлкеле ситуацияләргә корылган, кешеләрнең мәгънәсез эшләрен тасвирлый. Тәнкыйтьченең барлык әсәрләрендә дә бер үзенчәлек күзгә ташлана: хикәяләрнең һәркайсы диярлек укучы алдында сорау куя, аны уйланырга мәҗбүр итә. Автор бу очракта һәр кешегә үзенчә нәтиҗәләр чыгарырга ирек бирә. Очерк, эссе жанрына мөрәҗәгать итеп, Г. Кашшаф татар журналистика тарихында да үз сүзен әйтә. Документаль фактларга нигезләнгән очерклар аша совет чынбарлыгы сурәтләре укучы күз алдына тагын да калкурак килеп баса.

Г. Кашшафның язучылык эшчәнлеге, нигездә, заман таләпләреннән, чор ихтыяҗыннан туса да, аерым әсәрләренең тема һәм проблемалары бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый.

4. Театр тәнкыйте Г. Кашшаф эшчәнлегендә аерым урын алып тора. Әлеге рецензияләрдә драматургия әсәрләре генә түгел, ә гомумән татар театры тарихы да чагыла. Шунысы мөһим: Г. Кашшафның бу юнәлештәге эшчәнлеге аны тәнкыйтьче-галим, татар театрының тарихын, үсешен күзәтеп барган тамашачы буларак кына түгел, ә бәлки сәнгатькәр, театр тәнкыйтьчесе, татар театры тарихчысы буларак таныырга мөмкинлек бирә. Тәнкыйтьченең күпсанлы мәкалә-рецензияләре тулы бер әдәби анализ бирүне күздә тотып язылмаган. Аның хезмәтләре безгә фактологик материал туплау, татар әдәбияты тарихы, татар театры тарихы өчен бай материал бирү ягыннан мөһим.

5. Г. Кашшафның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеген түбәндәге чорларга бүлергә мөмкин:

а) 1920 еллар ахыры – 1930 еллар уртасы − стиль, юнәлеш өлкәсендә эзләнүләр;

ә) 1930 еллар уртасы − Бөек Ватан сугышы башланганчы − җитлегү чоры;

б) Бөек Ватан сугышы еллары − 1953 елга кадәр − төрле өлкәләргә караган актив эшчәнлек;

в) 1953 елдан алып 1975 елга чаклы − төп игътибарны М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына юнәлтү һәм аны өйрәнү.

Г. Кашшафның озак еллар буе көндәлек алып баруы күпләргә мәгълүм түгел. Алар − әдәбият өчен хәзинә. Шулай ук Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Г. Кашшафның фонды да бар. Әлеге материаллар әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән. Димәк, Г. Кашшафның эшчәнлегенә һәм мирасына карата җиткереләсе күп кенә фикерләр бар әле. Сүз – мәгънәсе белән көчле, һәм әдәбиятта да матурлык бөртек-бөртек сүзләрдән туа. Г. Кашшафның да төп эшчәнлеге бүген безгә сүзләр аша җиткерелә. Тәнкыйтьче һәрбер сүзгә игътибарлы булырга өнди. Аның танылган әдипләрне өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлегенә килгәндә дә шушы ук күренешнең кабатлануын күзәтәбез. Нәтиҗә чыгарып әйткәндә, Г. Кашшаф үзенең әдәби-тәнкыйди һәм гыйльми эшчәнлеге белән татар әдәбияты тарихында гына түгел, бәлки сәнгатендә дә үзенә аерым урын алырга лаеклы шәхес.

С. Кудаш язганча: «Г. Кашшаф татар совет әдәбиятының сабан туйларында яки ипподромнарда елына бер тапкыр чаба һәм юырта торган аргамакларыннан түгел. Ул татар совет әдәбиятының ел әйләнәсенә муеныннан камыт төшерми торган йөк аты булды. Аны нинди зурлыктагы арбага җиксәләр һәм аңа күпме йөк салсалар, ул шуны тарта һәм алга таба сөйри бирде»[1]. Һәм бу чыннан да шулай. Г. Кашшафның хезмәтләре зур кыйммәткә ия. Тәнкыйтьче үз эшчәнлегенең кешеләргә карата мәхәббәт, ышаныч белән башкарылуын белдереп, болай ди: «Мин кешеләрне үзем уйлаганга караганда яхшырактыр дигән фикер белән яшәдем»[2]. Әлеге юлларга тәнкыйтьченең яшәү мәгънәсе салынган.

---

[1] Юзиев Н. Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 132 .

[2] Әгъзәмов Ф. Тугрылык // Мәдәни җомга. 1997. 25 апрель.

# БИБЛИОГРАФИЯ

## I. Чыганаклар


1. Кәшаф Гази. Татарда поэма һәм аның үсү баскычлары // Авыл яшьләре. 1928. № 31. Б. 51.

2. Кашшаф Г. Яшь язучылар тирәсендә // Авыл яшьләре. 1929. № 2. Б. 15.

3. Кашшаф Г. Таш урамнар җыры // Кызыл Татарстан. 1929. 17 ноябрь.

4. Кашшаф Г. «Джавап» // Красная Татария. 1929. 14 декабрь.

5. Кашшаф Г. Безнең юл // Кызыл Татарстан. 1930. 11 февраль.

6. Кашшаф Г. Без ничек эшлибез // Совет әдәбияты. 1933. № 8–9. Б. 82–83.

7. Кашшаф Г. Ибрай Газый иҗаты // Совет әдәбияты. 1933. № 10. Б. 49–55.

8. Кашшаф Г. «Роберт». Балалар өчен поэма // Кызыл Татарстан. 1933. 22 декабрь.

9. Кашшаф Г. Әдәби әсәрләрнең сыйфаты өчен // Кызыл Татарстан. 1934. 14 июнь.

10. Кашшаф Г. Охранник. Хикәя // Совет әдәбияты. 1934. № 6. Б. 28–43.

11. Кашшаф Г. М. Максуд әсәрләре // Совет әдәбияты. 1935. № 2. Б. 90–91.

12. Кашшаф Г. Ил чигендә. Хикәя. Башы // Совет әдәбияты. 1935. № 4–5. Б. 25–44.

13. Кашшаф Г. Ил чигендә. Хикәя. Дәвамы // Совет әдәбияты. 1935. № 6. Б. 54–61.

14. Кашшаф Г. Ил чигендә. Хикәя. Ахыры // Совет әдәбияты. 1935. № 7. Б. 7–19.

15. Кашшаф Г. Гаепсездән гаеплеләр // Кызыл Татарстан. 1936. 12 февраль.

16. Кашшаф Г. «Шатлык җыры» // Кызыл Татарстан. 1936. 10 апрель.

17. Кашшаф Г. Кави Нәҗминең ике повесте турында // Совет әдәбияты. 1936. № 6. Б. 82–91.

18. Кашшаф Г. «Капитан кызы» // Совет әдәбияты. 1937. № 1. Б. 83–88.

19. Кашшаф Г. Тукай һәм аның чоры // Яшь Сталинчы. 1938. 15 апрель.

20. Кашшаф Г., Хәйри Х. Тукай әсәрләренең бер томлыгы турында // Совет мәктәбе. 1938. № 3/4. Б. 60–63.

21. Кашшаф Г., Маннур Ш. Бишбүләк // Кызыл Татарстан. 1938. 15 май.

22. Кашшаф Г., Хөсни Ф., Исхак Ә. Карлыгач // Кызыл Татарстан. 1938. 21 май.

23. Кашшаф Г., Исхак Ә. Өйләнү // Кызыл Татарстан. 1938. 23 май.

24. Кашшаф Г., Җәмил Х. Ташкыннар // Кызыл Татарстан. 1938. 29 май.

25. Кашшаф Г., Хөсни Ф. Корыч ничек чыныкты // Кызыл Татарстан. 1938. 3 июнь.

26. Кашшаф Г. Г. Камал әсәрләрендәге кайбер типлар // Совет әдәбияты. 1938. № 6. Б. 62–70.

27. Кашшаф Г. Башкорт Дәүләт Академия театрының гастрольләре // Совет әдәбияты. 1938. № 7. Б. 96–105.

28. Кашшаф Г. Сибгат Хәким шигырьләре турында // Кызыл Татарстан. 1938. 8 сентябрь.

29. Кашшаф Г. Намус // Кызыл Татарстан. 1938. 21 ноябрь.

30. Кашшаф Г. Һади Такташ // Кызыл Татарстан. 1938. 8 декабрь.

31. Кашшаф Г. Урманда // Кызыл Татарстан. 1938. 30 декабрь.

32. Кашшаф Г. Башлап язучылар иҗатына карата // Азат хатын. 1938. № 18. Б. 8–10.

33. Кашшаф Г., Вахитов И. Галиәсгар Камал // Кызыл Татарстан. 1939. 6 январь.

34. Кашшаф Г., Вахитов И. Татарның бөек драматургы // Совет әдәбияты. 1939. № 1. Б. 42–58.

35. Кашшаф Г. Яшьләрнең хикәяләре турында // Азат хатын. 1939. № 1. Б. 14 – 15.

36. Кашшаф Г. Бүреләр һәм сарыклар // Кызыл Татарстан. 1939. 9 февраль.

37. Кашшаф Г., Камал Ә. Матур туганда // Кызыл Татарстан. 1939. 13 март.

38. Кашшаф Г. Татар совет драматургиясенең тантанасы // Кызыл Татарстан. 1939. 6 апрель.

39. Кашшаф Г. Театр сезоны ябылу уңае белән // Кызыл Татарстан. 1939. 15 май.

40. Кашшаф Г. Гасырлар аша ишетелгән халык авазы // Кызыл Татарстан. 1939. 12 сентябрь.

41. Кашшаф Г. Мөхәммәт Гали (Әдәби иҗатына 25 ел тулу уңае белән) // Кызыл Татарстан. 1939. 29 ноябрь.

42. Кашшаф Г. Мөхәммәт Гали // Совет әдәбияты. 1939. № 12. Б. 86–100.

43. Кашшаф Г. Үсү юлы // Совет әдәбияты. 1939. № 7. Б. 76–92.

44. Кашшаф Г. Һади Такташ //Азат хатын. 1939. № 23. Б. 10–11.

45. Камал Г. Первый театр. Предисловие Г. Кашшафа. Казань: Татгосиздат, 1939. С. 5 – 8.

46. Кашшаф Г. Туй күңелле булсын (хикәя) // Кызыл Татарстан. 1940. 1 январь.

47. Кашшаф Г. Каләм мастерлары. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 120.

48. Кашшаф Г. Шәриф Камал // Совет әдәбияты. 1940. № 1/2. Б. 30–44, 46.

49. Кашшаф Г. Образлар мастеры // Кызыл Татарстан. 1940. 29 март.

50. Кашшаф Г. Чүл буенда. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 115.

51. Кашшаф Г. М. Максуд иҗат кичәсе // Совет әдәбияты. 1940. № 4. Б. 103.

52. Кашшаф Г. Шәриф Камал. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 141.

53. Кашшаф Г. Ана шатлыгы // Ленин-Сталин турында. Казан: Татгосиздат, 1940. Б. 254.

54. Кашшаф Г. Галиябану // Кызыл Татарстан. 1940. 22 август.

55. Кашшаф Г. «Гөлчәчәк» комедиясе турында // Кызыл Татарстан. 1940. 17 декабрь.

56. Кашшаф Г. Ленин-Сталин турында // Совет әдәбияты. 1941. № 1. Б. 88–91.

57. Кашшаф Г. Творческий успех поэта Мусы Джалиля // Красная Татария. 1941. 4 марта.

58. Кашшаф Г. Новый декадный спектакль // Красная Татария. 1941. 30 апреля.

59. Кашшаф Г. Канга – кан, җанга – җан // Кызыл Татарстан. 1941. 25 октябрь.

60. Кашшаф Г. Наемщик // Кызыл Татарстан. 1941. 22 ноябрь.

61. Кашшаф Г. Киң күңелле патриот // Кызыл Татарстан. 1941. 9 декабрь.

62. Кашшаф Г. Ул безнең белән // Совет әдәбияты. 1941. № 12. Б. 58–61.

63. Кашшаф Г. Күңелле спектакль // Совет әдәбияты. 1942. № 3. Б. 79–80.

64. Кашшаф Г. К. Нәҗми әсәрләре // Красная Татария. 1942. 4 апрель.

65. Кашшаф Г. Посылка (хикәя) // Совет әдәбияты. 1942. № 3. Б. 24–33.

66. Кашшаф Г. Рус кешеләре // Кызыл Татарстан. 1942. 31 октябрь.

67. Кашшаф Г. Хуш, ялкынлы талант // Совет әдәбияты. 1942. № 11–12. Б. 130–132.

68. Кашшаф Г. Иҗтимагый моңнар җырчысы // Совет әдәбияты. 1943. № 5. Б. 41–51.

69. Кашшаф Г., Җ. Фәйзи. Татар операсының үсүе // Кызыл Татарстан. 1943. 24 июль.

70. Кашшаф Г. Урман. Юл язмалары // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 65–68.

71. Кашшаф Г. Ил агалары // Кызыл Татарстан. 1943. 1 август.

72. Кашшаф Г., Җ. Фәйзи. Татар операсының үсүе // Совет әдәбияты. 1943. № 8. Б. 72–78.

73. Кашшаф Г. Татар әдәбияты яңа борылышта // Кызыл Татарстан. 1943. 23 ноябрь.

74. Кашшаф Г. Татарские писатели в Москве // Красная Татария. 1943. 23 ноября.

75. Кашшаф Г. Вечер памяти Ш. Камала // Красная Татария. 1943. 26 декабрь.

76. Кашшаф Г. Укытучы. Казан: Татгосиздат, 1943. Б. 112.

77. Кашшаф Г. Ватан сугышы чорында татар совет әдәбияты // Кызыл Татарстан. 1944. 13 февраль.

78. Кашшаф Г. Шәриф Камалның тууына 60 ел тулу уңае белән // Совет әдәбияты. 1944. № 2–3. Б. 84–86.

79. Кашшаф Г. Халыкка мәхәббәт, дошманга нәфрәт җырлады ул // Кызыл Татарстан. 1944. 1 март.

80. Кашшаф Г. Безнең урамда бәйрәм // Кызыл Татарстан. 1944. 28 март.

81. Кашшаф Г. «Гроза» // Кызыл Татарстан. 1944. 5 апрель.

82. Кашшаф Г., Нәҗми К. Диңгез батыры (очерк) // Кызыл Татарстан. 1944. 30 апрель.

83. Кашшаф Г., Нәҗми К. Диңгез батыры (очерк) // Совет әдәбияты. 1944. № 4. Б. 53–56.

84. Кашшаф Г. Ватан сугышы елларында татар совет әдәбияты // Кызыл таң. 1944. 20 август.

85. Кашшаф Г. Ютазы хатлары // Кызыл Татарстан. 1944. 8, 10 октябрь.

86. Кашшаф Г. Сезон башы // Совет әдәбияты. 1944. №11–12. Б. 94–96.

87. Кашшаф Г. Патриотизм көче // Совет әдәбияты. 1945. № 5. Б. 65–67.

88. Кашшаф Г. «Ашыгыч нәтиҗә» // Совет әдәбияты. 1945. № 5. Б. 118–121.

89. Кашшаф Г. Василий Яницкий // Совет әдәбияты. 1945. № 6. Б. 42–54.

90. Кашшаф Г. Киң колачлы әсәрләр көтәбез // Совет әдәбияты. 1945. № 6. Б. 72–73.

91. Кашшаф Г. Гадел Кутуй // Совет әдәбияты. 1945. № 7. Б. 58–67.

92. Кашшаф Г. Чырайлы җитдилек һәм реаль хисләр өчен // Совет әдәбияты. 1945. № 8. Б. 68–77.

93. Кашшаф Г. «Әби һәм кияү» (хикәя) // Совет әдәбияты. 1945. № 10. Б. 131–134.

94. Кашшаф Г. Тарихи шәхесләрне гәүдәләндерү юлында // Совет әдәбияты. 1945. № 11. Б. 101–112.

95. Кашшаф Г. Куен дәфтәреннән // Совет әдәбияты. 1946. № 1. Б. 120–124.

96. Кашшаф Г. Иң мөһим нәрсә // Совет әдәбияты. 1946. № 1. Б. 128.

97. Кашшаф Г. Тавышны аңа багышлыйм // Кызыл Татарстан. 1946. 3 февраль.

98. Кашшаф Г. Халык тантанасы // Кызыл Татарстан. 1946. 12 февраль.

99. Кашшаф Г. Салих Сәйдәшев концерты // Кызыл Татарстан. 1946. 22 февраль.

100. Кашшаф Г. Сайлау кампаниясе һәм язучылар // Совет әдәбияты. 1946. № 2. Б. 100–108.

101. Кашшаф Г. Ул көрәш моңнарын җырлады // Совет әдәбияты. 1946. № 2. Б. 112–114.

102. Кашшаф Г. Мендәр (күңелле хикәя) // Совет әдәбияты. 1946. № 3. Б. 68–72.

103. Кашшаф Г. Татар совет әдәбиятының мөһим бурычлары // Кызыл Татарстан. 1946. 19 апрель.

104. Кашшаф Г. Бөек хисләр // Кызыл Татарстан. 1946. 9 май.

105. Кашшаф Г. Тукай – публицист // Кызыл Татарстан. 1946. 12 май.

106. Кашшаф Г. Ант картинасы − Совет киносының зур җиңүе // Кызыл Татарстан. 1946. 21 август.

107. Кашшаф Г. Уңышсызлык һәм аның сәбәпләре // Совет әдәбияты. 1946. № 7-8. Б. 133–144.

108. Кашшаф Г., Мөсәгыйть Ф. Бер уңышсыз спектакль турында // Кызыл Татарстан. 1946. 15 сентябрь.

109. Кашшаф Г. Ил авазы булып яңгырый алмаган җыентык // Совет әдәбияты. 1946. № 9. Б. 116–120.

110. Кашшаф Г. Пьесалар җыентыгы // Совет әдәбияты. 1946. № 10. Б. 92–98.

111. Кашшаф Г. Тормыш җыры // Кызыл Татарстан. 1947. 5 март.

112. Кашшаф Г. Кави Нәҗми. Очерк // Совет әдәбияты. 1947. № 2–3. Б. 133–136.

113. Кашшаф Г. Рус мәсьәләсе // Кызыл Татарстан. 1947. 9 апрель.

114. Кашшаф Г. Кави Нәҗми хикәяләре // Кызыл Татарстан. 1947. 19 апрель.

115. Кашшаф Г. Нур Баян // Совет әдәбияты. 1947. № 4. Б. 90–94.

116. Кашшаф Г. Юлбашчыларыбызның образлары татар сәхнәсендә // Кызыл Татарстан. 1947. 7 май.

117. Кашшаф Г. Человек с ружьем // Красная Татария. 1947. 30 мая.

118. Кашшаф Г. Ленин, Сталин образлары татар сәхнәсендә // Совет әдәбияты. 1947. № 5. Б. 96–103.

119. Кашшаф Г. Әхмәт Фәйзинең поэтик йөзе // Совет әдәбияты. 1947. № 6. Б. 91 – 105.

120. Кашшаф Г. Зәңгәр кыя // Совет әдәбияты. 1947. № 7. Б. 97 – 104.

121. Кашшаф Г. Татар совет әдәбиятының 30 еллыгы // Совет әдәбияты. 1947. № 11. Б. 74–90.

122. Кашшаф Г. Хезмәт иясләренең дәртле җырчысы // Кызыл Татарстан. 1947. 28 декабрь.

123. Кашшаф Г. Большевик язучы // Совет әдәбияты. 1947. № 12. Б. 96–99.

124. Кашшаф Г. Гадел Кутуй // Кутуй Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1947. Б. 5–24.

125. Кашшаф Г. Наш друг М. Горький // Красная Татария. 1948. 28 марта.

126. Кашшаф Г. Тарихи карарны үтәү юлында // Кызыл Татарстан. 1948. 14 август.

127. Кашшаф Г. Тарихи карардан соң // Совет әдәбияты. 1948. № 8. Б. 87–90.

128. Кашшаф Г. Җыр дәвам итә // Кызыл Татарстан. 1948. 3 октябрь.

129. Кашшаф Г. Хыялны узган чынлык // Кызыл Татарстан. 1948. 6 ноябрь.

130. Кашшаф Г. Тәнкыйть мәсьәләләренә карата // Совет әдәбияты. 1949. № 7. Б. 90–96.

131. Кашшаф Г. Прекрасна как жизнь // Совет әдәбияты. 1949. № 7. Б. 77–89.

132. Кашшаф Г. Социаль вакыйгаларны яктырту юлында // Совет әдәбияты. 1949. № 10. Б. 101–115.

133. Кашшаф Г. Аның исеме белән // Кызыл Татарстан. 1950. 1 январь.

134. Кашшаф Г. Ватан данын җырлаучы // Совет әдәбияты. 1950. № 2. Б. 47–53.

135. Кашшаф Г. Матур әдәбият өлкәсендә // Кызыл Татарстан. 1950. 4 март.

136. Кашшаф Г. Гаделлек байрагы астында // Кызыл Татарстан. 1950. 12 март.

137. Кашшаф Г. Безнең заман геройлары // Совет әдәбияты. 1950. № 3. Б. 109– 123.

138. Кашшаф Г. Мәҗит Гафури // Кызыл Татарстан. 1950. 25 июль.

139. Кашшаф Г. Татарстанда әдәбиятның яңа күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1950. № 8. Б. 65–84.

140. Кашшаф Г. Шәриф Камалның драмалары // Камал Ш. Әсәрләр: 2 т. Т. 1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1950. Б. 3–8.

141. Кашшаф Г. Татар совет әдәбиятының югары уңышы // Совет мәктәбе. 1951. № 2. Б. 15–17.

142. Кашшаф Г. Матур темалар, җитлекмәгән образлар // Совет әдәбияты. 1951. № 6. Б. 101–115.

143. Кашшаф Г. Балканда // Совет Татарстаны. 1951. 8 август.

144. Кашшаф Г. Без тыныч профессия кешеләре // Совет әдәбияты. 1951. № 10. Б. 15–17.

145. Кашшаф Г. Күренекле язучы, ялкынлы патриот // Совет Татарстаны. 1951. 15 декабрь.

146. Кашшаф Г. Уңышлар һәм теләкләр // Совет Татарстаны. 1952. 1 январь.

147. Кашшаф Г. Татар сәхнәсенең күренекле остасы // Совет Татарстаны. 1952. 15 февраль.

148. Кашшаф Г. Тормышны тирәнтен һәм дөрес чагылдыру өчен // Совет әдәбияты. 1952. № 2. Б. 92–114.

149. Кашшаф Г. Яшьлек спектакле // Совет Татарстаны. 1952. 20 март.

150. Кашшаф Г. Бөек рус язучысы // Пионер. 1952. № 3. Б. 1–3.

151. Кашшаф Г. Утыз ел // Совет Татарстаны. 1952. 26 июнь.

152. Кашшаф Г. Тридцатилетие журнала «Совет әдәбияты» // Комсомолец Татарии. 1952. 27 июня.

153. Кашшаф Г. Зур җиңү // Совет әдәбияты. 1952. № 8. Б. 10–102.

154. Кашшаф Г. Чорыбызга лаеклы художество әсәрләре бирик // Совет Татарстаны. 1952. 4 декабрь.

155. Кашшаф Г. О положительном герое наших дней // Советская Татария. 1952. 7 декабря.

156. Кашшаф Г. Шариф Камал // Комсомолец Татарии. 1952. 21 декабря.

157. Кашшаф Г. За глубокое и правильное отражение жизни // Советская литература. 1952. № 12. С. 92–114.

158. Кашшаф Г. Тормышны тирәннән һәм дөрес чагылдыру // Совет әдәбияты. 1952. № 12. Б. 92–114.

159. Кашшаф Г. Шәриф Камалның иҗат юлы // Камал Ш. Әсәрләр: 4 т. Казан: Таткнигоиздат, 1952. Т. 1. Б. 5–18.

160. Кашшаф Г. Шәриф Камалның драмалары // Камал Ш. Әсәрләр: 4 т. Казан: Таткнигоиздат, 1952. Т. 2. Б. 5–10.

161. Кашшаф Г. Корыч ихтыярлы шагыйрь // Совет Татарстаны. 1953. 30 апрель.

162. Кашшаф Г. Муса Джалиль – поэт несгибаемой воли // Комсомолец Татарии. 1953. 31 мая.

163. Кашшаф Г. Мудрый учитель и наставник // Советская Татария. 1953. 18 июня.

164. Кашшаф Г. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр // Совет әдәбияты. 1953. № 6. Б. 99–124.

165. Кашшаф Г. Источник бессмертия // Известия. 1953. 24 июня.

166. Кашшаф Г. «Рәйхан» // Совет Татарстаны. 1953. 30 июль.

167. Кашшаф Г. Үлемсезлек // Кызыл таң. 1953. 23 август.

168. Кашшаф Г. Гадел Кутуй // Совет Татарстаны. 1953. 28 ноябрь.

169. Кашшаф Г. Бессмертие // Муса Джалиль. Стихи, написанные в Моабитском застенке. Казань, 1953. С. 3–21.

170. Кашшаф Г. Шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты // Совет Татарстаны. 1953. 31 декабрь.

171. Кашшаф Г. Үлемсезлек // Җәлил М. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр. Казан: Таткнигоиздат, 1953. Б. 3–21.

172. Кашшаф Г. «Үлемсезлек» (Муса Җәлилнең соңгы шигырьләре) // Җәлил М. Җырларым. Моабит төрмәсендә язылган шигырьләр. 2 нче басма. Казан: Таткнигоиздат, 1954. Б. 3–22.

173. Кашшаф Г. Халык язучысы // Гафури М. Сайланма әсәрләр. Казан, 1953. Б. 5–14.

174. Кашшаф Г. Гадел Кутуй (Язучының тормыш һәм иҗат юлы) [Кереш сүз] // Кутуй Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1953. Б. 3–20.

175. Кашшаф Г. 1954 елда совет әдәбияты // Яшь сталинчы. 1954. 1 январь.

176. Кашшаф Г. Поэт – герой // Советская Татария. 1954. 7 января.

177. Кашшаф Г. Халык шагыйре – халык герое // Совет әдәбияты. 1954. № 1. Б. 77–88.

178. Кашшаф Г. Күңел көрлеге белән... // Совет Татарстаны. 1954. 15 март.

179. Кашшаф Г. «Саубановы» // Советская Татария. 1954. 16 июня.

180. Кашшаф Г. Әдәбиятта уңай герой мәсьәләсенә карата // Совет әдәбияты. 1954. № 6. Б. 47–65.

181. Кашшаф Г. Әдәбиятның идея-художество дәрәҗәсен күтәрик! // Совет Татарстаны. 1954. 14 август.

182. Кашшаф Г. Күргәзмәдә. Очерк // Совет әдәбияты. ф 1954. № 9. Б. 52–62.

183. Кашшаф Г. Иҗат эшебезне көчәйтә төшик // Совет Татарстаны. 1954. 2 декабрь.

184. Кашшаф Г. О положительном герое наших дней // Советская Татария. 1954. 7 декабря.

185. Кашшаф Г. Онытылмассың // Совет әдәбияты. 1955. № 1. Б. 93–95.

186. Кашшаф Г. Кеше көченең полководецы // Совет Татарстаны. 1955. 3 март.

187. Кашшаф Г. Кечкенә хикәяләр турында // Совет Татарстаны. 1955. 17 апрель.

188. Кашшаф Г. Муса Джалиль – поэт несгибаемой воли // Комсомолец Татарии. 1955. 31 мая.

189. Кашшаф Г. Гадел Кутуй // Совет Татарстаны. 1955. 17 июнь.

190. Кашшаф Г. Минем хатын (рецензия) // Совет Татарстаны. 1955. 5 ноябрь.

191. Кашшаф Г. Кыска хикәяләр // Шәйми М. Кыска хикәяләр. Казан, 1955. Б. 3–7.

192. Кашшаф Г. Муса Джалиль // Джалиль М. Героическая песня. Стихи. Изд-во ЦК ВЛКСМ «Молодая гвардия», 1955. С. 3–14.

193. Кашшаф Г. Шагыйрь һәм батырлык // Муса Җәлил: Сайланма әсәрләр: 3 томда. Казан: Таткнигоиздат, 1955. Т. 1. Б. 7–86.

194. Кашшаф Г. Предисловие // Поэзия Советской Татарии. М.: Гослитиздат, 1955. С. 5–30.

195. Кашшаф Г. Поэт-патриот Муса Джалиль. Доклад на сессии Ученого совета. Казань, 1955. С. 15.

196. Кашшаф Г. Подвиг поэта // Известия. 1956. 3 февраля.

197. Кашшаф Г. Патриот шагыйрь // Совет Татарстаны. 1956. 3 февраль.

198. Кашшаф Г. Бессмертие // Советская Татария. 1956. 14 февраля.

199. Кашшаф Г. Джалиль с нами // Комсомолец Татарии. 1956. 15 февраля.

200. Кашшаф Г. Абдулла Алиш. Көрәшче, язучы турында яңа материаллар // Яшь сталинчы. 1956. 4 май.

201. Кашшаф Г. Абдулла Алиш – язучы һәм көрәшче // Совет әдәбияты. 1956. № 6. Б. 109–117.

202. Кашшаф Г. Ф. Әсгать // Совет Татарстаны. 1956. 27 сентябрь.

203. Кашшаф Г. Ф. Әсгать // Совет әдәбияты. 1956. № 9. Б. 97–99.

204. Кашшаф Г. Декада спектакле // Совет Татарстаны. 1956. 31 октябрь.

205. Кашшаф Г. Яшьләр иҗатына карата // Совет Татарстаны. 1956. 27 ноябрь.

206. Кашшаф Г. Минем тәкъдимнәр // Совет Татарстаны. 1956. 13 декабрь.

207. Кашшаф Г. Беренче артистка // Совет әдәбияты. 1957. № 3. Б. 78–87 .

208. Кашшаф Г. Яшьлек һәм көрәш бакчасы // Совет Татарстаны. 1957. 23 апрель.

209. Кашшаф Г. Чорыбызның бөек герое // Татарстан яшьләре. 1957. 24 апрель.

210. Кашшаф Г. Моабитские тетради // Советская Татария. 1957. 24 апреля.

211. Кашшаф Г. Муса Джалиль и его «Моабитская тетрадь» // Гудок. 1957. 9 мая.

212. Кашшаф Г. Судьба человека – судьба песни // Комсомольская Правда. 1957. 24 мая.

213. Кашшаф Г. Шагыйрь эзеннән // Совет әдәбияты. 1957. № 5. Б. 96–109.

214. Кашшаф Г. Беренче тәэсирләр, беренче йомгаклар // Совет әдәбияты. 1957. № 7. Б. 71–74.

215. Кашшаф Г. Андре Тиммерманс белән очрашу // Совет Татарстаны. 1957. 18 август.

216. Кашшаф Г. Халык белән бергә // Совет әдәбияты. 1957. № 9. Б. 23–24.

217. Кашшаф Г. Һәрвакыт халык белән // Татарстан яшьләре. 1957. 15, 17 декабрь.

218. Кашшаф Г. Язучы һәм көрәшче // Алиш А. Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1957. Б. 3–18.

219. Кашшаф Г. Муса Җәлил. Тормышы һәм иҗаты турында очерк. Казан: Таткнигоиздат, 1957. 380 б.

220. Кашшаф Г. Яңа шәһәрдә. Очерк // Совет әдәбияты. 1958. № 1. Б. 47–58.

221. Кашшаф Г. Өлкән шагырьнең истәлекләре (Сәйфи Кудаш) // Совет әдәбияты. 1958. № 4. Б. 119–121.

222. Кашшаф Г. Халыкчан һәм тормышчан // Совет Татарстаны. 1958. 6 июнь.

223. Кашшаф Г. «Кыз урлау» // Татарстан яшьләре. 1958. 17 июнь.

224. Кашшаф Г. Поэт-герой Муса Джалиль // Труд. 1958. 3 июля.

225. Кашшаф Г. М. Җәлилнең яшерен оешмасында // Совет Татарстаны. 1958. 6 август.

226. Кашшаф Г. Бүгенге драматургия һәм тормышчан конфликт турында // Совет әдәбияты. 1958. № 8. Б. 87–99.

227. Кашшаф Г. Абдулла Алиш // Ялкын. 1958. № 9. Б. 16–17.

228. Кашшаф Г. Съезд алдыннан уйлану // Татарстан яшьләре. 1958. 4 декабрь.

229. Кашшаф Г. Беренче артистка. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 50 б.

230. Кашшаф Г. Язучы турында // Әсгать Ф. Сүзләрдән чәчәкләр. Казан, 1958. Б. 3–14.

231. Кашшаф Г. Шагыйрь һәм солдат // Совет Татарстаны. 1959. 9 январь.

232. Кашшаф Г. Сәхнәдә Ленин образы // Совет Татарстаны. 1959. 4 февраль.

233. Кашшаф Г. Бәхет һәм гаделлек җырчысы // Совет Татарстаны. 1959. 28 февраль.

234. Кашшаф Г. Янып яшәргә, дулкынланып язарга // Совет Татарстаны. 1959. 17 май.

235. Кашшаф Г. Маяк булып балкыган исемнәр // Совет әдәбияты. 1959. № 8. Б. 63–73.

236. Кашшаф Г. Аларның исемен халык онытмас // Совет Татарстаны. 1959. 25 август.

237. Кашшаф Г. Еники А. Труженик литературы // Совет Татарстаны. 1960. 13 января.

238. Кашшаф Г. Социалистик җәмгыятьтә мәхәббәт һәм гаилә // Татарстан яшьләре. 1960. 20 февраль.

239. Кашшаф Г. Француз партизаннары белән // Совет Татарстаны. 1960. 27 март.

240. Кашшаф Г. Яңалык нәрсәдә // Совет әдәбияты. 1960. № 3. Б. 98–105.

241. Кашшаф Г. Хөррият // Совет Татарстаны. 1960. 30 апрель.

242. Кашшаф Г. Монографик хезмәтләр кирәк // Совет әдәбияты. 1960. № 4. Б. 142–145.

243. Кашшаф Г. Татар әдәбияты атналыгы // Татарстан яшьләре. 1960. 23 июнь.

244. Кашшаф Г. Казан // Совет Татарстаны. 1960. 25 июнь.

245. Кашшаф Г. Тагын мәхәббәт турында // Татарстан яшьләре. 1960. 14 июль.

246. Кашшаф Г. Башкортстанда татар әдәбияты атналыгы // Совет әдәбияты. 1960. № 7. Б. 148–153.

247. Кашшаф Г. Смерть прозвучала песней // Советская Украина. 1960. № 4. С. 144 – 149.

248. Кашшаф Г. Ульянова-Елизарова А.И. Ильичның балалык һәм мәктәп еллары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. Б. 40.

249. Кашафутдинов М.С. Основные этапы развития татарской советской литературы и творчество Мусы Джалиля: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1960. С. 22.

250. Кашшаф Г. «Моабит төрмәсендә язылган шигырьләренә карата» // Җәлил М. Сайланма әсәрләр [Шигырьләр, поэмалар]. Казан: Таткнигоиздат, 1960. Б. 538–548.

251. Кашшаф Г., Кац М. Сабантуй (Отрывок из киносценария «Муса Джалиль») // Советская Татария. 1961.15 февраля.

252. Кашшаф Г. «Татар совет әдәбияты тарихы» китабы турында // Совет әдәбияты. 1961. № 2. Б. 126–141.

253. Кашшаф Г. Безнең кояш // Совет әдәбияты. 1961. № 4. Б. 58–60.

254. Кашшаф Г. Рәхим итегез, кардәшләр! // Социалистик Татарстан. 1961. 25 май.

255. Кашшаф Г. Драматург һәм режиссер // Социалистик Татарстан. 1961. 30 май.

256. Кашшаф Г. Кем ул? // Азат хатын. 1961. № 5. Б. 14–15.

257. Кашшаф Г. Добро пожаловать, братья! // Комсомолец Татарии. 1961. 4 июня.

258. Кашшаф Г. Культурабызга зур хәзинә // Совет әдәбияты. 1961. №6. Б. 134–139.

259. Кашшаф Г. Чувство семьи единой // Литература и жизнь. 1961. 2 августа.

260. Кашшаф Г. Заманыбыз белән рухланып // Совет әдәбияты. 1961. № 8. Б. 16–23.

261. Кашшаф Г. Шагыйрь күңеле // Совет әдәбияты. 1961. № 11. Б. 149–151.

262. Кашшаф Г. Бир кулыңны, шагыйрь! // Социалистик Татарстан. 1961. 23 декабрь.

263. Кашшаф Г. Газета битләреннән башлап... // Социалистик Татарстан. 1961. 28 декабрь.

264. Кашшаф Г. Муса Җәлил. Герой-шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. 454 б.

265. Кашшаф Г. Муса Җәлил турында яңалык бар // Социалистик Татарстан. 1962. 28 март.

266. Кашшаф Г. Новое о Мусе Джалиле [По воспоминаниям участников подполья и бывших военнопленных] // Литература и жизнь. 1962. 28 марта.

267. Кашшаф Г. Шагыйрь һәм бүгенге көн // Совет әдәбияты. 1962. № 4. Б. 119–127.

268. Кашшаф Г. Игезәк батырлар // Ялкын. 1962. № 5. Б. 26–27.

269. Кашшаф Г., Мустафин Р. По следам ненайденных песен... // Комсомолец Татарии. 1962. 23 ноября – 26 декабря.

270. Кашшаф Г. Соңгы минутларда // Совет әдәбияты. 1962. №9. Б. 149–153.

271. Кашшаф Г. Дружба композитора и поэта // Советская Татария. 1962. 23 декабря.

272. Кашшаф Г. Якты талант // Социалистик Татарстан. 1963. 20 март.

273. Кашшаф Г., Мустафин Р. По следам ненайденных песен... // Комсомолец Татарии. 1963. 6, 20, 27 января, 8, 15, 22 февраля, 10 марта.

274. Кашшаф Г. Мустафин Р. Ищем песни Мусы Джалиля // Литературная Россия. 1963. 26 апреля.

275. Кашшаф Г. Милли әдәбиятларның бер-беренә якынаюы // Совет әдәбияты. 1963. № 4. Б. 129–131.

276. Кашшаф Г. Безгә рәхим итегез! // Татарстан яшьләре. 1963. 23 июль.

277. Кашшаф Г. Журналист эшенә өйрәнеп буламы? // Социалистик Татарстан. 1963. 24 июль.

278. Кашшаф Г. Күмәк иҗат тантанасы // Социалистик Татарстан. 1963. 22 сентябрь.

279. Кашшаф Г. Революция җырчысы // Социалистик Татарстан. 1963. 8 декабрь.

280. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1964. 14 гыйнвар.

281. Кашшаф Г. Әдәбият укытуны − бүгенге көн таләпләренә // Совет мәктәбе . 1964. № 2. Б. 31–37.

282. Кашшаф Г. Чибәрлек һәм бәхет турында // Татарстан яшьләре. 1964. 7 март.

283. Кашшаф Г. Чибәрлек һәм бәхет турында // Татарстан яшьләре. 1964. 10 март.

284. Кашшаф Г. Чибәрлек һәм бәхет турында // Татарстан яшьләре. 1964. 13 март.

285. Кашшаф Г. Чибәрлек һәм бәхет турында // Татарстан яшьләре. 1964. 14 март.

286. Кашшаф Г. «Красная ромашка» расцвела и на полянах немецкой земли // Советская Татария. 1964. 15 марта.

287. Кашшаф Г. Үз кеше иде ул... // Совет әдәбияты. 1964. № 5. Б. 8.

288. Кашшаф Г. Яшь журналистлар игътибарына // Татарстан яшьләре. 1964. 30 июль.

289. Кашшаф Г. Сезне университет көтә // Социалистик Татарстан. 1964. 31 июль.

290. Кашшаф Г., Мустафин Р. Еще одно свидетельство очевидца // Комсомолец Татарии. 1964. 23 августа.

291. Кашшаф Г. Небенцаль Л. Письмо из Берлина [Г. Кашшафу о Моабитской тюрьме] // Советская Татария. 1964. 25 августа.

292. Кашшаф Г. Он так любил жизнь // Литературная газета. 1964. 27 августа.

293. Кашшаф Г. Всегда в строю // Советская Татария. 1964. 10 октября.

294. Кашшаф Г. Дәртле талант // Социалистик Татарстан. 1964. 10 октябрь.

295. Кашшаф Г. Финиш ерак булсын // Совет әдәбияты. 1964. № 10. Б. 123–124.

296. Кашшаф Г. Муса турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 310 б.

297. Кашшаф Г. Эшләпә (хикәя) // Чаян. 1965. № 17. Б. 6–7.

298. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1965. 14 гыйнвар.

299. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1965. 22 гыйнвар.

300. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1965. 11 февраль.

301. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1965. 21 февраль.

302. Кашшаф Г. Безнең якларда // Социалистик Татарстан. 1965. 4 март.

303. Кашшаф Г. Нур Баян // Советская Татария. 1965. 30 мая.

304. Кашшаф Г. Большой вклад в литературоведение // Советская Татария. 1965. 27 августа.

305. Кашшаф Г. Муса Җәлил юбилее алдыннан [Юбилей комиссиясенең планнары һәм эше турында] // Социалистик Татарстан. 1965. 12 сентябрь.

306. Кашшаф Г. Зур юбилей алдыннан // Совет мәктәбе . 1965. № 9. Б. 2–4.

307. Кашшаф Г. Леон Небенцаль Казанда // Казан утлары. 1965. № 9. Б. 154–155.

308. Кашшаф Г. Муса сугышка китә (чын хикәя) // Ялкын. 1965. № 11. Б. 12–14.

309. Кашшаф Г. Муса Җәлил юбилеена карата // Социалистик Татарстан. 1965. 8 декабрь.

310. Кашшаф Г. Подвиг Джалиля // Советская Татария. 1965. 22 декабря.

311. Кашшаф Г. Ил батыры [Муса Җәлил шигыре дип уйланган әсәр турында] // Социалистик Татарстан. 1965. 22 декабрь.

312. Кашшаф Г., Мустафин Р. Поиск продолжается. Казань, 1965. 86 с.

313. Кашшаф Г. Муса фронтта (очерк) // Кызыл таң. 1966. 3–6 февраль.

314. Кашшаф Г. Немец халкы Мусаны зурлый [60 ел тулу уңае белән Германиянең күп шәһәрләрендә үткәрелгән кичәләр турында] // Социалистик Татарстан. 1966. 20 февраль.

315. Кашшаф Г. Немецкий народ чтит память советского поэта [О вечере в Берлине в Центральном Доме германо-советской дружбы] // Советская Татария. 1966. 27 февраля.

316. Кашшаф Г. Анын шигырьләреме? [Муса Җәлил шигырьләре дип уйланылган әсәрләр турында] // Казан утлары. 1966. № 2. Б. 17–27.

317. Кашшаф Г. Поиск. О поиске друзей Джалиля по плену // Москва. 1966. № 2. С. 209–211.

318. Кашшаф Г. Утренняя звезда Джалиля // Детская литература. 1966. № 4. С. 22–24.

319. Кашшаф Г. Яныл калды гомере маяк булып // Яшь Ленинчы. 1966. 5 ноябрь.

320. Кашшаф Г. Үрнәк кеше // Социалистик Татарстан. 1966. 27 ноябрь.

321. Кашшаф Г. Үрнәк кеше // Г. Ибраһимов турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 213–215 б.

322. Кашшаф Г. Матурлык һәм бәхет. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. 80 б.

323. Кашшаф Г. Воспоминания о Мусе Джалиле. Казань: Таткнигоиздат, 1966. С. 236.

324. Кашшаф Г. Поэт и борец // Муса Джалиль. К 60-летию со дня рождения поэта-героя. Казань: Газетно-журнальное изд-во Татарского обкома КПСС, 1966. С. 3–24.

325. Кашшаф Г. Тамашачы мәхәббәте // Социалистик Татарстан. 1967. 28 февраль.

326. Кашшаф Г. Родник неиссякаемый // Советская Татария. 1967. 31 октября.

327. Кашшаф Г. Беренче артистка // Габдулла Кариев турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Б. 115–117.

328. Кашшаф Г. Муса исеме Антарктидада [Муса Җәлил тавы] // Социалистик Татарстан. 1968. 16 май.

329. Кашшаф Г. Хатип Госман // Казан утлары. 1968. № 5. Б. 131–133.

330. Кашшаф Г. Үзем гаепле // Чаян. 1968. № 5. Б. 7.

331. Кашшаф Г. Светлая улыбка // Советская Татария. 1968. 15 сентября.

332. Кашшаф Г. Язучы һәм көрәшче // Кызыл таң. 1968. 15 сентябрь.

333. Кашшаф Г. Гаделлек солдаты // Казан утлары. 1968. № 9. Б. 85–86.

334. Кашшаф Г. Чүл буенда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. Б.94.

335. Кашшаф Г. Драматург һәм журналист // Социалистик Татарстан. 1969. 7 январь.

336. Кашшаф Г. Певец мужества // Советская Татария. 1969. 9 января.

337. Кашшаф Г. Күңелгә якын ул башкорт сәнгате // Социалитик Татарстан. 1969. 6 июнь.

338. Кашшаф Г. Эмоциональ спектакль // Социалистик Татарстан. 1969. 14 июнь.

339. Кашшаф Г. Живи, Башкирия! // Агидель. 1969. № 3. С. 16–17.

340. Кашшаф Г. Күрше күзлеге аша // Кызыл таң. 1969. 15 апрель.

341. Кашшаф Г. Башкортстанда // Казан утлары. 1969. № 6. Б. 152–163.

342. Кашшаф Г. Олы һәм матур иҗат юлы // Социалистик Татарстан. 1969. 3 октябрь.

343. Кашшаф Г. Юбилей спектакле // Социалистик Татарстан. 1969. 19 декабрь.

344. Г. Кашшаф Безнең шагыйрь // Җәлил М. Моабит дәфтәрләре. Шигырьләр, поэмалар, җырлар. [Сүз башын язучы, искәрмәләр бирүче Г. Кашшаф]. Казан: Тат.кит.нәшр., 1969. Б. 5–32.

345. Кашшаф Г. Киң колачлы талант // Социалистик Татарстан. 1970. 11 январь.

346. Кашшаф Г. Мин борчылам // Социалистик Татарстан. 1970. 21 январь.

347. Кашшаф Г. Кызлар җавап көтәләр // Татарстан яшьләре. 1970. 25 июль.

348. Кашшаф Г. Аның идеяләре белән рухланып // Казан утлары. 1970. № 6. Б. 138–145.

349. Кашшаф Г. Бер рецензия уңае белән // Татарстан яшьләре. 1970. 11 сентябрь.

350. Кашшаф Г. Эшче – горур яңгырый // Социалистик Татарстан. 1970. 13 ноябрь.

351. Кашшаф Г. Онытылмасын // Татарстан яшьләре. 1970. 3 декабрь.

352. Кашшаф Г. Дустыбыз иде // Социалистик Татарстан. 1970. 8 декабрь.

353. Кашшаф Г. Очерк в газетах Татарии // Мастерство очеркиста. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1970. Вып. 1. С. 3–15.

354. Кашшаф Г. Тирән чишмә // Азат хатын. 1971. № 1. Б. 11.

355. Кашшаф Г. Тынгысыз әдип Афзал Шамовка 70 яшь // Татарстан яшьләре. 1971. 4 март.

356. Кашшаф Г. Писатель, фронтовик, коммунист // Советская Татария. 1971. 4 марта.

357. Кашшаф Г. Эңгер-меңгер // Социалистик Татарстан. 1971. 2 май.

358. Кашшаф Г. Кайнар эзләр // Яшь ленинчы. 1971. 16 октябрь.

359. Кашшаф Г. Фәхри Әсгат // Казан утлары. 1971. № 10. Б. 182.

360. Кашшаф Г. Акчарлаклар // Совет Татарстаны. 1971. 17 ноябрь.

361. Кашшаф Г. Югары идеялелек өчен // Социалистик Татарстан. 1971. 21 ноябрь.

362. Кашшаф Г. Якты хатирәләр // Социалистик Татарстан. 1971. 15 декабрь.

363. Кашшаф Г. Большой друг татарской литературы // Советская Татария. 1971. 25 декабря.

364. Кашшаф Г. Талант чишмәсе // Социалистик Татарстан. 1971. 28 декабрь.

365. Кашшаф Г. Көн яктысы.... Төшлек вакыты // Ялкын. 1971. № 12. Б. 5.

366. Кашшаф Г. Укучы өчен, халык өчен // Социалистик Татарстан. 1972. 17 февраль.

367. Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Казан утлары. 1972. № 3. 139–Б. 158.

368. Кашшаф Г. Лаеклы әдип // Социалистик Татарстан. 1972. 21 апрель.

369. Кашшаф Г. Илһамландыргыч көч // Социалистик Татарстан. 1972. 5 ноябрь.

370. Кашшаф Г. Якты, үзенчәлекле талант // Социалистик Татарстан. 1972. 17 декабрь.

371. Кашшаф Г. Эре характерлар сурәтләгәндә // Социалистик Татарстан. 1972. 22 декабрь.

372. Кашшаф Г. Юбилей спектакле // Социалистик Татарстан. 1973. 6 гыйнвар.

373. Кашшаф Г. Тормышын хезмәт бизәде // Социалистик Татарстан. 1973. 18 апрель.

374. Кашшаф Г. «Салават» // Социалистик Татарстан. 1973. 8 июнь.

375. Кашшаф Г. Революция солдаты (Шамил Усманов) // Казан утлары. 1973. № 9. Б 130–133.

376. Кашшаф Г. Бәйрәм кояшы балкый // Татарстан яшьләре. 1973. 7 ноябрь.

377. Кашшаф Г. Чикләвек төше // Социалистик Татарстан. 1973. 22 ноябрь.

378. Кашшаф Г. Диләрә ханым // Совет әдәбияты. 1973. № 10. Б. 111 – 128.

379. Кашшаф Г. Иҗат портретына штрихлар // Казан утлары. 1974. № 2. Б. 176 –180.

380. Кашшаф Г. Кайнар йөрәкле әдип // Татарстан яшьләре. 1974. 16 март.

381. Кашшаф Г. Әсәрнең икенче гомере // Татарстан яшьләре. 1974. 20 апрель.

382. Кашшаф Г. Бар җырымны илгә багышладым... // Яшь ленинчы. 1974. 24 август.

383. Кашшаф Г. Бер төн // Социалистик Татарстан. 1974. 3 ноябрь.

384. Кашшаф Г. Үзенчәлекле талант // Казан утлары. 1975. № 6. Б. 116–119.

385. Кашшаф Г. Пәрдә ябылды... Проблемалар калды. Театр сезоны турында уйланулар // Социалистик Татарстан. 1975. 20 июль.

386. Кашшаф Г. Ил белән, халык белән (Гариф Ахуновка 50 яшь) // Социалистик Татарстан. 1975. 18 сентябрь.

387. Кашшаф Г. Якты бәйрәмебез // Социалистик Татарстан. 1975. 6 ноябрь.

388. Кашшаф Г. Күңел көзгесе: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 206 б.

389. Кашшаф Г. Журналистлык кайда бетә? // Казан утлары. 1977. № 4. Б. 154–158.

390. Кашшаф Г. Әхәт Гаффаров иҗаты турында // Казан утлары. 1977. № 8. Б. 177–178.

391. Кашшаф Г. По завещанию Мусы Джалиля. Казань: Таткнигоиздат, 1984. С. 224.

392. Кашшаф Г. Шагыйрь иҗаты (Мирас ядкәре) // Мирас. 2006. № 2. Б. 39–42.

393. Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда // Матбугат йорты – гомер китабы: истәлек-хатирәләр. Казан: Мәгариф, 2006. Б. 124–127.

## II. Фәнни-теоретик һәм тәнкыйди әдәбият

### *Татар телендә*

1. *Абдрахманов Ф.* Шәриф Камал // Совет әдәбияты. 1941. № 5. Б. 85–86.

2. *Агзамов Ф.И.* Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: Сорок лет на Кремлевской: Сборник / сост. и ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 31–32.

3. *Ахунҗанов И.* Остаз // Художник һәм аның сүзе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 3–8.

4. *Ахунов Г.* Беренче остазым // Мәдәни җомга. 1997. 1 май.

5. *Ахунов Г.* Гази Кашшаф хатлары // Татарстан. 1994. № 7–8. Б. 76–80.

6. *Ахунов Г.* Сайланма әсәрләр: 5 томда, 4 т.: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 448 б.

7. *Ахунов Г.* Сайланма әсәрләр: 5 томда, 5 т.: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 383 б.

8. *Әгъзамов Ф.* Галим. Журналист. Педагог // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / сост. и ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 30–45.

9. *Әгъзамов Ф.* Игелек // Мәгърифәт. 1997. 1 май.

10. *Әгъзамов Ф.* Остаз // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр. 2008. Б. 9–10.

11. *Әгъзамов Ф.* Тугрылык // Мәдәни җомга. 1997. 25 апрель.

12. *Әгъзамов Ф.* Якты эз // Социалистик Татарстан. 1977. 14 апрель.

13. Әдәби тәнкыйть теориясе: Махсус фән программасы / төз. Р.Ф. Харрасова. Казан: КДУ нәшр., 2007. Б. 32.

14. Әдәбият баскычлары: Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917−1973). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 476 б.

15. Әдәбият белеме сүзлеге [Төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 238 б.

16. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

17. Әдәбиятка багышланган тормыш: Г. Кашшафка 60 яшь // Азат хатын. 1967. № 4. Б. 10.

18. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 1 т. / Төз. Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.

19. *Әминов Ю.* Заман белән бергә // Совет әдәбияты. 1962. № 1. Б. 136–142.

20. *Әпсәләмов Г.* Агыла болыт. Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 264 б.

21. *Әпсәләмов Г.* Ленинградтан кайткач // Социалистик Татарстан. 1965. 19 ноябрь.

22. *Әпсәләмов Г.* Сугышчан тәнкыйть өчен // Совет әдәбияты. 1954. № 6. Б. 79–90.

23. *Әхмәтҗанов М.И.* Мирасханә: фонд һәм коллекцияләр күрсәткече. Казан. 2005. 221 б.

24. *Бакиров Г.* Муса турында истәлекләр // Социалистик Татарстан. 1965. 17 январь.

25. *Баттал Ф.* Хакыйкать кадерлерәк // Мирас. 2009. № 9. Б. 29–41.

26. Г. Кашшаф − филология фәннәре кандидаты // Совет әдәбияты. 1961. № 1. Б. 68.

27. Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим. Очерк һәм эссе: югары уку йортларының журналистика бүлеге студентларына «Әдәби-публицистик жанрлар» курсыннан уку ярдәмлеге. Казан: КДУ нәшр., 2008. 200 б.

28. Гази Кашшаф (Тууына 90 ел) // Казан утлары. 1997. № 4. Б. 188.

29. Гази Кашшафның тууына 80 ел // Ялкын. 1987. № 4. Б. 25–26.

30. *Гайнуллина Г.Р.* Очерк // Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 133.

31. *Галиев М.* Без, без, без идек // Догалы еллар. Казан: Татар. газета-журн. нәшр., 1998. Б. 93.

32. *Галимуллин Ф.Г.* Әле без туганчы... Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 320 б.

33. *Галимуллин Ф.Г.* Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 303 б.

34. *Галиуллин Т.Н.* Әдәбият – хәтер хәзинәсе: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. Казан: Мәгариф, 2008. 231 б.

35. *Галиуллин Т.Н.* Социалистик реализм юлыннан... Тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 264 б.

36. *Гафуров Н.* Кайгыртучан киңәшче // Татарстан яшьләре. 1957. 17 апрель.

37. *Гаффар Ә.* Гасырлар улы // Ватаным Татарстан. 2006. 10 февраль.

38. *Гаффар Ә.* Соңгы җыры рәвешендә // Социалистик Татарстан. 1976. 12 март.

39. *Гомәр А.* «Совет әдәбияты» журналының соңгы саннары турында // Кызыл Татарстан. 1948. 27 гыйнвар.

40. *Гомәр А.* Бөек еллар тавышы // Совет әдәбияты. 1946. № 11–12. Б. 130–132.

41. *Гыйлаҗев Т.Ш.* Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.

42. *Гыйләҗев И.* Каһарманмы, хаинмы? // Ватаным Татарстан. 2009. 16 гыйнвар.

43. *Даутов Р.* Бай мираслы әдип: [Гази Кашшафның тууына 100 ел] // Мирас. 2007. Б. 34–37.

44. *Даутов Р.Н.* Совет Татарстаны язучылары: биобиблиографик белешмә / Р.Н. Даутов, Н.Б. Нуруллина. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 246–248.

45. *Җамалетдинова Ф.* Гази ага безне һаман да укыта // Ватаным Татарстан. 2007. 17 апрель.

46. *Җәлил М.* Сайланма әсәрләр. Казан: Хәтер, 2004. 566 б.

47. *Җәлил М.* Сайланма әсәрләр: 3 томда. 3 т. Казан: Таткнигоиздат., 1956. 444 б.

48. *Җәлилова Ә.* Дуслыкка тугрылык // Социалистик Татарстан. 1977. 14 апрель.

49. *Җәмдихан Р.* Чын тарихны өйрәнергә кирәк // Мирас. 2009. № 11. Б. 55–63.

50. *Закирҗанов Ә.М.* Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 175 б.

51. *Закирҗанов Ә.М.* Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 303 б.

52. *Зарипов Р.* Кемгә тәүбә итәсе? // Мирас. 2009. № 11. Б. 20–27.

53. *Иделле Г.* Партия һәм халык таләпләрен большевикларча үтәү өчен! // Кызыл Татарстан. 1946. 22 ноябрь.

54. *Исхак Ә.* Фидакарьлек // Азат хатын. 1977. № 4. Б. 13.

55. *Камал Ә.* Укытучы // Совет әдәбияты. 1943. № 7. Б. 76–78.

56. *Кәримуллин Ә.* Татар сәхнәсе. Әдәбият күрсәткече (1917–1967). Казан, 1979. 332 б.

57. *Кәримуллин Ә.Г.* СССР һәм чит ил халыклары әдәбияты, фольклоры һәм сәнгате: татар теленә тәрҗемәләр: библиография, 1917–1962. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1963. 337 б.

58. *Кудаш С.* Ике китапны укып чыккач… // Кызыл таң. 1957. 11 апрель.

59. *Кудаш С.* Безнең Гази // Социалистик Татарстан. 1967. 16 апрель.

60. *Максуд М.* Сагынган минутларда (Муса Җәлил турында истәлекләр һәм уйланулар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 190 б.

61. *М. Максуд* «Беренче тәҗрибә» // Совет әдәбияты. 1957. № 12. Б. 98–102.

62. *Малик Х.* Муса Җәлил турында истәлекләр // Совет әдәбияты. 1965. № 4. Б. 150 – 152.

63. *Маннапов Ш.* Тугрылык Алиһәсе // Мәдәни җомга. 2007. 13 апрель.

64. *Мәрдиева М.* «Совет әдәбияты» журналында... // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 50–58.

65. *Мәрдиева М.* Татар журналистикасы тарихы буенча очерклар: югары уку йортларының журналистика бүлеге студентларына «Татар

журналистикасы тарихы» курсы буенча уку ярдәмлеге. Казан: В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт ун-ты, 2003. 132 б.

66. *Мәрдиева М.* Эзләнүләр һәм үсеш юлыннан // Казан утлары. 1982. № 5. Б. 28.

67. *Мәхмүтов Р.* Чиста күңелле егет // Шәһри Казан. 2007. 24 август.

68. *Минский Г.* Халыкка хезмәт: Г. Кашшафка 60 яшь // Казан утлары. 1967. № 4. Б. 96–97.

69. *Мостафин Р.* Бер «зарарлы әсәр» тарихы... // Сүнмәс утлар балкышы. Казан: Идел-Пресс, 2006. 250 б.

70. *Мостафин Р.* Җаваплылык тойгысы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 200 б.

71. *Мостафин Р.* Муса Җәлил эзләре буйлап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 150 б.

72. *Мостафин Р.* Өзелгән җыр эзеннән. Документаль повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 464 б.

73. *Мостафин Р.* Репрессияләнгән татар әдипләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 175 б.

74. *Мостафин Р.* Хаиннан батыр ясап буламы? // Ватаным Татарстан. 2008. 12 декабрь.

75. *Мөбарәкшина Р.* Саргайган битләрдә – авыр еллар шәүләсе // Идел. 2012. № 2. Б. 62–63.

76. *Муса Җәлил:* Сайланма әсәрләр: 3 т. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Т. 3. 404 б.

77. *Муса Җәлил:* Тик антыма таплар кунмасын. Эшлекле мәҗлес // Мәдәни җомга. 2009. 22 май.

78. Муса турында истәлекләр. Төз. һәм әдәби эшкәртүчесе Г. Кашшаф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. 310 б.

79. *Нәфыйков К.* «Барбаросс инкыйразы» татар драматургиясенә яңалык алып килүче // Мирас. 2009. № 11. Б. 139–140.

80. *Небенцаль Л.* Җәлил рухы – шагыйрьнең дусты // Казан утлары. 1977. № 2. Б. 136–137.

81. *Низаметдинов З.* Гази Кашшаф – Җәлилнең иң якын дусты // Кызыл таң. 1997. 25 февраль.

82. *Низаметдинов З.* Гази Кашшаф // Кызыл таң. 2000. 9 февраль.

83. *Низаметдинов З.* Дустына тугры әдип // Татар иле. 2007. № 17. Б. 6.

84. *Низаметдинов З.* Җәлил дусты // Мәйдан. 2007. № 4. Б. 77–86.

85. *Низаметдинов З.* Җәлил дусты Кашшаф // Казан утлары. 2007. № 4. Б. 136–142.

86. *Низаметдинов З.* Җәлилнең якын дусты // Өмет. 1997. 20 май.

87. *Низамов И.* Остаз мирасына тугрылык // Мәдәни җомга. 2007. 27 апрель.

88. *Низамов И.* Очерк турында кереш сүз // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 59–61.

89. *Низамов И.* Ул «аралыктагы» жанр түгел // Гази Кашшаф − язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 88–92.

90. *Низамов И.* Үзебездә ниләр бар? // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 141–148.

91. *Нурмөхәммәтов Т.* Кадерле бүләк // Социалистик Татарстан. 1966. 6 февраль.

92. *Нуруллин И.* Тәнкыйтьче һәм галим // Социалистик Татарстан. 1967. 14 апрель.

93. *Нуруллина Р.* Аның кебек яшәсәң иде // Татарстан яшьләре. 1977. 16 апрель.

94. *Нуруллина Р.* Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 16.

95. *Нуруллина Р.* Вакыт сынавын үтеп // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим... Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 20–21.

96. *Нуруллина Р.* Җәлилнең җан дусты иде: Гази Кашшафның тууына 90 ел // Ватаным Татарстан. 1997. 25 апрель.

97. *Нуруллина Р.* Тугрылык // Казан утлары. 1987. № 6. Б. 172–173.

98. *Рәкыйпов Ш.* Беренче кирәкле шәйдер // Шәһри Казан. 1997. 18 апрель.

99. *Рәкыйпов Ш.* Олуг үрнәк иде // Гази Кашшаф – язучы-журналист, педагог, галим… Казан: КДУ нәшр., 2008. Б. 14–29.

100. *Рябков Г.* Татар совет әдәбиятының бер яклы үсеше турында // Кызыл Татарстан. 1947. 5 март.

101. *Сафуанов С.* М. Җәлил турында өч китап // Кызыл таң. 1962. 25 февраль.

102. *Сәхапов М., Яһүдин Э.* «Барбаросс» инкыйразы // Мирас. 2009. № 6,7.

103. *Сираҗи М.* Гази Кашшаф – Җәлилнең иң якын дусты // Өмет. 2000. 14 июнь.

104. «Совет әдәбияты» журналы редколлегиясе тарафыннан ясалган хаталар турында Партия өлкә комитеты карары. 25 февраль 1958 ел. Татарстан Республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, 15 ф., 6 тасв., 5112 эш, 10 кгз // «Гасырлар авазы – Эхо веков». 2011. № 1/2. Б. 100.

105. Сүнмәс утлар балкышы: мең санлы хәзинәдән. Казан: Идел-Пресс, 2006. 708 б.

106. Татар әдәби тәнкыйте тарихы: программа / төз. Э.Р. Галиева. Казан, 2003. 40 б.

107. Татар әдәби тәнкыйте тарихы: программа / төз. М. Мәһдиев, З. Мәҗитов. Казан, 1986. 20 б.

108. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 4: Татар совет әдәбияты (1917−1941). 568 б.

109. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Казан: Раннур, 2001. Т. 6: 60–90 еллар әдәбияты. 544 б.

110. Татар әдәбияты тарихы: 6 т: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941−1960). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. 544 б.

111. Татар әдәбияты тәнкыйте тарихы: махсус курс программасы / төз. Т. Гыйлаҗев. Казан: КДУ нәшр., 1999. 42 б.

112. Татар совет театры (Очерклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 494 б.

113. *Урманчеев Ф.* Җәлил белән яңадан очрашу // Казан утлары. 1977. № 8. Б. 35–37.

114. Үлемсез җыр. Татарстан президенты Минтимер Шәймиевнең Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган тантаналы җыелыштагы чыгышы // Ватаным Татарстан. 2006. 27 февраль.

115. Үлемсезлек таңында. Муса Җәлил турында истәлекләр. Ред. Г. Кашшаф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 102 б.

116. *Фасеев К.* Совет әдәбиятының һәм сәнгатенең яңа, көчле күтәрелеше өчен // Совет әдәбияты. 1949. № 6. Б. 131–142.

117. *Фәйзуллин Р.* Гыйбрәтләр алырлык үткән юл: фәнни-публицистик язма. Казан: Идел-Пресс. 2004. 152 б.

118. *Фәйзуллина М.* Совет хатын-кызының героик образын бозып бирүчеләргә каршы // Кызыл Татарстан. 1947. 7 июль.

119. *Халит Г.* Бүгенге татар әдәбиятында тәнкыйть мәсьәләләре // Совет әдәбияты. 1941. № 1-2. Б. 122–148.

120. *Халит Г.* Хәзерге әдәби тәнкыйтьнең торышына карата // Совет әдәбияты. 1954. № 8. Б. 53–64.

121. *Халитов Г.* Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 328 б.

122. *Хамматов Ш.* Васыятькә тугрылык // Социалистик Татарстан. 1984. 2 сентябрь.

123. *Ханов Г.* Берьяклы гына булмасын // Социалистик Татарстан. 1961. 16 сентябрь.

124. *Хәйри Х.* Тәнкыйтьче һәм әдәбиятчы // Совет Татарстаны. 1957. 14 апрель.

125. *Хәким С.* Герой шагыйрь турында китап // Социалистик Татарстан. 1961. 19 сентябрь.

126. *Хәким С.* Торыгыз, Мусалар! Шигырьләр, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970.

127. *Хәлим А.* Аның миңа язган васыяте бар // Шәһри Казан. 2000. 22 декабрь.

128. *Хәмитов М.* Яшьләрнең дусты // Татарстан яшьләре. 1967. 14 апрель.

129. *Хөсни Ф.* Моннан шагыйрь узды // Ф. Хөсни. Уйланулар (Әдәби осталык мәсьәләләре). Казан: Татар кит. нәшр., 1961. Б. 5–23.

130. *Хуҗин М.* Солтанатлы каһарман // Хуҗин М.Х. Кочасы иде дөньяны…: иҗат тасвирәте төсмерләре [Төз. Г. Насибуллова]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 47–68.

131. *Шакир С.* Батырлык эзләреннән // Татарстан яшьләре. 1976. 24 гыйнвар.

132. *Шәмин Ә.* Үтәлгән васыять // Татарстан яшьләре. 1976. 15 гыйнвар.

133. *Юзеев И.* Ут эчендәге чәчәк... һ.б. (шигырьләр) // Казан утлары. 1996. № 1. Б. 78.

134. *Юзиев Н.* Гази Кашшаф // Татар әдәбияты тарихы: 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 5. 503 б.

135. *Юзеев Н.* Муса Җәлил әсәрләренең өч томлыгы // Совет Татарстаны, 1957. 10 январь.

136. *Юзиев Н.* Муса Җәлил турында фәнни китап // Совет Татарстаны. 1957. 4 октябрь.

137. *Юзиев Н.* Партия миңа каләм бирде (Гази Кашшафның тууына 80 ел) // Социалистик Татарстан. 1987. 15 апрель.

138. *Юзиев Н.* Тәнкыйтьченең күркәм эше // Социалистик Татарстан. 1966. 5 июнь.

139. *Юзиев Н.* Укытучылар һәм язучылар дусты // Совет мәктәбе. 1967. № 4. Б. 58–59.

140. *Юзиев Н.* Фидакарьлек // Әдәбият хәзинәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 127–140.

141. *Юзиев Н.* Фидакарьлек // Казан утлары. 1977. № 4. Б. 149–153.

## ***Рус телендә***

142. *Агзамов Ф.* Верность: К 80-летию со дня рождения Гази Кашшафа // Советская Татария. 1987. 15 апреля.

143. *Агзамов Ф.* Первый джалиловед // Муса Джалиль и патриотические традиции в советской литературе. Материалы Всесоюзной научной конференции, посвященной 80-летию поэта-героя. Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. С. 195–205.

144. *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1941–1956). Казань, 1996. 224 с.

145. *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1956–1990). Казань, 2002. 272 с.

146. *Ахмадуллин А.Г.* Горизонты татарской драмы. Статьи. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 216 с.

147. *Ахунзянов И.* Учитель и ученики // Советская Татария. 1977. 15 апреля.

148. *Бикмухаметов Р.* Биограф поэта // Вопросы литературы. 1962. № 5. С. 235–237.

149. *Бикмухаметов Р.* Волнующая книга // Советская Татария. 1957. 23 мая.

150. *Бикмухаметов Р.* Муса Джалиль: Личность. Творчество. Жизнь. М.: Худ. лит., 1989. 286 с.

151. *Бикмухаметов Р.* Поздравляем юбиляра // Литературная газета. 1967. 12 апреля.

152. *Бикмухаметов Р.Г.* Творческий путь Мусы Джалиля / СП СССР. Лит. ин-т им. А.М. Горького. М., 1955. 17 с.

153. Введение в литературоведение: учеб. пособие / Л.В. Чернец, В.Е. Хализев, А.Я. Эсалнек и др.; Под ред. Л.В.Чернец. М.: Высш. шк., 2006. 680 с.

154. *Воздвиженский В.* «Моабитские тетради» Мусы Джалиля. М.: Наука, 1969. 156 с.

155. *Воздвиженский В.* Поэзия Мусы Джалиля. Казань: Таткнигоиздат, 1981. 120 с.

156. Воспоминания о Мусе Джалиле / Сост. Г. Кашшаф, Р. Мустафин. Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. 236 с.

157. Гази Кашшаф. Некролог // Советская Татария. 1975. 11 декабря.

158. *Гафаров А.* Верность // Комсомолец Татарии. 1976. 8 февраля.

159. *Гизатуллин Н.* Видный татарский критик // Советская Татария. 1957. 16 марта.

160. *Гилязов И.А.* Легион «Идель-Урал». Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменем «третьего рейха». Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. 383 с.

161. *Голубков М.М.* История русской литературной критики XX века (1920–1990-е годы): учеб. пособие для студ. филол. фак. ун-тов и вузов. М.: Академия, 2008. 366 с.

162. *Джалилова Х.* О моем брате. Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. 96 с.

163. *Джалиль М.* Красная ромашка / Пер. с татарского. Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. 544 с.

164. *Елисеев И.* Словарь литературоведческих терминов / И.А. Елисеев, Л.Г. Полякова. Ростов н/Д: Феникс, 2002. 319 с.

165. *Енакаев Р.* По завещанию Мусы // Южный Урал (Оренбург). 1984. 1 ноября.

166. *Есин А.Б.* Принципы и приемы анализа литературного произведения: учеб. пособие. 5-е изд. М.: Флинта: Наука, 2003. 248 с.

167. *Забиров И.* Джалиль и джалильцы: Документальные очерки и этюды. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 143 с.

168. *Зинченко В.Г.* Методы изучения литературы. Системный подход: учеб. пособие / В.Г. Зинченко, В.Г. Зусман, З.И. Кирнозе. М.: Флинта: Наука, 2002. 200 с.

169. История русской литературной критики: учеб. для вузов / Под ред. В.В. Прозорова. М.: Высш. шк., 2002. 460 с.

170. История русской литературно-художественной критики XX века: методические указания к курсу. Казань: Казан. гос. ун-т им. В.И. Ульянова-Ленина, 2003. 23 с.

171. История русской советской литературы / под ред. П.С. Выходцева. М.: Высш. шк., 1986. 632 с.

172. Гази Кашшаф // Писатели Советского Татарстана. Биобиблиографический справочник / Сост. и. Гиниятуллина. Казань, 1970. С. 227–230.

173. *Камал Г.* Первый театр. Казань: Таткнигоиздат, 1939. 32 с.

174. *Кашафутдинова А.* Стена пустует // Советская Татария. 1989. 3 сентября.

175. *Кожинов В.В.* Статьи о современной литературе. М.: Сов. Россия, 1990. 544 с.

176. *Колесникова Е.* Вместо диссертации // Советская Татария. 1961. 19 февраля.

177. *Куранов К.Н.* Верность дружбе // Между прошлым и будущим: сорок лет на Кремлевской: сборник / сост. И ред. В.З. Гарифуллин, Д.В. Туманов. Казань, 2002. С. 46–48.

178. Литературная энциклопедия терминов и понятий / под ред. А.Н. Николюкина. М.: НПК «Интелвак», 2003. 1600 стб.

179. Литературный энциклопедический словарь. М.: Советская энциклопедия, 1987. 750 с.

180. *Мардиева М.* Гази Кашшаф – редактор журнала «Совет әдәбияты» / М. Мардиева // Тонус. 1997. № 2 (3). С. 69–76.

181. *Махмудов А.Г.* «Лишь в свободе жизни красота…»: Поэтическое наследие Мусы Джалиля в свете современной эстетической мысли. Казань: Магариф, 2006. 95 с.

182. *Махмутов Х.К.* Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. С. 90 – 100.

183. *Муромский В.* Русская советская литературная критика (Вопросы истории, теории и методологии). Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1985. 150 с.

184. Муса Джалиль (Библиография. 1919–1961) / Сост. А.Г. Каримуллин. Казань, 1961. 78 с.

185. Муса Джалиль. Библиографический указатель. 1919–1973 (на татарском и русском языках). Казань: Изд-во Казанск. ун-та, 1976. 222 с.

186. Муса Джалиль. Указатель литературы. 1974–1984 (на татарском и русском языках) / Сост. Н.А. Ахметзянова, Р.С. Камалова, Р.Г. Гиниятова. Казань: Изд-во Казанск. Ун-та, 1987. 128 с.

187. Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века / Сост. Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова. Казань: Казанский государственный университет им. В.И.Ульянова-Ленина, 2006. 150 с.

188. Муса Джалиль. Фотоальбом. 1906–1966. Сост.: Г. Кашшаф, Ф. Акчурин. Казань: Татгосиздат, 1966. 190 с.

189. *Мустафин Р.* Завещание // Советская Татария. 1984. 11 ноября.

190. *Мустафин Р.* Засекреченные страницы // Литературная газета. 2006. № 9.

191. *Мустафин Р.* Как работал Джалиль // Вечерняя Казань. 2006. 8 февраля.

192. *Мустафин Р.* Научные публикации о жизни и творчестве Мусы Джалиля (Джалиловедение как наука) // Муса Джалиль: творчество и подвиг. Взгляд из XXI века / Сост. Х.Ю. Миннегулов, Н.М. Юсупова. Казань: Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина, 2006. С. 15–20.

193. *Мустафин Р.* По завещанию Мусы Джалиля: К 100-летию со дня рождения Гази Кашшафа // Республика Татарстан. 2007. 17 апреля.

194. *Мустафин Р.* По следам оборванной песни. Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. 399 с.

195. *Мустафин Р.* Слово о старшем друге // Советская Татария. 1967. 16 апреля.

196. *Нигматуллина Ю.Г.* Комплексное исследование художественного творчества. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1990. 152 с.

197. Основы литературоведения: учеб. пособие для филологических факультетов пед. ун-тов / под общ. ред. В.П. Мещерякова. М.: Московский лицей, 2000. 372 с.

198. *Петровская И.Ф.* Еще раз об источниках биографических сведений о русских писателях и их окружении // Русская литература. Л., 1984. № 2. С. 192–202.

199. Подвиг и духовное наследие М. Джалиля в системе российских ценностей. Оренбург: Изд. центр ОГАУ, 2006. 308 с.

200. Проблемы социалистического реализма. М.: Изд-во Московского ун-та. 1975. 352 с.

201. *Рамеев З.З.* Текстология татарской литературы начала XX века. Казань: Алма-Лит, 2008. 188 с.

202. *Резвова Т.* Живет и побеждает // Литературная Россия. 1966. 11 марта. С. 10.

203. Русская литературная критика. История и теория. Межвузовский научный сборник. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1988. 160 с.

204. *Салихова А.Р.* Литературно-критическое наследие Габдрахмана Карама: Автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 20 с.

205. Советская литература в прошлом и настоящем / под ред. И.Ф. Волкова. М.: Изд-во МГУ, 1990. 157 с.

206. Советская многонациональная литература (Очерк развития): учеб. пособие для филол. спец. вузов / под ред. Г.И. Ломидзе. М.: Высш. шк., 1986. 199 с.

207. Современная русская советская литература. Темы. Проблемы. Стиль. В 2 ч. М.: Просвещение. 1987. Ч. 2. 256 с.

208. Сочинения. Стихи. Поэмы. Критика, публицистика. Автобиографические заметки, письма. Воспоминания о М. Джалиле (А. Джалиль, Г. Кашшаф, письмо А. Фадеева, К. Симонова, М. Иконникова, Л. Небенцаль). Примечания Г. Кашшафа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1962. 606 с.

209. Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). Казань, 1981. 128 с.

210. Указ Президиума Верховного Совета СССР о награждении писателя Гази Кашшафа орденом «Знак Почета» // Литературная газета. 1967. 1 мая.

211. *Умеров Ш.* Книга о настоящем человеке // Вопросы литературы. 1966. № 10. С. 222–224.

212. Философия социальных и гуманитарных наук: учеб. пособие для вузов / под общ. ред. проф. С.А. Лебедева. М.: Академический проект, 2006. 852 с.

213. *Хализев В.Е.* Теория литературы: учеб. 3-е изд., испр. и доп. М.: Высш. шк., 2002. 347 с.

214. *Хамматов Ш.* Ему завещал Джалиль: К 80-летию со дня рождения Гази Кашшафа // Вечерняя Казань. 1987. 15 апреля.

215. *Ханзафаров Н.Г.* Татарская комедия. Казань: ФӘН, 1996. 268 с.

216. *Ханин Л.* Письмо Мусы Джалиля // Нева. 1958. № 11. С. 238–239.

217. *Холиков А.А.* Биография писателя как жанр: учеб. пособие. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2010. 96 с.

218. *Холиков А.А.* Писательская биография: жанр без правил // Вопросы литературы. 2008. № 6. С. 41–62.

219. *Юзеев Н.* Доверие. // Кашшаф Гази. По завещанию Мусы Джалиля. Казань, 1984. С. 3–14.

220. *Юзеев Н.* Мир поэта. Творческие портреты Х. Такташа, М. Джалиля, Х. Туфана, С. Хакима. Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. С. 63–125.

221. *Юзеев Н.Г.* Поэмы Мусы Джалиля. Казань, 1958. 20 с.

## Summary

The monograph is devoted to the study of literary criticism and scientific work of the famous Tatar literary critic, scholar, teacher, journalist, writer, social activist and founder of Jalil's science, one of the authors of textbooks and anthologies by Tatar literature of the Soviet period for schools, an active participant in the literary life of 20–70- ies of XX century Gazi Kashshaf (Mirgazi Sultanovich Kashshafut-dinov, 1907–1975).

Works, specifically examining the literary-critical and scientific heritage of G. Kashshaf, virtually are not in existence. However, many reviews and memories of colleagues and friends G. Kashshaf are preserved that help to provide more than forty-year artistic career critic and scholar, his role in the literary process of the Soviet era.

The book consists of four chapters. The first of these covers biography, multifaceted, creative and social activity on the background of criticism of historical and socio-political realities of the Soviet era. G. Kashshaf is presented here as a teacher of high school, one of the founders of the Department of Journalism at the Kazan State University, author of textbooks.

Particular emphasis is placed on the editorial position of criticism, which he held for many years in the Tatar literary and artistic and socio-political magazine "The Council adabiyaty" ("Soviet literature", now "Kazan Utlary" – "Lights of Kazan"). Literary career of G. Kashshaf is considered as separate chapter, the analysis of literary works of the author leads to some interesting conclusions.

The third chapter of the monograph reveals talent of G. Kashshaf as a critic and scholar. In his works, he pays great attention to the writer's biography, the process of formation of their creativity. In reviews, articles, reports, literary portraits and other genres of criticism it explores the work of many well-known Tatar Soviet writers. A special place in the activities of G. Kashshaf takes theater criticism. He admires the acting talent, staging director, assesses the performances and works that underlie them. Criticism also take place sometimes.

The last chapter of the book introduces readers to the activities of G. Kashshaf as Jalil scientist and his research in this direction. As a close friend of the poet, he has done everything possible in the way of execution of his will. It was in the papers about Musa Jalil clearly reflected plexus creative thinking and scientific criticism.

Научное издание
*Серия «Библиотека журнала «Фәнни Татарстан»*
3-я книга

***Бадертдинова Ляйсан Шаукатовна***
**ЛИТЕРАТУРНО-КРИТИЧЕСКАЯ И НАУЧНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ГАЗИ КАШШАФА**
(на татарском языке)

Фәнни басма
*"Фәнни Татарстан" журналы китапханәсе*
3 нче китап

***Бәдертдинова Ләйсән Шәүкәт кызы***
**ГАЗИ КАШШАФНЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ҺӘМ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

Редактор *Я.М. Абдулкадыйрова*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Басарга кул куелды 12.12.2014.
Формат 60х84 1/16. Офсет кәгазе. Times New Roman гаринтурасы
Офсет басма. Шартлы басма табагы 12,3. Нәшер-хисап табагы 9,7
Тираж 300. Заказ К-17

Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31